# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2022 1(33)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык шагыйре (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Нур-Солтан)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

## БУ САНДА

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Кадирова Э.Х., Фәйзуллина Г.Ч.* Тубыл губернасының XIX гасыр һәм XX гасыр башы метрика кенәгәләрендә туганлык атамалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Миңнуллин К.М., Сабитова И.И.* Татар халкының борынгы җырларында соматизмнар һәм аларның функциясе . . . . . . . . . 15
*Гыйлемшин Ф.Ф.* Тәрҗемә әсәрләрдә алмашлыкларның кулланылыш үзенчәлекләре *(«Мең дә бер кичә», «Тутыйнамә», «Кәлилә вә Димнә», «Кырык вәзир кыйссасы» һәм «Әбүгалисина кыйссасы» әсәрләре нигезендә)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
*Хаҗиева Г.С.* Татар теле лексикасының экспрессив-стилистик катламнары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
*Куряева Р.И.* Казансу бассейны гидронимнары һәм ойконимнары арасындагы үзара бәйләнеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
*Хәбибуллина Л.Г.* Татар телендә ситуатив һәм мотивлы хәл мөнәсәбәтләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Гомәров И.Г.* Болгар чоры әдәбиятын өйрәнүдә яңа язма чыганак: Сөләйман бине Дауд Суваринең «Зөһрәт әр-рийаз...» әсәре 49
*Дәүләтшина Л.Х.* Г. Гыйльмановның балалар өчен язылган әсәрләрендә мифологик катлам . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
*Надыршина Л.Р.* Харрас Әюп поэмаларында милли яшәеш проблемалары. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
*Шәрипова А.С.* XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар драматургиясендә халык язмышы темасы *(Т. Миңнуллин, Д. Салихов, Р. Зәйдулла әсәрләре мисалында)* . . . . 72

### ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВКА – 135

*Ибраһимов М.И.* Галимҗан Ибраһимов иҗатында миллият мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
*Миңнуллина Ф.Х.* Г. Ибраһимов тәнкыйтендә заман драматургиясенә мөнәсәбәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
*Фәйзуллина Ф.Г.* Галимҗан Ибраһимов иҗаты – академик басмада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
*Шәриф Байчура.* Галимҗан Ибраһимов белән очрашулар *(Истә калганнардан)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Җыр жанрында такмаклар: төрләре һәм функцияләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
*Яруллина-Йылдырым Р.Ә.* Татар һәм төрек халыкларында сөннәт йоласы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120

*Закирова И.Г.* Татар фольклорында Кендек әбиләре образы
*(Истәлекләр һәм сөйләкләр мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . . 127

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Дәүләтшина Л.Ш.* XX гасыр башы татар җәмгыятендә
хатын-кыз мәгарифе мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132

## СӘНГАТЬ

*Шкляева Л.М.* Идел буендагы җирле халыклар эстетикасында
изге имән образы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
*Бердникова О.Ю.* Татарстанда заманча мода юнәлеше булган
киез һәм ефәк костюмнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144

## ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР

Солтан Габәши татар музыкасы турында. . . . . . . . . . . . . . . 149

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Мәрданова Ф.Ф.* Беренче татар этнографы . . . . . . . . . . . . . 161

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Юсупова Н.М.* Тукай фәнендә яңа офыклар . . . . . . . . . . . . 168
*Ключевская Е.П.* Султанова Р.Р. Школа мастеров: художественное
образование в сфере сценографии в Казани (Казань: Татар. кн.
изд-во, 2021. 280, с. ил.) китабына бәяләмә . . . . . . . . . . . . 174
*Бәширова И.Б.* Абдуллина Ч.З., Сәгъдиева Ф.К. Татарстан
Республикасында тел вәзгыяте: Татар теленең кулланылыш
даирәсе (Казан, 2021. 136 б.) китабына бәяләмә . . . . . . . . . . 177

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Кадирова Э.Х., Файзуллина Г.Ч.* Термины родства в метрических книгах Тобольской губернии XIX – начала XX века 7
*Миннуллин К.М., Сабитова И.И.* Соматизмы в татарских народных старинных песнях и их функции . . . . . . . . . . . . . . . . 15
*Гилемшин Ф.Ф.* Особенности использования местоимений в переводных произведениях *(на примере произведений «Мең дә бер кичә», «Тутыйнамә», «Кәлилә вә Димнә», «Кырык вәзир кыйссасы» и «Әбүгалисина кыйссасы»)* . . . . . . . 23
*Хазиева Г.С.* Экспрессивно-стилистические пласты лексики татарского языка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
*Куряева Р.И.* Взаимосвязь гидронимов и ойконимов бассейна р. Казанка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
*Хабибуллина Л.Г.* Ситуативные и мотивировочные взаимосвязи обстоятельственных отношений татарского языка . . . . . . . . . 43

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Гумеров И.Г.* Новый письменный источник по литературе периода Волжской Булгарии: «Зухрат ар-рийаз...» Сулеймана бин Дауда Сувари . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
*Давлетшина Л.Х.* Мифологический пласт в произведениях Г. Гильманова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
*Надыршина Л.Р.* Проблемы национального бытия в поэмах Харраса Аюпа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
*Шарипова А.С.* Тема судьбы народа в татарской драматургии рубежа XX–XXI веков *(на примере пьес Т. Миннуллина, Д. Салихова, Р. Зайдуллы)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72

## ГАЛИМДЖАНУ ИБРАГИМОВУ – 135

*Ибрагимов М.И.* Проблемы национальной идентичности в творчестве Галимджана Ибрагимова . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
*Миннуллина Ф.Х.* Отношение к современной драматургии в критике Г. Ибрагимова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
*Файзуллина Ф.Г.* Академическое издание произведений Галимджана Ибрагимова. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
*Шариф Байчура.* Встречи с Галимджаном Ибрагимовым *(Воспоминания)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Мухаметзянова Л.Х.* Жанровые особенности такмаков . . . . . . 114
*Яруллина-Йылдырым Р.А.* Обряд обрезания у татар и тюркских народов . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
*Закирова И.Г.* Образ повивальной бабки в татарском фольклоре . 127

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Давлетшина Л.Ш.* Женское образование в татарском обществе начала XX века . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132

## ИСКУССТВО

*Шкляева Л.М.* Образ священного дуба в эстетике коренных поволжских народов . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139

*Бердникова О.Ю.* Костюмы из войлока и шелка, как направление современной моды в Татарстане . . . . . . . . . . . . . . . . 144

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

Султан Габаши о татарской музыке . . . . . . . . . . . . . . . 149

## ПЕРСОНАЛИИ

*Марданова Ф.Ф.* Первый татарский этнограф . . . . . . . . . . . 161

## НОВЫЕ КНИГИ

*Юсупова Н.М.* Новые горизонты в тукаеведении . . . . . . . . . 168

*Ключевская Е.П.* Рецензия на книгу «Султанова Р.Р. Школа мастеров: художественное образование в сфере сценографии в Казани (Казань: Татар. кн. изд-во, 2021. 280, с. ил.)» . . . . . . 174

*Баширова И.Б.* Рецензия на книгу «Абдуллина Ч.З., Сәгъдиева Ф.К. Татарстан Республикасында тел вәзгыяте: Татар теленең кулланылыш даирәсе (Казань, 2021. 136 б.)». . . . . . . . . . . . . 177

УДК 81´373.232.4

***Э.Х. Кадирова,***
***Г.Ч. Фәйзуллина***

# ТУБЫЛ ГУБЕРНАСЫНЫҢ XIX ГАСЫР ҺӘМ XX ГАСЫР БАШЫ МЕТРИКА КЕНӘГӘЛӘРЕНДӘ ТУГАНЛЫК АТАМАЛАРЫ

В качестве источника метрические книги, прежде всего, интересуют историков с точки зрения генеалогических и демографических исследований. Кроме того, они дают богатый материал и для лингвистических исследований. Изучение метрических документов позволяет рассмотреть разные пласты лексики. В статье дается описание терминов родства в метрических книгах Тобольской губернии XIX – начала XX века. Результаты исследования интересны как ценный источник для татарской исторической лексикологии и диалектологии.

**Ключевые слова:** татарский литературный язык, термины родства, сибирские татары, Тобольская губерния, метрические книги.

As a source, metric books are primarily of interest to historians from the point of view of genealogical and demographic studies. In addition, they provide rich material for linguistic research. The study of metric documents allows you to consider different layers of vocabulary. The article describes the kinship terms in the metric books of the Tobolsk province of the 19th – early 20th centuries. The results of the study are interesting as a valuable source for Tatar historical lexicology and dialectology.

**Keywords:** Tatar literary language, kinship terms, Siberian Tatars, Tobolsk province, metric books.

Мәкаләдә себер татарларының XIX гасыр һәм XX гасыр башы метрика кенәгәләрендә урын алган туганлык атамаларын барлап, анализ бирү максаты куела.

Тикшеренү объекты – Тубыл губернасы Тубыл өязенең XIX гасыр һәм XX гасыр башына караган кулъязма метрика кенәгәләре.

Анализ өчен Күкрәнде, Әшле, Комарау юрталарының XIX гасырның 30 нчы елларыннан XX гасыр башына кадәрге чорда теркәлгән документлары алынды. Күкрәнде документларында – Күкрәнде, Кундан, Ләчек, Әшле кенәгәләрендә – Әшле, Комарау текстларында Комарау һәм Хан авыллары халкы турында мәгълүматлар китерелә. Язмаларда 1) туган балалар, 2) никахлашкан, аерылышкан һәм 3) үлгән кешеләр теркәлгән.

Туганлык терминнары телнең иң борынгы катламын тәшкил итәләр һәм, нигездә, үзгәрешсез саклананалар. Мондый терминнар безнең тарафтан каралган документларда утыздан артык исәпләнә һәм алар туганлыкның барлык төп төшенчәләрен үз эченә ала.

Төрки тел белемендә дә Л.А. Покровскаяның «Термины родства в тюркских языках» исемле мәкаләсе үзенең күләме, эчтәлегенең

тирәнлеге белән аерылып тора һәм бүгенге көндә дә әһәмиятен югалтмый [Покровская]. Татар телендә туганлык терминнарын монографик планда Д.Б. Рамазанова өйрәнә [Рамазанова]. Әлеге галимнәрнең хезмәтләрендә туганлык терминнары 1) кан буенча һәм 2) никах буенча кардәшлек атамалары дип аерып карала.

Кан буенча кардәшлекнең төп төшенчәләре – бабай һәм әби, ата һәм ана, ул һәм кыз, абый һәм сеңел.

Әйтергә кирәк: метрика кенәгәләре махсус тәртип белән тутырыла [Фәйзуллина, Кадыйрова, б. 18–21]. Туу турындагыларында баланың җенесен белдергән атама һәм аның атасы белән анасы турында мәгълүмат китерелсә, вафатларны исәпкә алганнарында бары тик мәрхүмнең үзе турындагы мәгълүмат бирелә. Никах документлары туганлык атамаларына иң бай бүлек санала. Аларда булачак ир белән хатын, аларның әтиләре (кайбер очракларда бабалары турында да өстәмә китерелә), никахның шаһитлары турында тулы мәгълүмат язылганлыктан, атамалар арта. Күпчелек очракларда шаһитлар килен белән кияүнең туганнары булганлыктан, документлар туганлык терминнарына байый. Тагын шуны әйтергә кирәк: шаһитларның ирләр арасыннан булырга тиешлегеннән чыгып, текстларда ир җенесенә кагылышлы туганлык терминнары урын ала. Һәр очракка аерым тукталыйк.

Документларның аерым кысага салынган булуы һәм аларда даими гыйбарәләр белән эш итү мәҗбүрилеге бер төрлерәк лексемалар кулланылуга китерә. Туу документларында *атасы* (его (ее) отец), *анасы* (его (ее) мать) сүзләре килә: ***Атасы** ясаклы Хабибулла, **анасы** Янбикә* (Әшле), ***Атасы** ясаклы Тукдаган, **анасы** Сөярбикә* (Күкрәнде), ***Атасы** сарт Түләк, **анасы** Мәликә* (Комарау). Никах язулары өлешендә *ата* сүзенең *атасы*, *әткәсе, әтекәсе* формалары урын ала: *Кыз тарафыннан **әткәсе** Уразмөхәммәд Торыш углы вәли вәкил булды* (Күкрәнде); *Кыз тарафыннан **әтекәсе** Бикбулат Кубшан углы вәли вәкил булды вә кияү тарафыннан **әтекәсе** Сәфәр Ходайкол углы вәли вәкил булды* (Әшле); *Кыз тарафыннан **атасы** Мөхәммәднияз Мөхәммәдбакый углы вәли вәкил булды* (Комарау). *Әткә* сүзе тубыл-иртыш диалектында эти мәгънәсендә кулланыла [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, б. 89], *әтекә* формасының да әлеге диалектта шул төшенчәне белдерүе мәгълүм. Кайбер документларда *ата, әткә*, *әтекә* сүзенең мәгънәсен конкретлаштыру максатыннан, *тугма әтекәсе* (родной отец) атамасы килә: *Мәзкүрә кызым Сәрибә өчен вәли вәкил **тугма әтекәсе** Бикбулат Кубшан углы әлимза кылдым* (Әшле). Әшле метрика китапларындагы 1861 елгы никах документларында *үгәй әтекәсе* атамасы очрый. Ул *үгәй кыз* атамасы белән янәшә килә: *Мәзкүрә **үгәй кызым** Шәкәр өчен вәли вәкил әтекәсе Габдерәхим Теләүбирде әлимза кылдым. – Кыз тарафыннан **үгәй әтекәсе** Габдерәхим Теләүбирде углы вәли вәкил булды* (Әшле). Ике янәшә мисалда аерма шунда: текст атаның үзе исеменнән язылганда – *әтекәсе*, мәчет вәкиле тарафыннан язылган өлешендә *үгәй әтекәсе* дип бирелә. Комарау документларында *асраган атасы* термины очрады: *Кыз тарафыннан*

***асраган атасы*** *Мөхәммәдрузый Гомәр мәрхүм углы вәли вәкил булды* (Комарау). Тагын бер үзенчәлекле очрак бар: *Кыз тарафындан* ***үгәй атасы*** *казак Алимбай Йулдаш углы Корманоф хазир булуб, вәли вәкил булды вә кияү тарафындан* ***үз атасы*** *Мөхәммәдкасыйм Һәвазбакый углы Бикшаноф хазир булуб, вәли вәкил булды*. Бу мисалда *үгәй атасы* атамасына *үз атасы* термины каршы куела. Шунда ук үги әтисе исеменнән әлеге документны тутыручы дин әһеле *мәзкурә кызым* дип күрсәтә, *үгәй кызым* дими: *Мәзкур шартга* ***мәзкурә кызым*** *Хәлимәбикә Сөйдүк кызының ризалыгы илән вә аның хат белмәслеге өчен вә хазир соравы илән мән Алимбай Йулдашов Корманоф кулум куйдым* (Комарау). *Үз атам* очрагы XVII йөз эш кәгазьләрендә дә теркәлгән [Старотатарская..., с. 149]. Шул ук төбәк текстларында атаның үги кызын *асраган кызым* дип атаган мисал да бар: *Мәзкур шартга мәзкурә* ***асраган кызым*** *Рәсәләнең ризалыгы илән, вә аның хат белмәслеге өчен, вә аның хазир соравы илән, мән вәли вәкил булгучы Рузыймөхәммәд Гомәр мәрхүм углы кулум куйдум* (Комарау).

Шул рәвешле, ата һәм ана төшенчәләрен бирүдә Тубыл губернасы метрика китапларын тутыручылар тарафыннан *атасы, анасы, әткәсе, әтекәсе, үгәй әтекәсе, тугма әтекәсе, үгәй атасы, үз атасы, асраган атасы* атамалары файдаланыла. Әлеге терминнар иске татар язма истәлекләрендә очрый, хәзерге татар әдәби телендә һәм сөйләшләрдә актив кулланыла.

Никах кенәгәләрендә кызның да, кияүнең дә шаһитлары булып, нигездә, этиләре яки ир туганнары килә. Әшле текстларында бер урында бабай термины очрады: *Кыз тарафындан* ***бабасы*** *Госман Назарбакый углы вәли вәкил булды* (Әшле). Комарау никах документларында кызыклы мисал теркәлгән. Документны тутыручы бабайның кызның анасының атасы икәнлегенә басым ясый: *Кыз тарафындан* ***анасының атасы*** *Рәхмәтулла Мәмәтйар углы вәли вәкил булды.*

Кечкенә яшьтәге сабыйларны, кыз баланы һәм ир баланы атау өчен күп очракта документларда *углан* сүзе кулланыла, ягъни *кыз углан, ир углан.* Күкрәнде, Әшле, Комарау документларында туу турындагы текстларда ир бала һәм кыз баланы шушы рәвешле теркиләр: ***Кыз углан*** *Әминә,* ***ир углан*** *Яшәр.* Комарау китапларында берничә елгы язмаларда *кыз Бибизаһирә, ир углан Торуш* формасы килә, ягъни кыз балага углан сүзе язылмый. *Ир Нәҗмеддин, кыз Зарифа* кебек бирү очраклары да бар. Әшле һәм Күкрәнде юрталарының вафат булганнарны теркәү текстларында алар белән беррәттән гарәп алынмалары *сабый* (ир бала), *сабыя* (кыз бала) лексемалары килә: *сабыя Уразбикә, сабый Габдессәлам* (Әшле). 1 – صبى) мальчик, юноша; парень; 2) мальчик, подмастерье, ученик [Баранов, с. 540]. صبية – девочка, девушка [Баранов, с. 540]. Бу сүз яңа туган балалардан алып, нигездә, 4–5 яшькә кадәрге, сигез, тугыз, хәтта бер очракта 15 яшьтәгеләргә дә карый. Шушы төр документларда берничә урында *балига* алынмасы килә. Мәсәлән, унсигез яшендәге кыз баланың вафаты турындагы хәбәрдә *Балига Насыйбә, 18 яшендә* дигән

язма урнаштырыла. Кеңәгәләрдә бала төшенчәсен бирүдә бала сүзе очрамый, әмма үлү сәбәпләрен күрсәткән графада ***бала*** *тугырмакдан вафат булды* (Әшле); ***Бала*** *кәтүрмәк зәхмәте илән вафат улды* (Комарау) мисалларында әлеге лексема кулланыла. Балалар авыруы (кызамык) атамасы урынына *углан зәхмәте* термины файдаланыла.

Метрика китапларында *углан* сүзе бала төшенчәсен белдерсә, *угыл* лексемасы 'ул' мәгънәсендә килә: *Тобол губернасы шул ук өязе Әшле авылының мәншүрле мәхәллә имамы мулла Искәндәр Кубшан* ***углы*** *никах хотбәсене укудыгыма әлимза кылдым* (Күкрәнде).

'Бер нәселдән булган, туган кешене' татар әдәби телендә *кардәш, карендәш* диләр. Бу ике атама тыва, чуваш, якут телләреннән башка барлык төрки телләрдә кулланыла. *Карендәш* формасы борынгырак санала һәм сүзнең килеп чыгышы *карын+даш* буларак аңлатыла [Покровская, с. 38]. Документларда *тугма карендәше, дугма карендәше, тугма агасы, тугма ахы, карендәше, бертугма карендәше* атамалары очрый. Соңгы елларда беренче вариант активлашса да, борынгырак чорда, киресенчә, карендәш лексемасы еш очрый. Ф. Хисамова XVIII йөз эш кәгазьләрендә *карендәш* лексемасының кулланылуын ассызыклый [Хисамова, б. 47]. XVIII гасыр шагыйре Габдессәлам шигырьләрендә шулай ук *карендәш* термины килә [XVIII гасыр татар әдәбияты, б. 50]. Г. Тукай иҗатында алар икесе дә урын ала [Габдулла Тукай, б. 396–397]. Без тикшерә торган текстларда әлеге лексема нәкъ шул төшенчәләрне белдереп килә: *Кияү тарафындан* ***карендәше*** *Габбас Бәдрәш углы вәли вәкил булды* (Күкрәнде); *Кияү тарафындан* ***карендәше*** *Мәләх Бикмәмәт углы вәли вәкил булды* (Әшле); *Кыз тарафындан* ***карендәше*** *Ибраһим Кырымшак углы вәли вәкил булды вә кияү тарафындан* ***карендәше*** *Йыйанхуҗа Әбуталиб углы вәли вәкил булды* (Комарау).

*Карендәш* сүзе кыз лексемасы белән янәшә *кыз туганым* дигәнне аңлата: *Мәзкурә* ***кыз карендәшем*** *Аидбикә өчөн вәли вәкил карендәше Колмөхәммәд Әлмөхәммәд углы әлимза кылдым* (Күкрәнде); *Мәзкурә* ***кыз карендәшем*** *Уразбикә өчөн вәли вәкил карендәше Габделгази Хәлил углы әлимза кылдым* (Әшле); *Мәзкур шартга* ***кыз карендәшем*** *Бибиҗамал Этбакмас мәрхүмнең кызының ризалыгы илән мән вәли вәкил булгучы Ибраһим Кырымшак углы әлимза кылдум* (Комарау). Мисалларда, алдагы баганалардагы мәгълүмат буенча, беренче ике очракта бертуганнар аңлашылса, соңгысында атасының бертуганы күздә тотыла. Һәр төр документларда да мондый мисаллар бар.

*Тугма карендәше, дугма карендәше, кардәше, тугма агасы, агасы, тугма ахы* лексемалары документларда аерым урыннарда шулай ук бер төшенчәне белдереп килә дип нәтиҗә ясарга мөмкин, әмма *карендәш* сүзенең *абый* яки *эне* атамаларының кайсы очракта кайсын белдерүен текстларда аңлау мөмкинлеге юк.

Бер үк документның ике баганасындагы мәгълүматны янәшә куеп карасак, *карендәш* атамасының беренче очракта килен белән аның бертуганын белдерүен, ә кияүнең карендәше Баһаведдин Гали углы белән бертуганнар түгеллеген күрәбез: *Кыз тарафындан* ***карен-***

***дәше Зәйнеддин Сәйфеддин углы*** *вәли вәкил булды вә кияү тарафындан* ***карендәше Баһаведдин Гали углы*** *вәли вәкил булды* (Әшле); *Тобол губернасы шул ук өязе Әшле иленең* ***Олобикә Сәйфеддин кызыны*** *никахландырылды, яше 17 дә; шул ук илнең* ***Садыйк Рамазан углына****, яше 43 дә* (Әшле).

*Тугма карендәш* атамасы барлык текстларда да актив кулланыла: Комарау документларында *дугма карендәше* (т–д тәңгәллеге) варианты да очрый: *Кияү тарафындан атасы илән* ***дугма карендәше*** *Хәсән Гомәр мәрхүм углы вәли вәкил булды* (Комарау). Комарау китапларында *Кияү тарафындан* ***бертугма карендәше*** *Сәйфулла Дусмөхәммәд углы вәли вәкил булды* мисалында бертуган булуын аерып, *бертугма карендәш* атамасы кулланыла. Андый очрак Күкрәнде текстларында да урын ала: *Кияү тарафыдин* ***бертугма*** *Габдулла Ниятбакый вәли вәкил булды* (Комарау). Бер генә документта урын алган *атасының карендәше* мисалы да конкрет очракка басым ясый, ягъни атасының туганы икәнлеген ассызыклый: *Кыз тарафындан* ***атасының карендәше*** *Әбелкасыйм Хәбибулла углы вәли вәкил улды* (Әшле).

Әйтеп узганыбызча, каралган барлык документларда да *карендәш – кардәш* вариантларыннан *карендәш* очрагы гаять актив. Комарау текстларында *карендәш* атамасы кебек үк *тугма кардәш, кыз кардәшем* атамаларында *кардәш* сүзе килә һәм аерым гына да кулланыла: *Кыз тарафындан* ***кардәше*** *Ислам Кодунай углы вәкил булды вә кияү тарафындан* ***карендәше*** *Хөсәен Нәүрүз углы вәкил булды* (Комарау); *Мәзкур шартга* ***кыз кардәшем*** *Бибибостанның ризалыгы илә мән вәли вәкил булгучы Надир Мөхәммәдриза углы әлимза кылдум* (Комарау); *Кияү тарафындан* ***тугма кардәше*** *Габдерәшид Моратбакый углы вәкил булды* (Комарау).

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә *ага* сүзенә түбәндәге аңлатма китерелә: 1) яшь ягыннан сөйләүченең үзеннән олы булган ир туган, абый; 2) өлкән яшьтәге ир кеше; 3) сөйләүченең үзеннән олырак булган ир кешегә мөрәҗәгать итү сүзе; 4) өлкән, хөрмәтле кеше; аксакал [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, б. 56]. Аталган кешедән яшь буенча олы булган ир туганны без караган метрика кенәгәләрендә *тугма агасы, агасы, тугма ахы, ахы* һәм күп очракта *тугма карендәше* лексемалары белдерә. Алдагы мисалда кызның шаһиты *тугма агасы* дип китерелсә дә, әтиләре башка булганлыктан, бертуганнар дип әйтә алмыйбыз: *Кыз тарафындан* ***тугма агасы*** *Садыйк Исән углы вәли вәкил булды вә кияү тарафындан* ***тугма карендәш****е Тукдаган Габделбакый углы вәли вәкил булды Тубыл губернасы шул ук өязе Кундан иленең Нәзирә Ханнанҗар кызыны никахландылды, яше 19 да; шул ук өязе Ләчек иленең Тукдабай Габделбакый углына, яше 26 да (Күкрәнде). Ага* сүзе үзе генә дә документларда очрый: *Кияү тарафындан* ***агасы*** *һәм карендәше Корманғали Сәфәргали углы вәли вәкил булды* (Комарау).

*Ахы* лексемасы (*ахы* – гарәп алынмасы: أَخ – брат [Баранов, с. 31]) документларда ялгыз гына да кулланыла, *тугма ахы* варианты да бар.

Мисаллар: *Кияү тарафындан **тугма ахы** Нияз Аедмөхәммәд углы вәли вәкил булды* (Әшле); *Насбикә өчөн вәли вәкил **тугма ахы** Нигъмәтулла Мөхәммәдулла әлимза кылдым* (Күкрәнде).

Күкрәнде китапларындагы *Кияү тарафындан **ахы** Дустмөхәммәд Аидмөхәммәд углы вәли вәкил булды* мисалында, кияү Калмөхәммәд Аидмөхәммәд углы булганлыктан, Дустмөхәммәд Аидмөхәммәд углын һәм Калмөхәммәд Аидмөхәммәд углын бертуганнар дип фаразлыйбыз.

Бер документтан алынган әлеге ике мисалдагы *Кыз тарафындан **тугма ахы** Сәфәр Кадыйргали углы вәли вәкил булды* (Әшле); *Мәзкурә кыз карендәшем Зөлхия өчөн вәли вәкил **ахы** Сәфәр Кадыйргали углы әлимза кылдым* (Әшле) *тугма ахы, ахы* атамаларының бер туганлык мөнәсәбәтен атавы күренә. *Ахы* сүзе XVIII гасыр шагыйре Габделмәннан Мөслимов шигырьләрендә шулай ук *ир туганы* мәгънәсендә килә [XVIII гасыр татар әдәбияты, б. 130].

Әшле документларында бер урында гарәп алынмасы *гамм* очрады: عم – дядя (со стороны отца) [Баранов, с. 689]. Бу очракта никах документын тутыручы, мәгълүматны конкретрак бирү максатыннан, әлеге сүзгә мөрәҗәгать итә дип уйлыйбыз: *Кияү тарафындан **гамме** Баязид Гали углы вәли вәкил булды.*

XIX гасыр метрика кенәгәләрендә никах буенча туганлык терминнарыннан *ир, хатын, кияү, килен, кайне, кайнана, йизни* атамалары очрады. Мисаллардан күренгәнчә, алар бүгенге көндә дә татар әдәби телендә һәм сөйләшләрендә актив лексика составында.

Күкрәнде, Әшле, Комарау никах документларында – барысында да шаһитлар түбәндәгечә бирелә: *Кыз тарафындан тугма карендәше Этимгән Уразгали углы вәли вәкил булды вә кияү тарафындан тугма карендәше Баһаветдин Гали углы вәли вәкил булды* (Күкрәнде); *Кыз тарафындан әтекәсе Бикбулат Кубшан углы вәли вәкил булды вә кияү тарафындан карендәше Хафиз Кинҗә углы вәли вәкил булды* (Әшле); *Кыз тарафындан карендәше Сәйфулла Дусмөхәммәд углы вәли вәкил булды вә кияү тарафындан атасы Нийаз Йагкуб углы вәли вәкил булды* (Комарау). Мисаллардан күренгәнчә, никах укылачак кыз белән егетне *кыз* һәм *кияү* дип язалар, ягъни егетне кияү дип атасалар да, кызны килен дип күрсәтмиләр**.** Документларда *килен* сүзе ‘ир кешенең улының хатыны (каенатаның килене)’ төшенчәсендә кулланыла: *Мәзкур шартга **киленүм** Хөсниҗамалның ризалыгы илән мән вәли вәкил булгучы Сәфәр Әвнәк углы әлимза кылдум* (Комарау). Кияү сүзенең ‘өйләнеп йөргән егет’ мәгънәсеннән тыш, ‘кияүгә чыгучының кызының ире’ төшенчәсен белдереп килгән очракка да мисал бар: *Кыз тарафындан **кияве** Кодаш Билал мәрхүм углы вәли вәкил булды* (Комарау). Моның шулай икәнлеген алдагы текст ачыклый: *Мәзкур шартга мәзкурә каенанам Тәбиянең Сәфәргали кызының ризалыгы илән вә әмере илән мән **кияү** вәкил булгучы Кодаш Билал мәрхүм углы әлимза кылдум* (Комарау). Никах документларында бары тик кияү белән килennең яшьләрен күрсәткәндә (кайбер очракларда) *егет* атамасы урын ала: ***кыз** унйите йәшендә, **йегет** йегерме алты йәшендә* (Комарау).

*Ир – хатын* атамалары документларда хәзерге татар әдәби телендәге кулланылышта килә: *Корбанбакый Яңабай углы **хатыны** Янбикә Йумаш кызыны **иренең** әмерене инкяр кылыб, әҗнәбиләрнең өйләренә чыгыб йөрүдеге сәбәбле вә мәхәббәте йуклугындан халегъ улунган* (Әшле); *Тобол губернасы шул ук өязе Әшле иленең Балда Габдерәхим углы **хатуны** Мөслимә мулла Кадергали кызыны халегъ кылды, илле сумлук ат, илле сум акча бәрабәренә* (Әшле). *Тобол губернасы шул өйәзе Комарау иленең Җәләледдин Җәгъфәр углы **хатыны** Уразабикә Нәкыйб кызына талак вакыйг улынды* (Комарау). Талак текстында бер очракта *хатын* лексемасына өстәмә мәгълүмат китерелә: *Тобол губернасы шул өязе Ишәй иленең асдавнуй казак Сөйүҗбакый мәрхүм кызы Бибишәрифәгә шул ук өязенең Хан иленең зирагатьче Мөхәммәдәмин Мөхәммәдкәрим углы **никахда улан хатуны** Бибишәрифәгә үз ихтыяры илән үзе теләб җәмигъ хокук никахны мәзкур Бибишәрифә илән хазир гуаһлар хозурында бер талак баин илән талак кылдум.* Комарау текстларында талак документларында берничә урында *зәүҗ* (хатынның ире), *зәүҗә* (ирнең хатыны) атамалары кулланыла: *Хатун улан Фатыйма мәзкур **зәүҗенең** бер талак бәин илән талак кылмаклыгыны кабул әйләде.* Аларны вафат булганнарны теркәү кенәгәләрендә дә очратырга мөмкин: ***зәүҗ** Аллаяр, **зәүҗә** Туйбикә* (Әшле). Өйләнешүчеләрнең шаһитлары саналган графада *зәүҗәен,* ягъни ‘ир белән хатын’ атамасы килә: ***Зәүҗәйеннең** ризалыкларының шаһидләре* (Комарау).

*Каене – каенана* пары без тикшерә торган текстларда шулай ук очрады. «Каен» сүзе – татар телендә һәм күпчелек төрки телләрдә никах буенча туганлык төшенчәсен гомумиләштерә торган термин һәм ул «без конкретизирующих его значение слов передаёт в тюркских языках лишь идею родства по мужу и жене» [Рамазанова, с. 102]. Татар телендәге *каената, каенана, каенага, каениш, каенигәч* атамаларының беренче компоненты – *каен* сүзе. Безнең тарафтан каралган документларда *кайны, кайнана* терминнары кулланылган: *Мәзкур шартга мәзкурә **кайнанам** Тәбиянең Сәфәргали кызының ризалыгы илән вә әмере илән мән кияү вәкил булгучы Кодаш Билал мәрхүм углы әлимза кылдум* (Комарау); *Кыз тарафындан **кайне** Сәфәр Әвнәк углы вәли вәкил булды* (Комарау). Әлеге ике атама да «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә себер диалектларына сылтама белән урын алган: *кайным* себ. – каената. *Кайнысы, кәйнәсе үлеп киткән.* – төм.; *Кайныма әткә тибес пес* – тбл.; *Пы кайным үстергән пыйас* – твр. [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, б. 377]; *Кайнана* себ. – каенана. *Тәлил тә тартып утырадым кайнана абыс тип.* – брб. д. [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, б. 377].

*Йизни* термины Күкрәнде, Комарау документларында очрый: *Кыз тарафыдин **йизнәсе** йасаклы Гыйбаш Илйас углы вәли вәкил булды* (Күкрәнде); *Кыз тарафыдин **йизнәсе** Әхмәд Хуҗа углы вәли вәкил булды* (Күкрәнде); *Кыз тарафындан **йизнәсе** Нияз Этимгән углы вәли вәкил булды* (Комарау).

Шул рәвешле, туганнарны, никах, талак һәм вафатларны теркәп барган Күкрәнде, Әшле һәм Комарау юрталары текстлары шул чорның бу төр документларына куелган таләпләргә туры китерелеп төзелгәннәр һәм аларда күптөрле туганлык терминнары урын алган. Утыздан артык туганлык атамасының зур күпчелеген гомумтөрки сүзләр тәшкил итә, берничә гарәп алынмасы очрый. Метрика кенәгәләрендә кулланылган бу сүзләр татар әдәби телендә һәм себер диалектларында бүгенге көндә дә актив лексика составында.

**Әдәбият**


*Баранов Х.К.* Арабско-русский словарь. 3-е изд., стер. М., 1958. 186 с.

Габдулла Тукай: Шигърият теле : Сүзлек = Габдулла Тукай: Язык поэзии: Словарь: ике китапта. 1 нче китап / К.Р. Галиуллин, Р.Н. Кәримуллина. Казан: Мәгариф, 2009. 503 б.

*Покровская Л.А.* Термины родства в тюркских языках // Историческое развитие лексики тюркских языков. М.: Изд-во АН СССР, 1961. С. 11–81.

*Рамазанова Д.Б.* Термины родства и свойства в татарском языке: в 2 кн. Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. 190 с.

Старотатарская деловая письменность XVIII в. Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 171 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 6 томда. Тулыл. һәм төзәт. 2 басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. 751 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. 643 б.

XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия. Казан: Дом печати, 2006. 363 б.

*Фәйзуллина Г.Ч., Кадыйрова Э.Х.* Тарихи-лингвистик чыганак буларак XIX гасыр һәм XX гасыр башы метрика язмалары // TATARICA. 2021. № 2 (16). С. 7–24.

*Хисамова Ф.М.* XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре Казан: Казан ун-ты нәшр., 1981. 162 б.



*Исследование выполнено при финансовой поддержке РФФИ, проект № 20-412-720008 «Метрические записи XIX – начала XX вв. о тобольских и тюменских бухарцах как историко-лингвистический источник»*

*Тикшерену «Метрические записи XIX – начала XX вв. о тобольских и тюменских бухарцах как историко-лингвистический источник» исемле 20-412-720008 фәнни проекты кысаларында РФФИ финанс ярдәме белән башкарылды*



***Кадирова Энҗе Хәнәфи кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Фәйзуллина Гүзәл Чахвар кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, Төмән дәүләт университетының башлангыч һәм мәктәпкәчә белем бирү теориясе һәм методикасы кафедрасы профессоры*

УДК 398.8

***К.М. Миңнуллин,***
***И.И. Сабитова***

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ БОРЫНГЫ ҖЫРЛАРЫНДА СОМАТИЗМНАР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ФУНКЦИЯСЕ

В статье рассматриваются вопросы функционирования языковых единиц в татарском песенном творчестве. Выявлены группы соматизмов с учётом активности их употребления в татарских старинных лирических песнях, исследованы переносные, контекстуальные значения отдельных названий частей тела. Особое внимание уделено функциям, роли соматизмов в рассматриваемых текстах. По мнению авторов, основной функцией соматических единиц в татарских лирических песнях является передача эмоций и чувств. Отмечается универсальность лексемы «баш» ‘голова’ в трансляции эмоционально-чувственного мира человека.

**Ключевые слова:** соматизм, лингвофольклористика, старинные лирические песни, татарский язык.

The article deals with the functioning of language units in the Tatar song art. Groups of somatisms are identified, taking into account the activity of their use in ancient Tatar lyric songs, the figurative, contextual meanings of individual names of body parts are investigated. Particular attention is paid to the functions, the role of somatisms in the studied texts. According to the authors, the main function of somatic units in Tatar lyrical songs is the transmission of emotions and feelings. The universality of the lexeme «bash» ‘head’ in the translation of the emotional and sensory world of a person is noted.

**Keywords:** somatism, linguo-folkloristics, ancient lyrical songs, Tatar language.

Билгеле булганча, татар лингвофольклористикасы – хәзерге лингвистиканың актив үсештәге өлкәләреннән берсе. Аның тикшерү объекты халык иҗаты текстлары булса, төп бурычы – фольклор телен өйрәнү. Бу эш ике юнәлештә алып барыла: фольклор әсәрләрен төрле яклап өйрәнү (халык авыз иҗаты әсәрләренең лексик составы ачыклана, сүзләрнең семантик, морфологик характеристикалары билгеләнә) һәм сүзлекләр төзү [Галиуллин, 2018]. Әлеге өлкәдә паремияләр (мәкаль-әйтемнәр, канатлы әйтелмәләр) шактый тирән өйрәнелгән.

К. Миңнуллинның татар җырлары текстларында тупланган сүз сәнгате хәзинәсен анализлаган «Һәр чорның үз җыры» хезмәте (2003) татар лингвофольклористикасында тәүге тикшеренүләрдән санала. Автор, җыр текстларының лексик составы, нигездә, татар теленең төп сүзлек фондын чагылдырса да, статистик исәпләүләргә таянып, җырларның төрле төркемнәрендә сүз сайланышы һәм кулланылыш ешлыгының бердәй булмавына игътибар итә [Миңнуллин,

2003, б. 368]. Образлылык тудыру, сүз-сурәт ясау һәм җырларның сәнгать үзенчәлекләре системасын булдыруда аеруча зур роль уйнаган сүзләрнең кулланылыш ешлыгы да югарырак икәнлеген ачыклый [Миңнуллин, 2003, б. 369]. Тикшерүче җырларның лексик фондына тематик яктан зур төрлелелек хас булуын ассызыклый, җыр текстларындагы сүзләрне берничә лексик-семантик төркемгә (кеше, кардәшлек мөнәсәбәтләре һәм рухи дөньяга караган лексика, тормыш-көнкүреш белән бәйле лексика, табигать, туган-үскән җир һәм мохит белән бәйле лексика) бүлеп өйрәнә. Авторның әлеге төркемнәрне берничә төркемчәгә аеруы да игътибарга лаек (туганлыкны, кардәшлекне белдерә торган сүзләр, кеше әгъзаларын белдерә торган сүзләр, кием-салым, бизәнү әйберләре атамалары, аш-су белән бәйле сүзләр, үсемлек һәм хайван атамалары һ.б.) [Миңнуллин, 2003, б. 280–360].

Татар теленең соматик лексикасы төрле яклап тикшерелә: этимологиясе, семантикасы, диалектлардагы соматизмнар өйрәнелә [Рамазанова, 2013], сүзьясалыш потенциалы ачыклана [Сабитова, 2015; Ямалетдинова, 2007]. Соматизмнарның дастаннарда һәм әкиятләрдә кулланылыш үзенчәлекләрен күрсәткән хезмәтләр дә бар [Сабитова, 2019].

Шул ук вакытта фольклор текстларындагы соматизмнарның мәгънәләрен, алардагы семантик үзгәрешләрне, синтагматик һәм парадигматик бәйләнешләрнең үзенчәлекләрен билгеләп, җентекләбрәк өйрәнү актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала.

Тәкъдим ителә торган мәкаләдә татар халкының борынгы лирик җырлары текстларында соматизмнарның кулланылышы тикшерелә, аерым сүзләрнең мәгънәләре тулыландырыла, халкыбызның этник портретына кайбер штрихлар ачыклана.

Фәнни тикшерену өчен соматик берәмлекләр, тоташ сайлап алу ысулы белән, 1988 елда басылып чыккан «Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар» җыентыгыннан тупланды [Татар халык..., 1988]. Лирик җырларның асылында һәркем күңеленә хуш килгән, һәр кешегә якын эчке кичерешләр, уйланулар, хис-тойгылар ята. Әлеге төркемгә йолаларга һәм тарихи вакыйгаларга мөнәсәбәте булмаган җырлар керә.

Җыентыкта теркәлгән 585 лирик җырның 406 сы борынгы лирик җырларга карый. Алар 8 төркемгә («Туган ил, туган як», «Социаль тормыш, хәсрәтле дөнья», «Чит җирләрдә бәхет эзләүчеләр моңы», «Гомер агышы, яшәү кадере», «Хатын-кыз язмышы», «Мәхәббәт җырлары», «Дуслык, туганлык, мәҗлес җырлары», «Шаян җырлар») бүленгән [Татар халык ..., 1988, б. 120–334].

Соматизмнар – җыр текстларында кулланыла торган иң популяр лексик берәмлекләр. Бу – җырның төп сурәтләү объекты кеше, аның эчке кичерешләре, кыяфәте, килеш-килбәте, тышкы матурлыгына бәйле булу белән аңлатыла. Татар халкының борынгы лирик җырларында сомонимнардан *баш*, *бит* / *йөз* / *чырай* / *чәһрә*, *ирен*, *авыз* /

*агыз / ауз*, *маңгай*, *түбә*, *кул*, *аяк*, *бармак*, *эч / корсак*, *бил*, *арка / сырт*, *күкрәк / изү*, *терсәк*, *беләк*, *муен*, *тез*, *иң*, *гәүдә*, *тән*, *буй*; сенсионимнардан *күз*, *колак*, *тел*, *чәч/сач*, *керфек*, *каш*, *сакал*, *мыек*, *толым*, *тырнак*; остеонимнардан *кабырга*, *теш / деш, сөяк*; планхнонимнардан *йөрәк*; агнионимнардан *кан* лексемалары, шулай ук кеше әгъзаларының авырту хәлендә булуы, физик төзелеше белән бәйле лексикадан *шеш, сызлавык* һәм *миң* сүзләре теркәлгән.

Анализ күрсәткәнчә, борынгы лирик җырлар текстында очраган соматизмнарны, куллану ешлыгына карап, өч төркемгә бүләргә мөмкин: куллану ешлыгы югары (*йөрәк*, *күз*, *баш*, *йөз*, *эч*), куллану ешлыгы уртача (*күкрәк*, *кул / әл*), куллану ешлыгы түбән (*колак*, *тел*, *чәч / сач*, *керфек*, *каш*, *авыз / агыз/ ауз*, *маңгай*, *муен*, *арка* һ.б.) булган берәмлекләр. Рус лирик җырларында *баш, йөрәк, кул, чәч* исемнәренең шулай ук югары ешлыклы булуы [Ван, 2019, б. 142] – безнеңчә, төрле культураларда кешенең рухи дөньясын, кичерешләрен, килеш-килбәтен тасвирлауда охшашлык булуны күрсәтә торган факт.

Кеше әгъзаларын белдерә торган сүзләр тарихи яктан бик борынгы чорларга карый. Шуңа күрә дә борынгы лирик җырларда кайбер лексемаларның фонетик вариантлары да очрый: *чәч / сач, авыз / агыз / ауз, теш / деш*. Шулай ук хәзерге вакытта бары тик язма әдәби истәлекләрдә генә сакланып калган *әл* архаизмы «Кыз балалар, бичаралар» җырында, ә искергән *чәһрә* сүзе «Чәһри асыл кыз бала» җырында теркәлгән [Татар халык ..., 1988, б. 291].

Телнең үсеш-үзгәреше барышында соматизмнарның семантикасы киңәйгән, күптөрле яңа мәгънәләре һәм мәгънә төсмерләре, күчерелмә мәгънәләре барлыкка килгән. Мәсәлән, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *баш* сомонимының – 30 [Татар теленең..., 2020, т. 1, б. 459–461], *күз* сенсонимының – 22 [Татар теленең..., 2017, т. 3, б. 528–529], *кул* сомонимының – 19 [Татар теленең ..., 2017, т. 3, б. 481–482], *эч* сомонимының – 9 [Татар теленең..., 1981, т. 3, б. 558], *йөрәк* планхнонимының – 9 [Татар теленең..., 2020, т. 2, б. 770], *йөз* сомонимының – 8 [Татар теленең..., 2020, т. 2, б. 760–761], *күкрәк* сомонимының 8 [Татар теленең..., 2017, т. 3, б. 561–562] мәгънәсе күрсәтелгән.

Әлеге сүзләр, кагыйдә буларак, туры мәгънәдә кешенең тышкы кыяфәтен сурәтли (мәсәлән, «Аччы, туташ, ишегеңне» җырында *күз, каш, керфек, ирен, чәч, теш, бармак, тырнак, йөз / бит, күкрәк, буй* лексемалары [Татар халык..., 1988, б. 213]), шулай ук адресатның үзенчәлекле күзаллавын (*Ак пирчәткә – кызлар бүләге, Кызлар* ***аузы*** *– йөзем җиләге;* ***Авызың*** *да уймак,* ***тешең*** *энҗе,* ***Телең*** *дә оҗмах ачкычы*; *Сикертмә* ***каш****, бөдрә* ***чәч****, Үпкәләмә үпмәгәч!;* ***Буй*** *гынаең зифа,* ***йөзең*** *күркәм, Яман күздән, җаныем, саклан син; Ярны ла сөйсәң, сөй матурын Ак* ***сөякле****, кара* ***кашлысын;*** *Ике* ***бите*** *кызыл алма, Кызылырак алмадан да; И алтын* ***чәч****, гәүһәр* ***баш****, Күз өстендә кыйгач* ***каш;*** ***Кашларың*** *кыйгач,* ***йөзләрең*** *кояш, Күңлем*

*яктыра, күрсәм, җанашым; Кара* ***кашым****, йолдызым, Энҗе* ***тешем****, гөл* ***йөзем****, Ак* ***чыраең****, кыйгач* ***кашың****, күреп туймыйдыр күзем* һ.б.) чагылдыра.

Шул ук вакытта лирик җырларда соматизмнар кешене тискәре яктан бәяли торган сүзләр белән бергә сирәк кулланыла: *Таң йолдызы калкып бара, Син егетнең* ***йөзе*** *кара*.

Гомумән, лирик җырлар текстларында әгъза атамаларының күчерелмә мәгънәдә кулланылуы күзәтелә. Мәсәлән, *күкрәк* атамасы «кичерешләрнең, хисләрнең һ.б.ның шартлы билгесе; күңел» мәгънәсендә бирелә: *Бакмагызчы минем шат йөземә, и дусларым,* ***Күкрәкләрдә*** *хәсрәт, күздә яшь; Чит җирләрдә йөргән егетләрнең* ***Күкрәкләре*** *дәртле, күзе яшь; Нурлы гына йөзем бик саргайды* ***Күкрәкләрем*** *тулы сагышка.* Әлеге лексеманың татар теле сүзлекләрендә теркәлмәгән «йөрәк» мәгънәсендә кулланылган очрагы да бар: *Күкрәп кенә типкән* ***күкрәгемдә*** *Ачы хәсрәт катулары бар*. Җыр текстларында *эч* лексемасы да «йөрәк, күңел» мәгънәсендә еш очрый: *Мин бара алмыйм яңгыр яуганга, Мин җырлыймын* ***эчем*** *янганга; Бәхетләрем булмаганга* ***Эчем*** *сагыш, күзем яшь;* ***Эчкенәем*** *аркама ябышкан Кайгы-хәсрәт белән сагыштан; Ата балалары түзә икән* ***Эчкенәе*** *тулы сагышка; Карурман кошлары,* ***Эчләремнең*** *пошканы* һ.б.

*Кул* атамасының «тиң, лаеклы, иш, пар» мәгънәсе *Бәдриҗамал безгә* ***кул*** *түгел, Йөзгә матур, буйга зур түгел* контекстында очрый. Шул ук сомоним «иялек, хуҗа булу» мәгънәсенә дә ия: *Тарырсыңмы икән* ***кулларыма****, Зөһрәдәй матур җан сөйгән?; Кадерле лә иде бу башкаем Әткәй, әнкәй кулында чакта.*

Билгеле булганча, фольклор текстына эләгеп, сүз яңа мәгънә төсмерләрен ала, ягъни сүзнең семантикасы киңәя. Мәсәлән, *Ул чын җимешләр гел бетмәсен,* ***Башыгыздан*** *дәүләт китмәсен* контекстында *баш* лексемасы яңа мәгънәдә кулланыла: «карамагында (булу)». Әлеге мәгънә дә татар теле сүзлекләрендә теркәлмәгән. Текстларга ясаган анализ *баш* соматизмы кеше тәне әгъзаларының иң мөһимнәреннән берсе буларак кабул ителүен күрсәтә. Ул тормыш-яшәеш, гомер, сәламәтлек символы буларак күзаллана: *Кара кашым, асыл ташым, Исән үк булсын, кайтыр ла* ***башым****; Маллар кыйбат түгел,* ***баш*** *кыйбат; Исәплимен дә мин, әй, еглыймын, Харап булды, әнкәй, яшь* ***башым****; Кар сай булса, читләрдин чабарбыз,* ***Баш*** *сау булса, малларын табарбыз. Баш* соматизмы, **газиз, кайгылы, моңлы, ялгыз, бәхетле** сыйфатлары белән бергә килеп, кешенең эчке дөньясын ачып бирергә ярдәм итә: *Илемдә үскән егет идем, Сәфәр китте* ***газиз башларым****; Байкал күле тозлы икән, Бу* ***баш*** *нигә* ***моңлы*** *икән?; Кисмәдем каен башын Шуңа* ***кайгылы башым****; Чит илләрдә йөри* ***ялгыз башым*** *Адашып ла калган торнадай; Кайда гына барсаң, бәхетең булса,* ***Бәхетле*** *генә* ***башлар*** *хур булмас*. Җан-тән, шәхес» мәгънәсендә дә кулланыла: *Синең кара кашың өчен ашыйлар бит* ***башымны****; Кызыл мәрҗән йөзек кашында, кыз кайгысы егет* ***башында***.

Лирик җырлардагы тән әгъзалары атамаларының характерлы үзенчәлеге – лирик герой кичерешләрен тагын да тирәнрәк сурәтләү максатыннан, еш кына аларның иркәләү-кечерәйтү аффикслары белән кулланылуы: *йөрәккәем*, *йөзкәем*, *башкаем*, *күзкәйләрем*.

*Йөрәк, күз, йөз, каш* соматизмнары исем, сыйфат белән ярашып, лирик геройның эчке дөньясы, аның адресатка мөнәсәбәте турында мәгълүматны үз эченә алган үзенчәлекле код ролен дә башкаралар: *йөрәк парәм*, *йөрәк маем*, *гөл йөзем*, *ике күзем*, *кара күзем*, *зәңгәр күзем*, *кара кашым*, *энҗе тешем, күз өскәйләремдә кашым, күз нурым, алма битем, нурлы йөзем* һ.б.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, лирик җырлар текстларында соматизмнарның төп функциясе – лирик геройның эмоциональ халәтен сурәтләү. Тән әгъзалары исемнәре мәхәббәт хисләрен аеруча аһәңле белдерергә ярдәм итә. Бу бигрәк тә *йөрәк*, *күз*, *йөз*, *эч*, *каш*, *чәч*, *баш* соматизмнарына хас: *Шәкерт мәдрәсәгә йөридер, Күрсәм, **йөрәк** маем эридер*; *Алып эчтем суның салкынын, Ул да басмый **йөрәгем** ялкынын*; *Су салкынын балыклар сизәләр, Сөйгән ярлар **йөрәкне** өзәләр*; *Карасам, **күземнең** нуры кала, Җаныем киткән юлларга*; ***Күзем** йомсам, **күз** алдымда Хафизәләм иркәм гәүдәсе*; *Син җаныемны уйлый-уйлый, **Йөзләремдә** нурлар калмады*; ***Эчем** ялкын, тышым салкын, Мәрфуга, Мәрфуга, аппагым, саргайганны кем белсен*; *Сикерткәләп **кашларыңны**, Әйләндердең **башларымны***; *Карарга да кыймыйм йөзләреңә, **Күз алмакай** гына эридер; Кемнәрнең ярларын кемнәр сөймәс, **Чәчкәйләре чәчкә** бәйләнгәч лә; Барма, егет, ят илләргә, **Чәчем** сиңа бәйләнә; Насыйп булыр микән, җаным, безгә Бер ястыкка **башлар** куярга; Гыйшык хәле бик яман хәл, Май кундырмый, бәгърем, **йөрәккә*** һ.б.

*Йөрәк*, *күз*, *баш*, *йөз*, *эч* лексемалары татар лирик җырларында сагыш, сагыну, юксыну, моң, кайгы, хәсрәт, ялгызлык хисләрен тапшыру функциясен дә үти. Аны берничә төркемгә аерып карарга мөмкин:

1) туган ил, туган җирне сагыну: *Безнең дә генә илләр кай тарафта, Алмас та гына идем **күземне***; *Туган җирем исемә төшсә, **Башымнан** һушым китә; **Эченәкәем** уттай, әй, кабына, Туган илкәемне сагынып; Кычкырмачы, кәккүк, син кычкырма, Эч**кенәемне** минем пошырма! Кәккүгем, Чит җирләрдә үтә яшьлегем! Туган җирем, туганнарым сагынам, --- Уйламаган идем сагынулардан Саргаер дип нурлы **йөзләрем***);

2) туганнарны, дусларны сагыну: *Якташым юк, юк туганым, **Йөрәккәем** көн дә өзелә; Сезнең дә авыл, безнең авыл Аралары алтмыш чакырым; Алтмыш кына түгел, йөз егерме, дусларым, Сезне күрергә **күзем** тилмерде; Без китәрбез инде сез калырсыз, Ни эшләрбез **йөрәкләр** янганда?*);

3) ата-ананы сагыну: *Үлмәсә егет үлми икән **эче** тулы сагышка, И анам, бик сагынам, калды миннән аерылып; Ак күгәрчен булып*

*төшемә кирә Әнкәемнең* ***күкрәк*** *сөтләре; Шомырттан кара* ***чәчемне*** *майлыймын да тарыймын, И анам, бик сагынам, калдың миннән аерылып*;

4) баланы сагыну: *Бәбекәем өчен елап Күрмәс булды* ***күзләрем;*** *Шул балалар дия-дия, Карлыган* ***күзем*** *бетердем*;

5) үткән гомерне сагыну: *Моңлана ла күңел,* ***күз*** *яшәрә, Үткән гомерләрне, әй, уйласам*;

6) сөйгән ярларны сагыну: *Туган җирләр калды еракта, Сөйгән ярлар тора* ***йөрәктә***; *Син җаныемны уйлый-уйлый,* ***Йөзләремдә*** *нурлар калмады*; *Карасам* ***күземнең*** *нуры кала Җаныем киткән юлларга; Нидән бу матурның* ***йөзе*** *сары? Янында йөрергә, абау бәгърем, яры юк; Якын араларда күршәлмәсәк,* ***Йөздә*** *сары, күздә яшь булыр; Үзең дә генә анда булган белән, Син китмисең минем дә* ***йөрәктән;*** *Я кайтырбыз, я кайтмабыз, тулган аем,* ***йөрәк*** *маем Күрешергә туган илгә; Ике* ***күзем*** *юлда була, Килеп китсәң ни була?; Аерылдым гүзәлемдин Шуңа* ***йөрәкләрем*** *яна; Күзем йомсам, күз алдымда Хафизәләм иркәм* ***гәүдәсе***;

7) ялгызлыктан сагышлану: *Ялгыз гына* ***башым****, юк юлдашым, дусларым, ишләрем, Ничек баш кынаемны кичерәем?; Карурман кошлары,* ***Эчләрем*** *пошканы, Ялгызым ят илдә йөримен*;

8) кайгы-хәсрәт, борчу-уй, сагыштан рухи сызлану кичерү: *Ачы хәсрәт, төрле сагыш – Бар да безнең* ***башларда;*** *Нурлы* ***йөзләрне*** *саргайта Бу дөньяның уйлары; Төрле хәсрәт-уйны күп уйласам, Дивана ла була бу* ***башым;*** *Кайгы да хәсрәт яман икән, Май кундырмый икән* ***йөрәккә;*** *Үзегез рәхәтләрдә калдыгыз, Безнең* ***башны*** *утларга салдыгыз;* ***Эч*** *кенәем аркама ябышкан Кайгы-хәсрәт белән сагыштан; Әле дә хәсрәтләрем юк кебек, Яна* ***йөрәккәйләрем*** *ут кебек; Нурлы гына* ***йөзем*** *ник саргайды* ***Күкрәкләрем*** *тулы сагышка; Кеше хәлләрен лә кеше белми,* ***Эчкәйләрем*** *яна төтенсез; Бу да дөньяларның хәсрәтеннән Ике* ***күз*** *генәмне кан ишкән.*

Лингвистлар фикеренчә, *сагыш* «кешенең психоэмоциональ өлкәсенең мөһим өлеше булып тора». «Сагыш» концепциясенең иң еш кулланылган мәгънәләренең берсе – ностальгия: туган җирне сагыну хисе, җирсү. Бу, әлбәттә, татарларның таралып яшәве белән дә аңлатыла [Василова, 2006, б. 10].

*Баш, күкрәк, гәүдә, кул, йөрәк, муен* соматизмнары борынгы лирик җырларда эш авырлыгы белән ассоциацияләнә торган халәтләрне тасвирлау функциясен башкара, чөнки физик эш чыдамлылык, көч, билгеле бер күнекмәләр таләп итә: *Маллар эзләп читтә йөри торгач, Каннар савып бетте* ***йөрәккә;*** *Фани дөнья малы өчен Йөрәккә утлар каба; Бай кул астында хезмәт итү* ***Йөрәктәге*** *майны эретәдер;* ***Муен*** *тамырларым корып бетте, Бер минут та рәхәт тормадым, Идел камышы, бурлак сагышы; Нindәй нужаларга дучар булмай Ялчы булган мескен ир* ***башы;*** *Аталардан бала яшьли калса,* ***Күкрәк*** *көче белән мал табар; Чит илләрдә йөргән егетләрнең Иленә кайта коры* ***гәүдәсе;*** *Илаһи бирмәгән бәхетләрне Тотып алып булмый*

***кул*** *белән; Кече яшьтән бирле авыр хезмәт,* ***Баштан*** *акылларымны җибәрә* *һ.б.*

*Кул, баш, күз* кебек кайбер атамалар ирексездән сөймәгән кешегә кияүгә китәсе кызның ачы хәсрәтен дә чагылдыра: *Ят* ***кулына*** *биргән көннән, әнкәй, Бетте сөйгән кызың ардагы*; *Ардакларда торган газиз балаң Хәзер* ***күз*** *яшь түгә аулакта; Бирмәдең, әтием, үз тиңемә, Бирдең картка, адәм кименә. Әтием,* ***башымны*** *бәйләдең, Сөйгән ярымнан җәллэдең.*

Борынгы лирик җырларда яңа гаиләдә яшәүнең авырлыгы *йөз, баш, маңгай* лексемалары ярдәмендә күрсәтелә: *Усал каениш киленен кага, анакаем,* ***Йөзенә*** *сары суксын дип*; *Кадерле лә иде бу* ***башкаем*** *Әткәй, әнкәй кулында чакта;* ***Маңгай*** *тирең сибеп эшләсәң дә, Һич ярап булмый ятларга; Бай да тормышлар кешене картайта, кырыс кайнишләр* ***йөзне*** *саргайта*.

Гомумән, соматизмнар, җыр текстларында еш кулланылып, конкрет эмоцияләрне, хис-тойгыларны сурәтләү функциясен башкара. Әлеге төркемгә караган лексика мәхәббәт хисләрен, тойгы-кичерешләрне тасвирлауда аеруча актив. Геройның төрле хис-эмоцияләрен гәүдәләндерүдә *баш* сомонимы универсаль булып тора.

**Әдәбият**

*Ван Х.* Кодовая функция соматизмов в русской лирической песне // Вестник Томского государственного педагогического университета (Tomsk State Pedagogical Universitu Bulletin), 2019. Вып. 4 (201). С. 138–149.

*Василова А.Ш.* Лингвокультурный концепт «сагыш» (тоска) в татарской языковой картине мира: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2006. 22 с.

*Галиуллин К.Р.* Татар фольклоры теле: мәкальләр, канатлы әйтелмәләр, җор сүзләр һәм әйтемнәр: сүзлек. Казан: ТӘһСИ, 2018. 588 б.

*Миңнуллин К.М.* Һәр чорның үз җыры. Казан: Мәгариф, 2003. 400 б.

*Рамазанова Д.Б.* Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика. Казан, 2013. 364 б.

*Сабитова И.И.* Словообразовательный словарь татарского языка: лексика тематической группы «Человек». Казань: ИЯЛИ АН РТ, 2015. 160 с.

*Сабитова И.И.* Татар телендә тән әгъзалары атамаларының халык авыз иҗатындагы синонимнары (дастаннар мисалында) // Фәнни Татарстан, 2019. № 2. Б. 14–18.

*Сабитова И.И.* Соматизмы в сказках татар Добруджа и их параллели в татарском языке // Ученые записки крымского инженерно-педагогического университета. Серия: филология, история. № 3–4. Симферополь: РИО КИПУ имени Февзи Якубова, 2019. С. 26–30.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 6 томда. 1 т. (А – В). Тулыл. һәм төзәт. 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. 751 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 6 томда. 2 т. (Г – Й). Тулыл. һәм төзәт. 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. 783 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: III том: К. Казан: ТӘһСИ, 2017. 744 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. III т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 831 б.

Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 488 б.

*Ямалетдинова А.М., Латыпова И.А.* Тематический русско-татарский словообразовательный словарь (На материале тематической группы «Человек. Части человеческого тела (организма)»). Туймазы, 2007. 119 с.

***Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать*
*институты директоры*

***Сабитова Илһамия Исламетдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел,*
*әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81´367.626

***Ф.Ф. Гыйлемшин***

# ТӘРҖЕМӘ ӘСӘРЛӘРДӘ АЛМАШЛЫКЛАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ
## («Мең дә бер кичә», «Тутыйнамә», «Кәлилә вә Димнә», «Кырык вәзир кыйссасы» һәм «Әбүгалисина кыйссасы» әсәрләре нигезендә)

Данная статья посвящена анализу местоимений, использованных в татарских произведениях, переведенных во второй половине XIX века с османо-турецкого и арабского языков. Объектом нашего исследования выступают тексты, которые оказали серьезное влияние на формирование норм современного татарского литературного языка. В текстах местоимения представлены тюрко-татарскими лексемами и отличаются многозначностью. В рамках одного произведения используются лексемы народно-разговорного и старотатарского письменного языка, тем самым демонстрируются особенности становления современного татарского литературного языка. В результате анализа функциональных особенностей местоимений выяснилось, что авторы оперировали широким спектром семантики местоимений, распространенной в татарском разговорном языке.

**Ключевые слова:** местоимение, татарский язык, значение, вариант, разговорный язык, текст, лексема.

This article is devoted to the analysis of pronouns used in Tatar works translated from Ottoman Turkish and Arabic in the second half of the 19th century. The object of our study is the texts that have had a serious impact on the formation of the norms of the modern Tatar literary language. In the texts, pronouns are represented by Turkic-Tatar lexemes and are distinguished by their ambiguity. Within the framework of one work, lexemes of the folk colloquial and Old Tatar written language are used, thereby demonstrating the features of the formation of the modern Tatar literary language. As a result of the analysis of the functional features of pronouns, it turned out that the authors operated with a wide range of semantics of pronouns common in the Tatar spoken language.

**Keywords:** pronoun, Tatar language, meaning, variant, spoken language, text, lexeme.

XIX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты Көнчыгыш әдәбияты ядкярләре белән баетыла башлый. Фатих Хәлиди татар теленә мәшһүр шәрык экиятләре җыентыгын – «Мең дә бер кичә»не тәрҗемә итә, Габделгалләм Фәезханов «Тутыйнамә» һәм «Кәлилә вә Димнә» әсәрләрен татарчалаштыра, Каюм Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы», «Әбүгалисина кыйссасы» һ.б. татар телендә дөнья күрә.

Әлеге әдәби әсәрләр безнең фәнни тикшерү объекты булып тора да. Аларның теле катнаш форматта язылган, анда халык сөйләме

һәм язма әдәби тел формалары үрелеп бара. Хикәяләү характерында булганлыктан, бу әсәрләрдә төрле хәлләр тасвирлана. Тәрҗемәчеләр текстта кабатлаулардан качарга омтылып, алмашлыкларның киң спектрын кулланганнар.

Безнең тикшеренүебезнең максаты – югарыда саналган әсәрләрдә зат һәм сорау алмашлыкларының кулланыш үзенчәлекләрен ачыклау. Текстларда зат алмашлыклары актив чагылыш тапкан һәм алар фонетик вариативлыклары белән аерылып торалар.

Анализлана торган текстларда I зат берлек сан алмашлыгы *bän*, *män* һәм *min* формалары белән белдерелә. Бер әсәр телендә ике яки өч форманы параллель куллану язучының халык сөйләм теленә иң якын форманы эзләү омтылышы белән аңлатыла. «Мең дә бер кичә» әкиятләренең татарча тәрҗемә текстларында *bän* һәм *män* шәкелләренең параллель кулланылышы күзәтелә: *balalar öčen män küb qajүyda ...* [Әлҗилдү сәдисү, б. 4] ‘Мин балалар өчен бик борчылам...’; *äfändem, bän any niček tabyb kiteräjem*? [Әлҗилдү сәдисү, б. 6] ‘Әфәндем, мин аны ничек табып китерә алам соң?’; *bän ber dä awaz qylүanym juq...* [Әлҗилдү сәдисү, б. 6] ‘Мин бер сүз дә әйткәнем юк...’.

«Кырык вәзир», «Кәлилә һәм Димнә» һәм «Әбүгалисина кыйссасы» әсәрләрендә *män* алмашлыгына өстенлек бирелә: *män ğen tügelder* [Әбүгалисина, б. 43] ‘Мин җен түгелмен...’ *män bulmasam mämläkät sineŋ qulyŋdan moŋarčy kitkän bulyr ide* [Кырык вәзир, б. 68] ‘Әгәр мин булмасам, син күптән инде патшалыгыңны югалткан булыр идең’; *män säneŋ ğeneseŋdän bula toryb, mäŋa bu tozaqny beldermädeŋ …* [Тутыйнамә, б. 10] ‘Мин синең туганың була торып, син мине бу тозак турында кисәтмәдең...’.

Мәгълүм булганча, башлангыч [b] формасы иске татар әдәби телендә XIX гасырга кадәр киң кулланылган. Башлангыч [m] һәм [b] формалы зат алмашлыкларын куллану XIII–XIV гасырлардагы төрки телле әсәрләрдә дә күзәтелә. «Тутыйнамә» китабында бу максат өчен бары тик *min* шәкеле генә кулланыла: *min däxi šulaj qotylyb kitärmen* [13: 83] ‘Мин шул рәвешле котыла алырмын ’; *mine satyb alasyŋ da oluү fajdalarүa irešäseŋ* [13: 5] ‘Мине сатып алырсың да зур табышларга ирешерсең; *saba jile, xäbäreŋ , barmy minem jöräk ğanymdan ber närsä kiterdeŋme?* [13: 7] ‘Иртәнге җил, сөйгәнемнән миңа хәбәр китердеңме?’ Югарыдагы мисалларда анализлана торган әсәрләр телендә традицион язма телгә хас вариантлар белән беррәттән, халык-сөйләм теленә караган I зат берлек сан формасындагы min ‘мин’ зат алмашлыгының активлыгы көчәю күзәтелә.

Әсәр текстларында I зат күплек сан формасындагы *bez* ‘без’ алмашлыгы үзләрен сөйләүче дип санаган затлар төркемен билгеләү өчен кулланыла: *bez qačanүa čaqly bu tar ojamyzda jabylyb toryrmyz* [Тутыйнамә, б, 7] ‘Кайчанга кадәр без тар оябызда бикләнеп утырырбыз?’; *bezdâ tuj baradyr* [Әлҗилдү хәмисү, б, 191] ‘Бездә туй бара’; *bez šulaj idärmez...* [Кырык вәзир, б. 23] ‘Без шулай итәрбез...’; *šäjäd bezlär öštenlek tabarmyz* [Кырык вәзир, б. 26] ‘Бәлкем, без (аларны)

җиңәрбез'; *bez baryb (...) kilermez* [Әлҗилдү рәбигу, б. 44] 'Без барып килербез';

Әсәр текстларында II зат берлек сан формасындагы *sin* / *sän* 'син' алмашлыгы әңгәмәдәшкә мөрәҗәгать итү өчен кулланыла. «Мең дә бер кичә» әкиятләре җыентыгында бу алмашлыкның ике формасы да параллель кулланыла: *sin xörmä ašab, tösen atar irkän...* [Әлф ләйлә вә ләйлә, б. 13] 'Син хөрмә ашап, төшләрен җиргә ташлыйсың икән...'; *säne häläk idäčäkem...* [Әлф ләйлә вә ләйлә, б. 14] 'Мин сине һәлак итәчәкмен'.

«Кәлилә вә Димнә», «Кырык вәзир» һәм «Әбүгалисина кыйссасы» әсәрләрендә исә *sän* формасы өстенлек итә: *äj, jeget, sän kem?* [Әбүгалисина, б. 45] 'Әй, егет, син кем буласың?'; *säne monda kitergän uldyr* [Әбүгалисина, б. 34] 'Сине монда китергән кеше – улдыр...'; *säne abysŧaj čaqyra digen* [Кырык вәзир, б. 153] 'Аны хуҗабикә чакыра, дип әйт'; *sän däxi mäŋa jämin it* [Кырык вәзир, б. 5] 'Син миңа сүз бир'; *sän kitablardan uqymadyŋmy* [Кәлилә вә Димнә, б. 11] 'Син китаплардан укымадыңмы...'; *sän irtä toryač šähärdän čyyyb kön čyyyšy jayyna qarab jör...* [Кәлилә вә Димнә, б. 2] 'Иртән торгач, син шәһәрдән чык та көнчыгышка таба бар'.

«Тутыйнамә» әсәрендә *sin* формасы актив кулланыла: *sine bu räwešle bälägä julyqtyrmyš* [Тутыйнамә, б. 83] 'Сине шулай итеп бәлага юлыктырган'; *min belämen ki sineŋ miŋa mäxäbbäteŋ xaqdyr* [Тутыйнамә, б. 6] 'Мин беләмен, синең миңа булган мәхәббәтең чын икәнен...'; *äj ana, sineŋ äjtkän süzläreŋdän baš tartmamyn* [Тутыйнамә, б. 35] 'Әй, ана, синең әйткән сүзләреңнән баш тартмамын...'.

Әсәр текстларында II зат күплек сандагы sez алмашлыгы патшаларга, вәзирләргә һ.б. абруйлы затларга ихтирамлы мөгамәләдә яки бер төркем кешеләргә мөрәҗәгать иткәндә кулланыла: *äj yaqylly wäzir, sez ğänäbeŋezdän ütenäbez* [Әл-җилдү әс-сәни, б. 9] 'Әй, акыллы вәзир, без сездән үтенәбез'; *sez alyb kitkän xatyn mänem xälälemder* [Кырык вәзир, б. 35] 'Сез алып киткән хатын-кыз – ул минем хатынымдыр'; *sez olyčylyq iteb mänem bu quwušyma täšrif ideŋez* [Кәлилә вә Димнә, б. 3] 'Сез олылап минем бу куышыма рәхим итегез'.

Әңгәмәдәшләрнең күплеген күрсәтү өчен, әсәрләрдә *sezlar* формасы да актив кулланыла: *sezlär (...) oryšqa čyqyač nä öčen qurqasyz* [Әл-җилдү әс-сәни, б. 29] 'Сез сугыш кырына чыккач, ни өчен куркасыз?; *bäyzysy sezlärne isŧäb...* [Әл-җилдү әс-сәни, б. 19] 'Кайберәүләр сезне күрергә теләде...'; *sezlärdän ütenämen, bu tuyryda jaxšy ujlab ... miŋa kiŋäš bireŋez* [Кәлилә вә Димнә, б. 6] 'Мин сездән, яхшылап уйлап, миңа киңәш бирүегезне үтенәм'.

Анализлана торган әсәрләрдә III зат берлек сандагы *ul* алмашлыгы әңгәмәдә катнашмаган кешегә ишарә итү өчен кулланыла: *ul kilgäč ğarijälärgä išarät qylyb* [Әбүгалисина, б. 44] 'Ул килгәч, җарияләргә хәбәр бирегез…'; *ul ägär tölkeneŋ süzen totmasa ide* [Тутыйнамә, б. 82] 'Ул әгәр төлкенең сүзен тыңламаган булса...', һ.б.

*Ul* алмашлыгы текстларда еш кына күрсәтү алмашлыгы буларак та кулланыла: *ul jeget šul bikneŋ xezmätendä čaγynda* [Кырык вәзир, б. 40] ‘Ул егет шул бәккә хезмәт иткән вакытта...’; *ul sandyqny aγačnyŋ külägäsenä qujyb, sandyqny ačty...* [Әлф ләйлә вә ләйлә, б. 6] ‘Ул сандыкны агач күләгәсенә куеп, ачты’; *ul qyz atasyn hafa kürgäč...* [Әлф ләйлә вә ләйлә, б. 7] ‘Ул кыз, курыккан әтисен күреп...’; *ul wäzir padišahnyŋ aldyna ber tabaq bal kiterde* [Кырык вәзир, б. 40] ’Ул вәзир патшага бер табак бал китерде’; *ul jazu tämam buldy* [Кәлилә вә Димнә, б. 6] ‘Ул хат тәмам булды...’; *ul jeget däxi qyzny xalas itärgä süz bireb* [Тутыйнамә, б. 82] ‘Ул егет кызны коткарырга сүз биргән иде’.

III зат күплек сандагы *alar* / *anlar* алмашлыгы сөйләшү процессында катнашмый торган затлар төркеменә ишарә итә: *män alarnyŋ bajtaq jaramas ešlären sizdem* [Кырык вәзир, б. 29] ‘Мин аларның күп кенә начар эшләрен сиздем’; *xammäl bu šartny kabul ideb, anlar ilä qaldy...* [Әлф ләйлә вә ләйлә, б. 53] ‘Йөк ташучы бу шартларны кабул итеп, алар белән калды...’; *alarnyŋ mujynnaryn syndyrsa ğihan tynyč bulyr* [Кәлилә вә Димнә, б. 4] ‘Аларның муеннарын сындырса, җиһан тыныч булыр иде’; *alar sine diwana bulγanlyqdan öjdän čyγyb kitkän dib...* [Тутыйнамә, б. 84] ‘Алар сине ахмак булганга күрә өйдән чыгып киткән дип (уйларлар)…’; *alarny ülterergä xökem itde* [Әбүгалисина, б. 52] ‘Аларны үлемгә хөкем итте…’.

Тикшерелә торган текстларда хәзерге татар теленең әдәби нормасы булган *alar* (алар) формасы өстенлек итә.

Кагыйдә буларак, *ni* һәм *nä* сорау алмашлыклары предметларга һәм күренешләргә карата кулланыла: *sän ni eślämäkče bulasyŋ?* [Әлҗилдү сәни, б. 6] ‘Син нәрсә эшләргә җыенасың?’; *qarčyq nä disen...* [Әлҗилдү хәмисү, б, 116] ‘Карчык нәрсә әйтә ала?’; *mindän ni is̱tärseŋ?* [Әбүгалисина, б. 39] ‘Миннән ни телисең?’; *nä bähä* [Әл-җилдү әс-сәни, б. 283] ‘Нинди бәя?; *bu nä xäjläder* [Әбүгалисина, б. 11] ‘Нинди хәйлә бу?’.

«Әбүгалисина кыйссасы» әсәрендә *ni* сорау алмашлыгы *waqyt* сүзе белән килеп, вакыт төшенчәсен белдерү өчен кулланыла: *ni waqyt mäγarä qapusy ačylyr dib köteb toryrlar ide* [Әбүгалисина, б. 7] ‘Мәгарә капкасы кайчан ачылыр дип көтеп торырлар иде...’.

Мисаллардан күренгәнчә, әсәрләрдә *nä* фонетик варианты, активлык ягыннан соңрак әдәби тел нормасына әверелгән *ni* шәкеленнән калыша.

«Кырык вәзир кыйссасы» һәм «Әбүгалисина» әсәрләрендә *nik* сорау алмашлыгы ‘ни өчен?’ дигән мәгънәдә кулланыла: *mändän nik qačasyŋ* [Кырык вәзир, б. 6] ‘Ни өчен миннән качасың?’; *any nik xalyqγa mälum itäsez?* [Әбүгалисина, б. 5] ‘Ни өчен аны халыкка җиткерәсез?’.

*Niček* сорау алмашлыгы предметның билгесен, эш-хәрәкәтнең башкарылу үзенчәлекләрен ачыклау өчен файдаланыла: *uγlym, söjlä, öč jašendä bulγannyŋ xikäjäse ničekder?* [Әлҗилдү рәбигу, б. 183] ‘Улым, сөйлә, өч яшьлек баланың хикәясе ничек булыр?’; *atamyznyŋ*

*išaräte niček ide?* [Кырык вәзир, б. 49] 'Әтиебезнең күрсәтмәсе ничек иде?'; *niček jaxšy kürsä, šulaj itsen* [Кәлилә вә Димнә, б. 5] 'Ничек кирәк дип саный, шулай эшләсен'; *ul xikäjä niček, söjlä* [Тутыйнамә, б. 88] 'Ул хикәя ничек, сөйлә'; *mondyj oluγ xämmäm bina qylmaq niček mömkin bulyr* [Әбүгалисина, б. 9] 'Мондый зур мунча төзү ничек мөмкин булды...'.

*Nä / ni qadär* һәм *ničä* сорау алмашлыклары кешеләрнең яки предметларның санын билгеләү өчен кулланыла: *nä qadär Baγdad γaskäre Afrädijun γaskärendän az bulsa da...* [Әл-җилдү әс-сәни, б. 22] 'Багдад гаскәре Афрадиюн гаскәреннән ничә тапкыр аз булса да...; *ničä jyl buldy...* [Әлҗилдү хәмисү, б. 6] 'Ничә еллар үтте...'; *ničä märtäbä atasyndan soradym, birmäde* [Әбүгалисина, б. 10] 'Ничә тапкыр этисеннән сорадым, бирмәде…'.

Өйрәнелә торган текстларда *närsä* алмашлыгы 'әйбер' мәгънәсен белдереп килә: *ul närsälär arasynda pulad jozaq belän biklängän ber sandyq tabyldy* [Кәлилә вә Димнә, б. 3] 'Ул әйберләр арасында корыч йозак белән бикләнгән бер сандык табылды...'; *ser didekläre närsä bänem qaršymda saqlanmaq öčen ber bülmägä qujγan närsä kebider, ul bülmäneŋ bikläb ačqyčlary juγalγan da, jänä jozaγy üzrenä möher orylmyšdyr...* [Әлҗилдү хәмисү, б. 11] 'Сер дигән әйбер саклар өчен бер бүлмәгә куйган әйбер кебек, ул бүлмә бикләнгән, ачкычлары югалган, янә йозаклары өстенә мөһер сугылган'; *kürde: ber zur jylan jatqan, bu su kebek aqγan närsä anyŋ zähäre* [Әлф ләйлә вә ләйлә, б. 33] 'Күрде: бер зур елан яткан, су кебек аккан әйбер – аның агуы…';

*Närsä* алмашлыгының бу мәгънәдә кулланылуы сөйләм теленең мөһим үзенчәлекләренең берсе булып тора, моны бүгенге сөйләм теле өлкәсендәге тикшерүләр дә исбатлый: «десемантизацияләнгән сүз сыйфатында чыгыш ясаучы һәм төрле предметларны, күренешләрне, субъектларны атау өчен кулланыла торган *нәрсә* сорау алмашлыгы аеруча үзенчәлеккә ия» [Галиуллина, б. 50].

*Kem* сорау алмашлыгы текстларда, гадәттәгечә, акыллы затны, ягъни кешене белдерү өчен кулланыла: *äj jeget, sän kemsän?* [Әлҗилдү рәбигу, б. 45] 'Егет, син кем буласың?'; *töse bujy da Mansyrγa šul qadär oxšady kem kürgän xuğa Mansyr dib xisab qylyr ide* [Тутыйнамә, б. 4] 'Тышкы кыяфәте белән ул Хуҗа Мансурга шундый охшаган иде ки, күргән кеше бу Хуҗа Мансур дип уйлар иде'; *kemne biräjek?* [Әбүгалисина, б. 61] 'Кемне бирәбез?'; *sez kemlärsez, qajsy jirdänsez?* [Кырык вәзир, б. 9] 'Сез кем соң, кай яклардан?'.

Вакыт турындагы сорауны белдерү өчен текстларда *qačan / qajčan* алмашлыгы кулланыла: *bez qačanγa čaqly bu tar ojamyzda jabylyb toryrmyz?* [Кәлилә вә Димнә, б. 7] 'Без кайчанга кадәр үз тар оябызда бикләнеп утырырбыз?'; *qajčan mäxbübeŋä julyqγan bulyr ideŋ?* [Тутыйнамә, б. 96] 'Кайчан син сөйгәнеңне очратыр идең?'.

*Ni öčen* сорау алмашлыгы текстларда процесслар һәм гамәлләрнең сәбәпләрен ачыклау өчен кулланыла: *ni öčen malyŋny juqqa beteräseŋ?* [Кырык вәзир, б. 59] 'Ни өчен малыңны юкка туздырасың?'; *xatynγa*

*kileb ni öčen taraq birmädeŋ didelar*... [Əлҗилдү рəбигу, б. 186] ‘Хатын янына килеп, ни өчен аңа тарак бирмəдең, дидeлəр...’; *ni öčen mondyj jäšeren serlärne söjläb*... [Тутыйнамə, б. 9] ‘Ни өчен мондый яшерен серлəрне сөйлисең?’; *ni öčen bolaj idäseŋ?* [Кырык вəзир, б. 53] ‘Ни өчен болай эшлисең?’.

Шулай итеп, тикшерелə торган əсəрлəрнең текстларында алмашлыклар төрки-татар сүзлəре белəн бирелгəн һəм алар күпмəгънəлелеклəре белəн аерылып торалар. Бер əсəр кысасында халык сөйлəм һəм иске татар теллəре лексемалары параллель кулланыла, бу күренеш хəзерге татар əдəби теленең формалашу үзенчəлеклəрен чагылдыра. Алмашлыкларның функциональ үзенчəлеклəрен анализлау нəтиҗəсендə тикшерелгəн əсəрлəрдə татар сөйлəм телендə таралган алмашлыкларның авторлар тарафыннан киң кулланылуы ачыкланды.

**Əдəбият**

*Галиуллина Г.Р.* Современная татарская разговорная речь: идентификационные признаки и социальная дифференциация / Г.Р. Галиуллина, Э.Х. Кадирова, Г.К. Хадиева. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2020. 220 с.

ابو علي سينا قصه سي ديمكله مشهور تخيلات ننك ترجمه سي.عبدالقيوم عبدالناصر اوغلي ننك ترجمات و تصنيفاتندادر. قزان اونيويرسيتيتي ننك طبع خانه سنده باصمه اولنمشدر ١٨٩٤ نچي يلده. ١١٢ ب. = Абу Гали Сина кыссасы димəклə мəшһүр тəхйилəтнең тəрҗемəсе = Рассказы Абу Гали Сины. Казань: Изд-во Казан. ун-та. 1894. 112 с.

الف ليلة و ليلة،بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي، ١٨٩٧ سنهده ٢١٢ ب. = Əлф лəйлə вə лəйлə = Тысяча и одна ночь. Т. 1. Казань: Изд-во Казан. ун-та. 1897. 212 с.

الجلد الثاني ترجمة الف ليلة و ليلة ايكنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي ٧٩٨١ سنه ده. اوشبو مننك ده بر كيچه كتابى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل قزان اويازى توبان قرصى آولى حاجى شمس الدين حسين اوغليننك ورثه لري خراجاتي ايلان اول مرتبه ١٨٩٨ يلده ١٢٠ ب. = Əл-җилдү əс-сəни тəрҗəмəти əлф лəйлə вə лəйлə = Тысяча и одна ночь. Т. 2. Казань: Изд-во Казан. ун-та. 1898. 120 с.

الجلد الثالث ترجمة الف ليلة و ليلة. اوچنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه باصلوى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ١٨٩٨ سنه ده. ٢٨٦ ب. = Əлҗилдү əс-сəлисү тəрҗəмəти əлф лəйлə вə лəйлə = Тысяча и одна ночь. Т. 3. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1898. 286 с.

الجلد الرابع ترجمة الف ليلة و ليلة. درتنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه باصلوى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ١٨٩٩ سنه ده. ٣١٨ ب. = Əлҗилдү рəбигу тəрҗəмəти əлфи лəйлəти вə лəйлə = Тысяча и одна ночь. Т. 4. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1899. 318 с.

الجلد الخامس ترجمة الف ليلة و ليلة. بشنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه باصلوى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ١٨٩٩ سنه ده. ١٩٢ ب. = Əлҗилдү хəмисү əлфи лəйлəти вə лəйлə = Тысяча и одна ночь. Т. 5. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1899. 192 с.

الجلد السادس ترجمة الف ليلة و ليلة. الطنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي

اول مرتبه باصلوى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ١٨٩٩ سنه ده. ٣٨٢ ب
= Әлҗилдү сәдисү әлфи ләйләти вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 6. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1899. 382 с.

طوطي نامه. عبدالعلام فيض خان اوغلي نك ترجماتندن. مطبعة كريميه، قزانده ١٩١٦. ١٧٥ ب
= Тутыйнамә =Тутыname, Казань, Матбага Каримия, 1916. 175 с.

كليله و دمنه كتابي. بو كتاب باصمه اولنمشدر قزان اونيويريستيني ننك طبع خانه سنده ١٨٨٩ نچى يلده.
٨٧ ب. = Кәлилә вә Димнә китабы= Калила и Димна. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1889. 87 с.

قرق وزير قصه سي، عثمانلى تلندن ترجمه قيلنوب قزانده اوچونچى مرتبه باصلدى. عبدالقيوم عبدالناصر
اوغلي ننك ترجماتنداندر. قزانده انيويرسيتيت طبع خانهسنده باصما اولنمشدر ١٨٨٣ سنه ده. ١٦٠ ب
= Кырык вәзир кыссасы = Рассказы сорока визирей. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1883. 160 с.

**_Гыйлемшин Флер Фоат улы,_**
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе фәнни хезмәткәре*

УДК 81´373

***Г.С. Хаҗиева***

# ТАТАР ТЕЛЕ ЛЕКСИКАСЫНЫҢ ЭКСПРЕССИВ-СТИЛИСТИК КАТЛАМНАРЫ

В данной статье рассматриваются экспрессивно-стилистические пласты татарской лексики в научном, публицистическом, официально-деловом и литературном стилях, которые были сформированы веками и имеют особую форму и функции. Как показало исследование, непрерывное непосредственное взаимодействие функциональных стилей способствует развитию татарского литературного языка. В работе подчеркнуто, что лексика книжных стилей обновляется, обогащается благодаря включению в них лексики разговорной речи. В разговорную речь, в свою очередь, проникают элементы книжных стилей. Постоянный процесс взаимодействия стилей, который определяет в конечном счете развитие татарского литературного языка.

**Ключевые слова**: стиль, экспрессивно-стилистические пласты, татарская лексика, научный стиль, официально-деловой стиль, публицистический стиль, литературный стиль.

This article examines the expressive-stylistic layers of the Tatar vocabulary in the scientific, journalistic, official-business, epistolary and literary styles, which have been formed over the centuries, have a special form and function. The research has shown that the continuous direct interaction of functional styles contributes to the development of the Tatar literary language. The work emphasizes that the vocabulary of book styles is updated, enriched by the inclusion of colloquial vocabulary in them. In spoken language, in turn, elements of book styles penetrate. There is a constant process of interaction of styles, which ultimately determines the development of the Tatar literary language.

**Keywords:** style, expressive-stylistic layers, Tatar lexicon, scientific style, journalistic style, epistolary style, literary style.

Бүгенге тел белемендә «функциональ стильләр, башка телләрдәге кебек үк, тел структурасына, шулай ук җәмгыять һәм аң-акыл системаларына» [Бәширова, 2005, б. 22] һәм заманга бәйле үзгәрешүсеш мөнәсәбәтендә каралалар. Стиль билгеле бер лексик чаралар системасы белән характерлана [Сафиуллина, Зәкиев, 1994, б. 83]. Лексик чаралар, нигездә, ике катлам – язма (китап) һәм сөйләм төрләрендә билгеләнәләр. Стиль (латин. *stylus* – язу коралы, язу манерасы, таякчык) сүзе, термин буларак, лингвистика, әдәбият, сәнгать, музыка өлкәләрендә төрле мәгънәләрдә кулланыла. Тел белемендә стиль – телнең дифференциаль төрләренең берсе, үзенә хас сүз байлыгы, фразеологик берәмлекләре, конструкцияләре булган, төрле тел чараларын үз эчендә туплаган, телнең башка ассистемаларыннан эмоциональ-экспрессив үзенчәлекләре белән аерылып торган тел системасы [Ахманова, 2004, с. 455]. Билгеле булганча, кешенең гамәли эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килеп, бу эшчәнлекне чагылдыруда

тотрыклы бер система булдырган функциональ стиль катламнарының гомуми тел белемендә аерым вазифалары бар. Иҗтимагый тормышта бара торган эшчәнлекне алып бару өчен барлыкка килгән, гасырлар дәвамында төрле вазифалар башкарган, калыплашкан сөйләм төрләрен функциональ стиль дип атыйлар. «Функциональ стиль – тарихи формалашкан төрле тел берәмлекләренең үзара бәйләнеш-мөнәсәбәте һәм сүз сайлауның сөйләмдә гамәлгә ашуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән сөйләм тибы» [СЭСРЯ, 2003, с. 581].

Язма тел – чынбарлыкның бер системасы булган җәмгыятьне яшәтү өчен кирәкле күптөрле иҗтимагый эшчәнлек алып бару процессында озын гасырлар узып формалашкан, аң-акыл тарафыннан кабул ителгән, махсус калыплашкан сөйләм [Бәширова, 2012, б. 212]. Язма телнең аерым вазифалары белән билгеләнгән рәсми, фәнни, иҗтимагый, матур әдәбият стиле кебек функциональ төрләре аерыла. Әлеге стильләрнең үзләренә хас табигате, чынбарлык һәм аң-акыл белән бәйләнеш мөнәсәбәте, шулай ук вазифалары – үзләренә йөкләтелгән эш башкару процессы таләп иткән төрле жанр-төрләрдә булуы билгеләнә, тел берәмлекләренең ни рәвешле сайлап алынуы һәм авторлык мөнәсәбәтенең чагылышы күзәтелә. Язма тел дәүләт эшендәге төрле хокукый хезмәтләрне, фәнни танып белүне теркәү, әдәбият, җәмгыятьнең барышы белән бәйле гамәлләр башкара. Тел һәм сөйләм процессында фәнни стиль – фәнни-коммуникатив, хәбәр итү вазифасы, иҗтимагый-публицистик стиль – өндәү-агитацияләү, рәсми эш кәгазьләре стиле – хәбәр итү, эпистоляр-хатлар стиле – йогынты ясау һәм хәбәр итү вазифалары белән аерылалар. «Язма телдә – төрле вазифа үти торган сөйләм типлары, ягъни функциональ стиль таләбенә туры килә торган ныклы тәртип саклану: әйтелергә тиешле фикерне барлык төбәкләрдә яшәүче укучыларга төгәл итеп җиткерү, һәр стильнең һәм аның җанр төрләренең үзләренә хас булган төзелеш-структурасын, тәкбирләү тәртибен катгый саклау, мөнәсәбәт – белдерелү-белдерелмәүнең чамасын белү, орфографиянең әдәби дөрес булуын даим аңлы рәвештә истә тоту таләп ителә» [Бәширова, 2012, б. 13]. Һәр функциональ стиль структур яктан оешкан һәм системалы бөтен булудан тыш, билгеле бер вакыт аралыгында барлыкка килгән, расланган һәм шомартылган лексик чаралар белән билгеләнә. Билгеле булганча, сөйләмнең язма һәм сөйләм формаларына хас фонетик, лексик, грамматик үзенчәлекләр бар. Әлеге аерманың булуын телнең язма һәм сөйләм төрендә дә бердәй хезмәт итә торган, барлык стильләр өчен дә уртак саналган стильара сүзләр тәшкил итә. Шулар фонында стилистик бизәкләргә ия сүзләрнең, сөйләм чараларының саны һәм сыйфаты ачыклана. Әлеге лексик чаралар һәр стильгә функциональ яктан беркетеләләр. Стильләрнең төрле катламнарын тәшкил иткән тел чаралары җыелмасы (лексик, морфологик, синтаксик, шулай ук фонетик чаралар) система бөтенлеген тәэмин итә. Система бөтенлеге функциональ стильләрне оештырганда барлыкка килгән тел чараларының билгеле бер стильдә ныгуы нигезендә формалаша,

шул рәвешле үзләренә мөстәкыйльлек булдыра. Стиль катламнарын тәшкил итүче тел чараларының үзара бәйләнеше функциональ стильләрнең системалы-структур бәйләнешен барлыкка китерә. Лексик чараларның системалы бөтенлеге функциональ стильләрне аеру критерийларының берсе булып тора. Шул рәвешле, һәр стиль үз лексик берәмлекләреннән торган бербөтен формалаштыра, ягъни һәр стильнең үзенә генә хас лексик берәмлекләре барлыкка килә. Әлеге лексик чаралар стильләргә функциональ яктан беркетеләләр. Телдә бер стиль катламына караган лексик чараларның икенче стиль катламына керә алу мөмкинлеге дә бар [Сафиуллина, Зәкиев, 1994, б. 83]. Мисал итеп, иҗтимагый-сәяси лексика рәсми эш кәгазьләре стилендә дә, фәнни һәм иҗтимагый-публицистик стильләрдә дә билгеләнә. Рәсми эш кәгазьләре стилендә иҗтимагый-сәяси лексика түбәндәгечә кулланыла: *Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты* ***Татарстан Республикасы законнары*** *рәвешендә әзерләнә һәм раслана,* ***җирле бюджетлар муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары муниципаль хокукый актлары*** *рәвешендә әзерләнә һәм раслана* (Ватаным Татарстан, 2021, № 56). Сәяси темаларга кагылышлы газета-журнал мәкаләләрендә иҗтимагый-сәяси лексика шулай ук аерым лексик катлам барлыкка китерә: *18 сентябрьдә РФ ФҖның VII чакырылыш* ***Дәүләт Думасына депутатлар сайлауларда бер мандатлы округларда*** *җиңгән кандидатлар исемлеге мәгълүм* (Ватаным Татарстан, 2021, № 56). Фәнни стильдә иҗтимагый-сәяси лексика социология, политологиягә караган өлкәләрдә еш кулланыла: ***Россия һәм Татарстан дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләр чикләрен бүлешү турындагы Шартнамәгә*** *кул кую үзәкнең безнең карашыбыз хаклыгын тану булды* (Ватаным Татарстан, 2021, № 56). Билгеле бер стильгә караган лексик чараларның икенче бер стильдә кулланылышы стилистик норма белән билгеләнә. «Стилистик норма – стилистик мөмкинлекләрнең тарихи формалашкан һәм тел үсешендә кабул ителгән чаралар, кануннар системасы ул» [СЭСРЯ, 2005, с. 433].

Фәнни стильдә сүз мәгънәсенең төгәл, катгый бер кысаларга керүе таләп ителә, сүзләр, нигездә, туры мәгънәләрендә кулланылалар, сурәтләү чаралары, метафорик сүзләр, гиперболалар, эпитетлар очрамый, сөйләм махсус терминнар белән сугарылган була. Мәсәлән: ***Биотехнология молекуляр биология*** *һәм* ***генетика, микробиология һәм биохимия, физиология һәм цитологиянең*** *теоретик нигезләренә таяна һәм аны фән һәм техниканың катнаш өлкәсе дип карарага була* (Фәнни Татарстан, № 3, 2018). Молекуляр биологиянең актуаль мәсьәләләрен яктырткан мәкаләдән китергән өзектә барлык сүзләр дә туры мәгънәдә кулланылганнар, образлы, метафорик сүзләр күзәтелми.

Матур әдәбият стилендә лексик чаралар образлылыкны арттыру, тәэсирлелекне көчәйтү максатында кулланылалар. Ул кулланылышы

ягыннан һәр катламны да чагылдырырга мөмкин. Биредә шактый иркен рәвештә китап теле лексикасы, сөйләм теле берәмлекләре янәшә кулланыла ала. Аның нигезен гомумкулланылыш сүзләре алып тора. Матур әдәбият теленең төп үзенчәлекләреннән берсе – лексик берәмлекләрнең коннотатив эчтәлеккә бай булуында. Бу төрдә стильара лексика да сәнгати сурәтләү вазифасын башкарып, эстетик функциядә кулланыла. Мәсәлән, матур әдәбият теле лексикасының функциональ-стилистик йөкләмәсе сүзләрнең семантик мәгънәләре киңәю, яңа сүзләр яки окказиональ сүзләр барлыкка килү, сүзнең комбинатор-структур мөмкинлекләрен файдаланып, яңа сүзләр иҗат ителү, диалекталь сүзләрне куллану, гади сөйләм лексикасына мөрәҗәгать итү, тарихи сүзләр, архаизмнарны билгеле бер максат белән әсәр тукымасына кертеп җибәрү, экзотизмнар, парлы сүзләрне куллану нигезендә ачыла.

Иҗтимагый-публицистик стильдә лексик катлам төрлелеге белән аерыла, иҗтимагый-сәяси фразеология зур урын алып тора һәм тел хәзинәсен баетуда әһәмиятле вазифа үти. Хәзерге иҗтимагый-публицистик лексика бары тик иҗтимагый-публицистик стиль кысалары белән генә чикләнми. Әлеге төр лексика башка стильләргә дә күчә ала, ягъни сүзләр функциональ чиклелектән азат. Функциональ яктан чикле булган сүзләрнең (диалекталь сүзләр, варваризмнар, сленг, гади сөйләм сүзләре) иҗтимагый-публицистик стильдә кулланылышы шулай ук гадәти күренеш. Мәсәлән, *«Көр булу»* – мәкалә исеме (Ватаным Татарстан, № 23, 2019), *«Яренгә тагын да зуррак уңышлар белән куандырырбыз әле», – диде колхоз рәисе* (Ватаным Татарстан, № 23, 2019) кебек диалекталь сүзләр аерым стильләргә, шулай ук әдәби телдә шушы төшенчәне белдерердәй сүз булмаса, һәм публицистикада, мәсәлән, әңгәмәдәшнең, персонажның сөйләм үзенчәлекләрен сурәтләү өчен кулланыла (репортаж жанрында киң таралган күренеш).

Шулай ук газета-журнал битләрендә күпсанлы варваризмнарны – чит тел сүзләрен очратырга мөмкин: *Соңгы елларда шәһәр урамнарында төсле буяулар белән «кальян өчен катнашмалар», 'Aroma' дип язылган такталар эленгән кечкенә кибетләр пәйда булды. Инде алкоголь, тәмәке тарту белән генә канәгатьләнмәгән яшьләр Spise, Tigrin, Dream да шушы хуш исле катнашмаларга кызыга башлады. Ә нигә әле татып карамаска янәсе?* (Шәһри Казан, № 56, 2019). *Инде Gucci, Prada брендлы киемнәргә килгәндә, мондый киемнәр безнең кебек гади халык сатып ала алырлык түгел шул* (Шәһри Казан, 2020, № 34).

Фәнни лексика – ул төрле эзләнү-тикшеренүләр ярдәмендә тирә-юньне, чынбарлыкны өйрәнеп, фәнни нәтиҗәләрне саклау һәм чагылдыру өчен кулланылган сөйләм тибында чынбарлыкны, фикерне логик эзлеклелектә, төгәл итеп, аерым бер фән тармагына гына хас булган гомумфәнни төшенчәләр һәм терминнар ярдәмендә фәнни чагылдырган сүзләр яки сүз гыйбарәләре. Фәнни стильнең актив лексик катламын гомумфәнни лексика тәшкил итә: *мәгънә, өлеш, элемент,*

*сан, процесс, функция, тигезләмә* һ.б. Мисал: *Alcanivorax borkumensis исемле бактерияләр һидрокарбоннарны таркатучы микробларның әһәмиятле төркемен тәшкил итәләр* (Фәнни Татарстан, 2020, № 3). Татар телендә фәнни лексика алынма сүзләр белән билгеләнә: *тәшкил итә, тәэмин итә, фараз, гомуми, шәрехләү, мәгънәви, гипотеза, процесс, текст, материал, консолидация, проблема, система, этап, традиция, гипотеза һ.б. Соңгы ун елда үсемлекләрдәге яңа биоактив метаболитларны һәм микроорганизмнарны өйрәнү гаять активлашты, бу химик һәм молекуляр-генетик анализ методларының камилләшүе күзәтелә* (Фәнни Татарстан, 2019, № 3). XX гасырда фәнни лексиканың үсешенә рус теленең тәэсире көчле була һәм бу лексик планда гына калмыйча, морфология, синтаксис дәрәҗәсендә билгеләнә. Үзгәртеп кору башлангач, югары уку йортлары өчен дәреслекләр, фәнни мәкаләләр татарча языла башлый һәм элеккеге фәнни стильгә кайтуга омтылыш туа.

Шулай итеп, татар телендә һәр функциональ стиль структур яктан оешкан һәм системалы бөтен булудан тыш, билгеле бер вакыт аралыгында барлыкка килгән, расланган һәм шомартылган лексик чаралар белән дә билгеләнә. Телнең тарихи үсеше процессында әдәби тел вазифаларының киңәюе, кеше эшчәнлегенең яңа төр-өлкәләрендә яисә коммуникатив процессларда файдаланылган әдәби тел чараларының һәм сөйләшүченең төрле иҗтимагый рольләренең үсеше стильләр, стильләр лексикасы формалашуга китерә.

**Әдәбият**


*Ахманова О.С.* Словарь лингвистических терминов. 2-е изд., стер. М.: УРСС: Едиториал УРСС, 2004. 576 с.

*Бәширова И.Б.* Татар әдәби теле тарихы: гомумтеоретик мәсьәләләр: татар әдәби теленең билге-шартлары һәм аларның өйрәнелеше. Казан, 2012. 255 б.

*Низамов И.* Ярдәмең берлән синең... Казан: Мәгариф, 2008. 238 б.

*Низамов И.М.* Татар социолингвистикасы. Казан: Казан. ун-ты, 2006. 150 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле / Ф.С. Сафиуллина, М.З. Зәкиев. Казан: Мәгариф, 1994. 320 б.

Стилистический энциклопедический словарь русского языка / под ред. М.Н. Кожиной. М.: Флинта: Наука, 2003. 696 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 874 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 726 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 475 б.

Татар теленең диалектологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 459 б.



***Хаҗиева Гүзәлия Сәйфулла кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Казан дәүләт мәдәният институтының универсаль компетенцияләр методологиясе һәм технологиясе кафедрасы мөдире*

УДК 81´373.21

***Р.И. Куряева***

# КАЗАНСУ БАССЕЙНЫ ГИДРОНИМНАРЫ ҺӘМ ОЙКОНИМНАРЫ АРАСЫНДАГЫ ҮЗАРА БӘЙЛӘНЕШ

Анализ ойконимов и гидронимов бассейна р. Казанка позволил сделать вывод, что часть ойконимов являются производными от гидронимов. Для таких ойконимов характерны компоненты «верхний», «нижний», «баш» и др. Сами гидронимы являются наиболее древними топонимами и представляют собой гибридные имена, составленные из лексем разных языков со значениями «река», «вода». На основе этимологического анализа гидронимов можно сделать выводы о народах, населявших Среднее Поволжье, об очерёдности их миграции. На территории Среднего Поволжья имеются следы финно-угорских народов Поволжья и Сибири, самодийских, тунгусо-маньчжурских и тюркских народов Сибири, а также южных тюркских народов Причерноморья. Финно-угорский пласт является самым древним. Самый верхний пласт состоит из татарского и чувашского языков.

**Ключевые слова:** ойконимы, гидронимы, этимология, финно-угорские языки, языки народов Сибири, тюркские языки.

Analysis of oikonyms and hydronyms of the Kazanka river basin shows that some oikonyms are derivatives of hydronyms. In Russian such oikonyms are characterized by components «верхний», «нижний», «баш» and others. Hydronyms themselves are the most ancient toponyms and consist of the words with the meaning «water» in different languages. Etymological analysis of hydronyms shows what nations lived on the territory of the Middle Volga region. They are Finno-Ugric nations of Siberia and the Volga region, Samoyedic, Tungus-Manchurian and Turkic nations. The most ancient nations of the Middle Volga region are Finno-Ugric, the last are Tatars and Chuvashes.

**Keywords:** oikonyms, hydronyms, etymology, Finno-Ugric languages, Siberian nations languages, Turkic languages.

Урта Идел буенең ойконимиясен (торак пунктларның исемнәрен) тикшерү барышында күп кенә ойконимнарның елга исемнәреннән, ягъни гидронимнардан ясалганлыгы ачыкланды. Торак пунктлар һәм елга исемнәре арасындагы үзара бәйләнешне ачыклау өчен, әлеге мәкалә авторы Идел бассейнына караган гидронимнарның һәм ойконимнарының электрон фондын төзеде. Ул 10 мең берәмлеккә якын ономастик лексиканы үз эченә ала. Эш барышында очраган барлык гидрографик терминнарны да без шунда ук керттек.

Гидронимнарның этимологиясе, гадәттә, бик катлаулы, аларны өйрәнү белән аерым тикшеренүчеләр генә түгел, ә тулы бер фәнни коллективлар шөгыльләнә.

Гидронимнар һәм ойконимнар арасындагы үзара бәйләнешне анализлауны без Казансу елгасы бассейны территориясеннән

башладык. Гидронимнарга туры килгән ойконимнарны чагыштырып, түбәндәге нәтиҗәгә килдек:

а) ойконимнар тулысынча гидронимнар белән туры килергә мөмкин:

Абла, Өнсә (Инся), Арча (Арск), Казаклар, Казиле (Казыли), Кипячий, Кырлай, Коры елга (Сухая река), Сулы (Сула), Ташкичү (Ташкичу), Чабакса (Чебокса), Төбәк-Чокырча (Тюбяк-Чекурча), Көек (Куюк), Күлтәс (Култесь), Муй, Наласа, Бөреле (Бирюли);

ә) ойконимнарның гидроним белән яраштырылган **Югары, Түбән** аергычы булырга мөмкин: Югары Әрнәш (Верхний Арняш), Югары һәм Түбән Аты (Верхние и Нижние Аты), Югары Ия (Верхняя Ия), Югары һәм Түбән Курса (Верхняя и Нижняя Корса), Югары Бирәзә (Верхние Верези), Түбән Көек (Нижний Куюк), Югары һәм Түбән Пошалым (Верхний и Нижний Пшалым), Югары Масра (Верхняя Масра);

б) ойконимның татарча **баш** (верховье) топоэлементы булырга мөмкин: Ашытбаш (Ашитбаш), Субаш Аты, Казанбаш, Курсабаш, Бирәзәбаш (Верези-баш), Солабаш (Сулабаш), Яңа Иябаш (Новый Яваш), Орнашбаш (Урнашбаш), Сәрдәбаш (Сердебаш), Шушмабаш, Көекбаш (Куюкбаш);

в) рус телендә ойконимнар күплек сандагы исем формасын алырга мөмкин: Бөреле (Бирюли), Бимәр (Бимери), Киндерле (Киндери), Келәтле (Клетни), Бирәзә (Верези), Чабакса (Чебоксы), Күлтәс (Культесы), Наласа (Наласы).

а) һәм б) пунктлары ойконимнарның гидронимнардан ясалганлыгы турында сөйли, ягъни елганың исеме – беренчел, ә торак пунктның исеме икенчел булган.

Ул вакытта, әгәр ойконим **Югары, Түбән, баш** компонентларына ия булса яки күплек сандагы исем рәвешен алса, аның гидронимнан килеп чыгуы турында нәтиҗә ясарга мөмкин (хәтта аларга тәңгәл елга юкка чыккан яки исемен алыштырган булса да).

Казансу бассейнында санап үтелгән билгеләргә ия түбәндәге ойконимнар бар, әмма аларга тәңгәл гидронимнар юк:

а) **Югары, Түбән** компонентлары булган ойконимнар: Югары Әзәк (Верхний Азяк), Югары Шүләнгер (Верхние Шеленгуры) (чагыштыр: Шеленгур), Югары һәм Түбән Шашы (Верхние и Нижние Шаши), Югары һәм Түбән Оры (Верхняя и Нижняя Ура);

ә) **баш** компоненты булган ойконимнар: Шулабаш, Шурабаш, Айбаш, Апсабаш;

б) күплек сандагы исем рәвешендәге ойконимнар: Әке (Аки), Бирли, Дөбьяз (Дубъязы / Дубъясы), Каймар (Каймары), Комыргуҗа (Кумургузы / Коморгузя), Коркачык (Куркачи), Мөрәле (Мрали / Мурали), Салмачы (Салмачи), Сасмачи, Турнали, Ульязы, Чыпчык (Чепчуги), Шуманы / Шуман, Эстачи, Югары Шүләнгер (Верхние Шеленгуры).

Күрәсең, а) һәм ә) пунктларындагы ойконимнар юкка чыккан Шүләнгер (чагыштыр: Шеланда, Шелдаис, Шелна, Шелокшанка,

Шиланлы елгалары), Шула (чагыштыр: Шуля елгасы) һәм Азяк (чагыштыр: төрки **озек / өзөк** «река, речка», карталарда еш кына **узяк**) гидронимнарыннан ясалганнар [Мурзаев, с. 406]. ә) пункты ойконимнары шулай ук гидронимнардан килеп чыккан булырга мөмкин.

Урта Идел буе гидронимнарына этимологик анализ түбәндәге кабатлана торган элементларның булуын күрсәтте: **ар, ба, га, да / до, ка, ем / им, ж / жа / жу, з / зай, лы, лей, ма, ра, с / са / сы, т / ты / тай, ш / ша** һ.б. Э.М. Мурзаев сүзлегендә бу элементларның мәгънәләрен эзләү нәтиҗәсендә аларның бер өлешен тәңгәлләштерергә мөмкин булды: венг. **ар** «поток», манси **ари** «речка», самод. **ба / бу / бы / би** «река», сельк. **гу / гы** «река», эвен. **до** «река», хакас. **зай** «река», морд. **лей / ляй** «речка», алт. **кол** «река» һ.б., мәсәлән, тат. **су** «вода» Суык Су һәм Ия-Су гидронимнары составына керә; тат. **ширмә** «река» – Ямаширмә елгасы; төрки, монг. **сала** «приток» – Сула / Сыла / Сола елгасы; себ.-тат. **ман** «река» – Лашман / Ылашман елгасы, Шуман торак пункы; чув. **шу** «вода» – Шуман торак пунты; морд. **лей / ляй** «река, речка» – Киндерля / Киндерлей елгасы; коми **сер** «река» – Серда / Сәрдә елгасы; манси **я** «река» – Ия-Су елгасы; венг. **ар** «река, поток» – Әрчу (Арча / Арск), Арняш / Орняш / Урняш, Бимәр / Бимерь / Бимерка (чагыштыр: Бима торак пункты) елгалары; самод. **чу** «река» – Арчу (Арча / Арск торак пункты), Ташкичү елгалары; ненец. **и** «вода» – Ия-Су елгасы; эвен., эвенк. **бира** «река» – Бөреле (Бөреле торак пункы), Бирәзә / Вереза / Верезинка елгалары; эвен. **до** «река» – Сәрдә / Серда елгасы; маньч. **ула** «большая река» (чагыштыр: төрки. **олы** «большой») – Ылашман / Лашман елгасы; тунг.-маньч. **му / муэ** «вода» – Му / Муй елгасы; аринск. (үле тел, кет теленә якын) **куль** «вода» (чагыштыр: тат. **күл** «озеро») – Күлтәс елгасы (Күлтәс / Культесы торак пункты); кет. **ур** «вода» – Урмаш, Урнаш / Орнаш / Арняш елгалары, хакас. **зай** «река», протоболг. **зәй** [Байчоров, с. 129] «река» – **Зай / Зәй / Дәй / Ди / Зи** елгасы [Гарипова, с. 42] (Зәй / Заинск, Югары Зәй / Верхний Зай, Яңа Зәй / Новый Зай, Зәй-Салаяз / Зай Солояз, Зәй-Чишмә торак пунктлары).

Бу чагыштыру Урта Идел буенда **елга исемнәре**, нигездә, **төрле телләр лексемаларыннан төзелгән «елга», «су» дигән мәгънәле гибридлы исемнәрдән** гыйбарәт, дип нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирде. Мәсәлән, ТРда Ия-Су елгасы исеме өч компоненттан тора: ненец. **и** «вода»+ манси **я** «река» + тат. **су** «вода»; Шуман ойконимы ике компонентлы: чув. **шу** «вода» + себ.-төрк. **ман** «река»; **Серда / Сәрдә** гидронимы [Гарипова, с. 108]) = коми **сер** «река» [Мурзаев, с. 503] + эвен. **до** «река», протоболг. **дәй** «река» [Байчоров, с. 128] (Рус Сәрдәсе торак пункты); Самара өлкәсендә: **Аскула** елгасы = хант. **ас** «река (большая)» [Мурзаев, с. 58] + алт. **кол** «река», чагыштыр: баш. **кул** «низина, овраг» [Мурзаев, с. 148], моннан – Аскула ойконимы, аның иске варианты Аскул, Аскула; Пенза өлкәсендә: **Азясь** елгасы = хант. **ас** «река (большая)» + протоболг. **зәй** «река» + тат. **су** «вода», моннан – Азясь, Большой Азясь, Малый Азясь, Николо-Азясь ойконимнары; **Аришка** елгасы = манси **ари** «речка» = чув. **шу** «вода»

[Мурзаев, с. 528] + рус. аффикс **-ка,** моннан – Аришка ойконимы; **Арчада** елгасы = венг. **ар** «поток» + госм., чаг. **чай** «маленькая речка» [Радлов, т. 3, с. 1824], протоболг. **джай** / **чай** «река» [Байчоров, с. 128] + эвен. **до** «река», протоболг. **дай** / **дәй** «река», моннан – Казанская Арчада, Никольская Арчада, Покровская Арчада ойконимнары; **Сердоба** елгасы = коми **сер** «река» + эвен. **до** «река» + самод. **ба** «река», моннан – Малая Сердоба, Сердобинка, Сердобск ойконимнары; **Час** елгасы = госм., чаг., протоболг. **чай** «речка» + тат. **су** «вода», моннан – Новые Часы, Старые Часы ойконимнары.

Киндерлей / Киндерля елгасы атамасының ике вариантта йөрүе соңгы [й] авазының төшеп калу ихтималы булу турында сөйли. Шул нигездә Бөреле һәм Бирәзә гидронимнарының килеп чыгышын ике компонентның кушылмасы буларак та аңлатып була: эвен. **бира** «река» + морд. **лей** «речка» һәм эвен. **бира** «река» + хакас. **зай** «речка», чагыштыр: Татарстанда Зәй елгасы һәм Башкортстанда Бира елгасы.

Бөреле гидронимына туры килә торган Бөреле ойконимы **-ли** кушымчасының, **-ле** кушымчасы кебек үк, морд. **лей**ның («речка») фонетик варианты булып торуын раслый. Ул чагында Кавал / Ковали, Казиле / Казыли, Мөрәле / Муралинка гидронимнары, шулай ук Мөрәле / Мрали, Бирли, Торналы / Турнали ойконимнары морд. **лей**дан килеп чыккан.

Бирәзә / Вереза / Верезинка гидронимының һәм Бирәзә, Верези ойконимнарының вариантлары атамалардагы **-за** / **-зә** / **-зи** кушымчаларының хакас. **зай**ның («речка») вариантлары булып торуын күрсәтә. Ул вакытта Коморгузя / Кумургузы / Комыргуҗа ойконимын да шул ук **зай** термины белән бәйләп була. Дубъязы / Дубъясы / Дөбьяз ойконимының өч варианты **-зы** / **-сы** / **-з** кушымчаларының хакас. **зай**ның вариантлары булуы турында сөйли. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: хакас телендә **зай** терминыннан тыш шул ук «речка, ручей» мәгънәсенә ия **сай** сүзе дә бар. Ул вакытта **-сы** кушымчасы тат. **су** «вода»га да, хакас. **сай**га да туры килергә мөмкин. Нәтиҗәдә, Наласа, Чабакса, Күлтәс / Культесь ойконимнары төрки **сай**, **су**дан барлыкка килгән. Шулай итеп, **-са, -сь** кушымчалары төрки **сай, су**га барып тоташа. Димәк, Инса, Корса / Курса, Нокса, Мораса гидронимнары да шул ук рәткә керәчәк.

Арчу / Арча атамаларында **-ча** / **-чу** кушымчаларының чиратлашуы **-ча** кушымчасының самод. **чу**ның («река») фонетик варианты булырга мөмкин, дип фаразларга мөмкинлек бирә. Ул чагында Чекурча / Чекурчинка гидронимын да самод. **Чу**га бәйләп була. Хәер азәрб., төрек. **чай**ны («речка, река») да күздә тотарга кирәк. Мөгаен Кипячий гидронимы, Куркачи / Коркачык, Эстачи, Салмачи, Сасмачи ойконимнары да шул ук рәттә урын аладыр.

Суык-Су елгасының атамасына игътибар итик. Ул салкын су мәгънәсенә ия. Ягъни исемдә аергыч һәм аерылмыш – бер үк тел сүзләре. Бу ТР территориясе буйлап ага торган Кичуй елгасының

мәгънәсен ачыкларга ярдәм итә. Ул ике компоненттан тора: венг. **ко** «камень» + самод. **чу** «река» (шунысы билгеле: самодий һәм фин-угор телләре бер үк Урал телләре семьялыгына керә). Ул вакытта **кө + чу** тезмәсе Таш елга («Каменная речка», «Каменка») мәгънәсен бирә. Моннан, Ташкичү гидронимы ике татар компонентыннан тора: тат. **таш** «камень» + тат. гидронимы Кичү. Монда тат. **таш** фин-угор атамасын яртылаш тәрҗемә итү (бу күренеш ярым калька дип атала) нәтиҗәсендә барлыкка килгән, ягъни ул да «Каменка» мәгънәсен бирә, ә икенче яктан, ул бертөрле диярлек аталучы һәм бер-берсенә якын урнашкан ике елганы аеру өчен хезмәт итә.

Казансу елгасы бассейнының югарыда санап үтелгән гидроним һәм ойконимнарыннан без түбәндәгеләрнең этимологиясен ачыклый алабыз: Шүләнгер / Шеленгур ойконимы ике компоненттан тора: хакас., сельк., чулым., шор. **шул** «елга, инеш» («река, речка») + мар. **энгер** «елга, инеш» («река, речка»), ягъни елганың беренчел атамасы Шүләнгер була. Шулабаш ойконимы Шула елгасы атамасыннан килеп чыккан, ул я хакас. «елга, инеш»кә («река, речка») барып тоташа, я ике компоненттан тора: чув. **шу** + морд. **лей** «инеш» («речка»). Дөбьяз ойконимын дүрт компонентның кушылмасы дип карап була: эвен. **до** «елга» («река») + самод. **би** «елга» («река») + манси **я** «елга» («река») + хакас. **зай «инеш» (**«речка»). Бирли һәм Мөрәле / Мрали ойконимнары Бөреле һәм Мөрәле гидронимнарына барып тоташа. Ульязы ойконимы өч компоненттан тора: кетс. **уль** «су, елга («вода, река») + манси **я** «елга» («река») + хакас. **зай** «инеш» («речка»). Сасмак / Сасмачи ойконимында манси **сос**ны «чишмә» («ручей») аерырга мөмкин.

Казансу елгасы бассейнында шулай ук берлек сандагы исемнәр рәвешендәге ойконимнар да бар: Әйша (Айша), Әлдермеш (Алдермыш / Альдермыш), Берек (Брек), Гөберчәк (Губурчак), Әбрә (Ибра / Ибря), Кушлавыч (Кошлауч / Кошлоус / Кушлауч), Кер-Хайван / Курхайван / Курхойван, Поник, Сарай-Чокырча (Сарай-Чекурча), Сеҗе (Сиза), Сикертән (Сикертань / Сикертан), Таршна / Таршня-Чирша, Өмбе (Уньба), Үрнәк (Урняк), Рясь, Рязь, Юльба, Чемяк, Яваш.

Санап үтелгәннәрдән түбәндәге ойконимнарның килеп чыгышын ачыкларга мөмкин: 1) Ибра = ненец. **и**«су» («вода») + эвен. **бира** «елга» («река»). 2) Поник, чагыштыр: Поника, Поники, Поникий Ключ, Поникла елгалары. **Пониква** термины белән суы агым уңаена кибә барган елга тибын билгелиләр, чагыштыр: словак **пониква** «агым юкка чыккан урын». 3) Курхойван = хант. **кор** «сазлык» («болото») + эвенк. **хой** «сазлык» («болото») + ненец. **ванг** «тирән сөзәк чокыр, чокыр, уйсулык, ерым» («котловина, впадина, ложбина, овраг»), ягъни «сазлыклы уйсулык» («болотистая ложбина»). 4) Рясь, Рязь (чагыштыр: Ря, Ряса елгалары) = Ря елгасы + хакас. **сай / зай** **«**инеш**»** («речка»). 5) Сарай-Чекурча (чагыштыр: Сара елгасы) = фин.-уг. **сара** «кушылдык» («приток»). 6) Сиза (чагыштыр: Сизяшурка елгасы) = ненец. **сё** «ермак» («проток») + хакас. **зай** «инеш» («речка»), яисә кет. диал. **сис / сез** «елга» («река»). 7) Сикертән (чагыштыр:

Сикертмә, Секерка елгалары) = ненец. **сё** «ермак» («проток») + хант. **кор** «үсемлекләр басмаган, чиста, баткак саз» + ненец **танё** «күлгә коючы инеш». 8) Юльба (чагыштыр: Юл, Юлма елгалары) = төрк. **юл** «инеш» («речка) + самод. **ба** «елга» («река»).

Гидронимнар структурасына анализ аларның составына кет, тунгус-маньчжур, самодий, фин-угор һәм төрки гидрографик терминнары керүен күрсәтә. Этимологияләштерелгән ойконимнар таблицасын төзик:

| Елга | Кет | Тунг.-маньч. | Самод. | Фин-угор | Төрки | Тиңләштерелмәгән |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Азяк | | | | | өзек | |
| Суык-Су | | | | | суык+су | |
| Ия-Су | | | и | я | су | |
| Сула / Сыла / Сола | | | | | | |
| Арча / Әрчу | | | чу | әр | | |
| Бөреле | | бира | | лей | | |
| Бирәзә | | бира | | | зай | |
| Дөбьяз / Дубъязы | | до | би | я | зай | |
| Ульязы | уль | | | я | зай | |
| Шүләнгер / Шеленгур | | | | энгер | шул | |
| Шуман / Шуманы | | | | | шу+ман | |
| Сәрдә / Серда | | до | | сер | | |
| Ташкичуй | | | чу | кө | таш | |
| Шула | | | | лей | шу, шул | |
| Ибра | | бира | и | | | |
| Курхойван | | хой | ванг | кор | | |
| Сарай | | | | сара | | |
| Сикертән /Сикертань | | | сё, танё | кор | | |
| Юльба | | | ба | | юл | |
| Ылашман | | ула | | | шу+ман | |
| Муй | | му | | | | |
| Ямаширма | | | | я | ширма | ма |
| Сасмачи | | | чу | сос | | ма |
| Салмачи | | | чу | | сала | ма |
| Рясь/Рязь | | | | | сай/зай | ря |
| Күлтәс/Культесь | | | | | сай | те |

Таблицага анализ ясаганнан соң, түбәндәге нәтиҗәгә килергә мөмкин: гидронималарда кет терминнары, гадәттә – беренче, ә төр-

ки терминнар соңгы урында тора. Моннан тыш гидронимга бер үк вакытта бары төрле тел төркемнәренең бер мәгънәле лексемалары гына керә. Ул вакытта без Салмачи гидронимында **сала** термины төрки түгел, чөнки ул беренче урында тора, дип нәтиҗә ясый алабыз. Димәк, Сула гидронимының килеп чыгышы да төрки түгел. Юльба ойконимындагы **юль** дә төрки була алмый, мөгаен ул – кет телендәге **уль** «су» («вода»). Бер гидронимда бер мәгънәгә ия ике төрки терминның үзара кушылуын да кабул итеп булмый, димәк, аның **шу** форманты төрки түгел. Шүләнгер / Шеленгур гидронимында да **шул** термины төрки була алмый. Бу термин самодий телләрендә дә очраганлыктан, аны тиешле төркемгә күчерәбез. Без **ч** / **ш** чиратлашуының бу төркемдә генә очравын күрәбез, димәк, чув. **шу**ның «су» («вода») килеп чыгышы төрки түгел, ә самод. **Ря**ның тәңгәлләштерелмәгән топоформанты Ря гидронимын биргән, Иделнең борынгы мордва телендәге атамаларын искә төшерик – Ра, Рав, Раво. Аларны молд. **рыу**, рум. **риу**, порт. **рио**, ингл. Ривер «елга» («река»), бор. һинд. **райас** «агым» («поток, течение») белән чагыштырырга мөмкин. Урта Идел буенда субстрат һинд-европа гидронимы **Ря** һәм «елга» мәгънәсендәге **ра** / **рә** лексемасы сакланып калган дип уйлыйбыз.

Шулай итеп, гидронимнарны гибридлы исемнәр буларак анализлауның тәүге тәҗрибәсе элек билгеле булмаган күп кенә ойконим һәм гидронимнарның этимологиясен ачыкларга мөмкинлек бирә. Ә инде Себердәге фин-угор, төрки һәм башка халыкларның гидрографик терминнарының гидронимнар составында булуы бу халыкларның элек Урта Идел буенда яшәгәнлеген расларга мөмкинлек бирә. Безнең фикеребезчә, себер-төрки гидрографик терминнары һуннарның күчеше чорында, ягъни безнең эраның IV гасырыннан да соңга калмыйча кертелгәннәр. Һәм алар, татар терминнарыннан кала, иң соңыннан барлыкка килгәннәр. Калган барлык топоформантлар да алданрак килеп чыккан. Кет топоформантлары иң борынгылардан санала. Элегрәк монгол гидрографик терминнары Урта Идел буенда Алтын Урда чорында барлыкка килгән дип фаразлана иде. Безнең анализ биредә **сала** («кушылдык») монгол терминының тагын да иртәрәк барлыкка килүе турында сөйли.

Анализ гидронимнарның иң борынгы топонимнар булуын тагын бер кат исбатлый. Алар үзләрендә әлеге территориядә төпләнеп яшәгән борынгы халыкларның лексикасын һәм фонетикасын саклаганнар һәм, шул рәвешле, бу очракта Урта Идел буе халыкларының килеп урнашу тарихына, этногенезына үзенчәлекле ачкыч булып торалар.

Гидронимнарга этимологик анализ ясап, Урта Идел буенда яшәүче халыклар, алар миграциясенең чиратка салынганлыгы турында беренчел нәтиҗәләрне ясарга мөмкин. Урта Идел территориясендә Идел буе һәм Себернең фин-угор халыклары, Себернең самодий, тунгус-маньчжур һәм төрки халыклары, шулай ук Кара диңгез буендагы көньяк төрки халыкларының эзләре бар. Фин-угор катламы – иң борынгы катлам. Аннан соң я көньяк төрки, я Себер катламы килә,

алар төрле эзлеклектә чиратлаша да алалар. Иң югары катлам татар һәм чуваш телләреннән тора. Соңгы нәтиҗәләргә килү өчен, материалларны җентекләп статистик эшкәртү сорала.

**Әдәбият**


*Байчоров С.Я.* О протобулгарских географических названиях в верховьях Кубани // Вопросы взаимовлияния и взаимообогащения языков. Черкесск, 1978. 178 с.

*Гарипова Ф.Г.* Словарь гидронимов Татарии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984.

*Мурзаев Э.М.* Словарь народных географических терминов. М.: Мысль, 1984. 656 с.

*Радлов В.В.* Опыт словаря тюркских наречий. Т. 1–4. СПб., 1905.

Татарская АССР. Административно-территориальное деление. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986.

Труды Казанского филиала АН СССР. Серия энергетики и водного хозяйства. 2. Казань, 1959.



***Куряева Рауза Исмаил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент (Казан)*

УДК 81´367

***Л.Г. Хәбибуллина***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СИТУАТИВ ҺӘМ МОТИВЛЫ ХӘЛ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

Статья посвящена исследованию структурных особенностей и установлению характера взаимосвязи обстоятельственных отношений в татарском языке. Они являются сложными и многоплановыми, их типы как функционально-семантические категории характеризуются широкой семантической вариативностью, которая связана со сложной системой средств выражения этих смысловых отношений.

**Ключевые слова:** обстоятельственные отношения ситуативного плана, обстоятельственные отношения мотивировочного характера, синкретичная семантика, татарский язык.

The article is devoted to the study of structural features and establishment of the nature of the relationship of adverbial relations in the Tatar language. Adverbial relations are complex and multifaceted, their types as functional and semantic categories are characterized by a wide semantic variability, which is associated with a complex system of means of their expression.

**Keywords:** adverbial relations of situational plan, adverbial relations of motivational nature, syncretic semantics, Tatar language.

Синтаксик берәмлекләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләрен өйрәнү телнең коммуникатив асылын ачарга мөмкинлек бирә, шуңа бәйле рәвештә семантикага мөрәҗәгать итү тел белеменең хәзерге торышы өчен, һичшиксез, актуаль. Татар телендә еш кына синкретик мәгънә бәйләнешләре очрый, аларны җентекләп анализлау шундый төр мөнәсәбәтләрнең нигезен ачыкларга, телне бөтен тулылыгында аңларга ярдәм итә.

Семантик синтаксис тел белеменең XX гасырның икенче яртысында формалашкан юнәлеше булып тора. Лингвистика фәненең бу тармагы тел тамгаларының эчтәлек ягын һәм аның тышкы ягы белән туры килүен өйрәнә. Чит ил һәм рус галимнәре А. Вежбицкая, З. Вендлер, Ч. Филлмор, Н. Хомский, У. Чейф, Ю.Д. Апресян, Н.Д. Арутюнова, В.В. Богданов, А.И. Варшавская, В.Г. Гак, И.П. Иванова, Г.В. Колшанский, Е.С. Кубрякова, В.С. Храковский һ. б. семантик синтаксис үсешенә үз өлешләрен кертkәннәр.

Формаль, тышкы структураларга гына түгел, ә семантик структураларга да мөрәҗәгать итү күп кенә тел фактларын ачарга ярдәм итә, бу үз чиратында кешенең фикер эшчәнлеге закончалыкларын тулырак һәм төгәлрәк аңлатырга булыша. Шулай итеп, синтаксик конструкцияләрнең структур-семантик үзенчәлекләрен өйрәнү лингвистик планда гына түгел, ә когнитив планда да әһәмиятле.

Семантиканы өйрәнүнең кайбер башлангычлары Җамал Вәлиди хезмәтләрендә үк очраса да, тюркологиядә сөйләмнең семантик ягына мөрәҗәгать итү XX гасырның 60 нчы елларыннан башлана. Галимнәр Л.К. Бәйрәмова, М.В. Зәйнуллин, М.З. Зәкиев, С.М. Ибраһимов, М.А. Сәгыйтов, Ф.С. Сафиуллина, А.Н. Юлдашев тел конструкцияләрен функциядән – формаль якка юнәлешендә тикшерәләр.

XXI гасырдан башлап лингвистика фәнендә, шул исәптән татар тел белемендә дә, мәгънәви мөнәсәбәтләр, кагыйдә буларак, функциональ якын килү кысаларында өйрәнелә.

Хәл мөнәсәбәтләре үз эченә кергән бәйләнеш төрләренең күплеге белән дә, кулланылыш ешлыгы белән дә башка мәгънәви-синтаксик мөнәсәбәтләр арасында зур урын алып торалар. Теоретик һәм иллюстратив материалны анализлаудан күренгәнчә, семантикасы буенча аларны мотивлы һәм ситуатив пландагы хәл мөнәсәбәтләренә бүлү максатка ярашлы.

Ситуатив пландагы хәл мөнәсәбәтләре күренешләрнең тышкы бәйлелеген күрсәтә, аларга, компонентлары арасындагы синтаксик мөнәсәбәтләрнең характеры буенча, пространство һәм вакыт мөнәсәбәтләре керә. Тышкы бәйләнеш мөнәсәбәте булып саналуларына карамастан, алар катлаулы эчке структурага ия. Пространство һәм вакыт мөнәсәбәтләре синтаксик берәмлек төзүдә мөһим роль уйныйлар, чөнки текстның вакыйгалылыгын барлыкка китерүдә катнашалар. Тел белемендә аларны өйрәнү төп ике юнәлештә алып барыла: беренчесе тел структурасының пространство-вакыт нигезләрен өйрәнүне күздә тота; икенчесе конкрет телләрдә, аларның белдерелүенең лексик-семантик типологиясен барлыкка китерү максаты белән, пространство һәм вакыт категорияләренең мәгънәсен анализлау белән бәйле.

Пространство семантикасы телдә урын һәм юнәлеш мәгънәләрендә чагылыш таба. Әлеге мөнәсәбәт турында фикер йөрткәндә, гадәттә, аерым предметларның пространство характеристикасы күзаллана.

Төрки тел белемендә бу категория белдерелү планы ягыннан А.Т. Додуева (карачай-балкар телендә), Р.А. Иманалиева (казакъ телендә), И.А. Невская (шор телендә), Ю.У. Хочавова (комык телендә) хезмәтләрендә өйрәнелгән. Моннан тыш, тюркологлар урын хәлләре, пространство мәгънәле килешләр, бәйлек һәм бәйлек сүзләрне өйрәнгәндә, теге яки бу дәрәҗәдә әлеге мәсьәләләрне яктырталар.

Ситуатив пландагы хәл мөнәсәбәтләре, бигрәк тә пространство мөнәсәбәте, башка хәл мөнәсәбәтләренә караганда күбрәк конкретлыкка ия. Татар телендә ул лексик-синтаксик категория, чөнки еш кына әлеге мөнәсәбәтләр системасын лексема буларак аерым сүзләр түгел, ә сүзләрнең синтаксик формалары тәшкил итә: *Менә аларны тау битендәге коры* ***җиргә*** *китереп ташладылар* (Ф. Бәйрәмова).

Пространство семантикасы сәбәп-нәтиҗә мәгънәсе белән катлаулана ала. Мәсәлән: *Караңгыда берни дә күренми иде; Беркем дә комачауламаслык тыныч бүлмәдә фикер алышырга уйладылар.*

Вакыт мөнәсәбәте процессларның, вакыйгаларның бер үк вакытта яки бер-бер артлы башкарылуын белдерә, еш кына башка мәгънә мөнәсәбәтләре белән катлаулана (мәсәлән, максат, шарт, кире шарт, сәбәп-нәтиҗә).

Максат-вакыт мәгънәсе вакытка мөнәсәбәтле максатчан эшчәнлекне белдерә: ***билгеләнгән вакытка*** *килү*.

*Әлеге конференция галимнең* ***100 еллыгына*** *оештырылды* тибындагы мисалларда эш-хәлнең билгеле бер срокка тәмамлануына омтылыш төсмере бар.

Иярчен урын җөмләнең хәбәре хәл фигыль формасы белән белдерелгәндә, пространство һәм вакыт мөнәсәбәтләре бәйләнеше күзәтелә. Мәсәлән: *Алар Казанга барып җит****кәнче****, ул юл читендәге халыкка вак акча сибеп барды* (Р. Зәйдулла).

Мотивлы мөнәсәбәтләргә сәбәп-нәтиҗә, максат, шарт һәм кире шарт мөнәсәбәтләре керә. Әлеге төр мөнәсәбәтләргә нәтиҗә өлешенең иярчен җөмләдәге эш-хәл белән мотивлашкан булуы хас. Бербересе белән тыгыз бәйләнештә торганлыктан, тел белемендә галимнәрнең аларны классификацияләүгә карашлары төрле.

Лингвистик әдәбиятта кире шарт мәгънәсен белдерә торган төзелмәләрнең генезисы мәсьәләсенә төрле фикерләр очрый. Әлеге төр төзелмәләр формасы буенча да, мәгънәсе буенча да каузаль, кондициональ, темпораль мөнәсәбәтләр белән бәйләнгәнлектән, комплекслы семантикага ия, башка хәл мөнәсәбәтләре арасында аларны иң катлаулысы дияргә була. Мәсәлән: *Әле кояш күтәрелмәсә дә, офык читләре агарып, таң шәүләсе төнне кысрыклаган мәл* (И. Иксанова); *Табынга, еллар авыр булуга карамастан, кызыл эремчек, бавырсак, ак май, кәрәзле бал куелды, буларын бөркеп, табагы белән бәрәңге килеп утырды* (Г. Ахунов); *Кышкы карлар күпме ак булмасын, Тәрәзләргә пычрак сылана* (М. Шабаев).

Күпчелек галимнәр (В.А. Богородицкий, Н. Баскаков) кире шарт мәгънәсен шарт мәгънәсе белән якынлаштыра. Н.К. Дмитриев аны шарт мөнәсәбәтенең бер төре дип саный [Дмитриев, 1940, б. 200]. Кире шарт мөнәсәбәтләрен сәбәп һәм инкяр комбинациясе дигән караш та бар, чөнки әлеге төр конструкцияләрдә, тормышка ашырылуы өчен кирәкле шартлар булып та, көтелгән нәтиҗәнең булмавы белдерелә. Кире шарт мөнәсәбәте каршы кую мөнәсәбәте белән дә тыгыз бәйләнештә: *Эт өрер – бүре йөрер* (Мәкаль).

Кире шарт конструкцияләрендә өстәмә сәбәп мәгънәсе дә була, нәтиҗә – көтелгәннең капма-каршысы. Көтелгән һәм фактик нәтиҗә арасындагы мәгънә бәйләнеше капма-каршы куюга нигезләнә һәм әлеге төр мөнәсәбәтне барлыкка китерә. Шулай итеп, кире шарт конструкциясендә башлангыч һәм нәтиҗә өлешләре генә эксплицит рәвештә белдерелә, ә алар арасындагы компонент имплицит өлкәгә карый.

*Һава торышы начар булса да, без урамга чыктык* кебек җөмләләрдә, гадәттә, үзара бәйләнми торган вакыйгалар тасвирлана һәм алар бәйләнешенең табигый булмавы белдерелә.

Үзендә шарт һәм вакыт мәгънәләрен берләштергән конструкцияләргә карата да фикерләр төрле. Татар телендә синкретик шарт-вакыт мәгънәсе я шарт, я вакыт мөнәсәбәтләре кысаларында карала.

Шарт формасы даими һәм периодик кабатлана торган күренешләр бәйләнешен белдергәндә, шарт һәм вакыт семантикасының үзара керешүе күзәтелә. Мәсәлән: *Матур парлар күрсәм – куанам...* (С. Сөләйманова).

Мондый җөмләләр башлыча эчтәлеге гомуми характерга ия мәкаль һәм әйтемнәрдә, гомумиләштергән әйтелмәләрдә очрый: *Белмисез – өйрәтербез, теләмисез – мәҗбүр итәрбез!* (Г. Ахунов); *Чулпан туды – таң атты; Вакытың үтте – бәхетең китте.*

Мисаллардан күренгәнчә, хәл мөнәсәбәтләре имплицит рәвештә теркәгечсез кушма җөмлә компонентлары арасында да урнаша ала. Шарт-вакыт мөнәсәбәтләрендә, шарт мөнәсәбәтләреннән аермалы буларак, күренешләрнең фараз ителгән бәйләнеше түгел, ә күпчелек очракта реаль чынбарлыкта булган бәйләнеш белдерелә. Кондициональ конструкцияләрдә шарт һәм нәтиҗә булуы мөмкин / булуы мөмкин түгел буларак аңлашыла. Шарт-вакыт мөнәсәбәтләренең вакыт мөнәсәбәтләреннән төп аермасы – аларның очраклы, тышкы характердагы күренешләргә түгел, ә бер вакыйганың икенчесеннән эчке бәйлелеген күрсәтүдә. Димәк, алар вакыт мөнәсәбәтләреннән катлаулырак булып чыга.

Татар телендә, гадәттә, вакыт мәгънәсен белдерүдә кулланыла торган *-ганда/-гәндә* формасы вакыт төсмерле шартны да белдерә ала: *Гыйлем булма**ганда**, бар акыл да юк була* (Мәкаль); *Гаиләдә татулык бул**ганда**, эшләр уңай бара* (Мәкаль); *Әйт**кәндә** сүзеңчә эшлә, әйт**мәгәндә** уеңча эшлә* (Мәкаль); *Газ исе сиз**гәндә**, 04 телефоны буенча хәбәр итегез; Әмма җиңәргә кирәк бул**ганда**, дошманыңның коралыннан да файланырга мәҗбүр буласың* (Р. Зәйдулла).

*-ганда/-гәндә* формасының шарт мәгънәсендә дә кулланылуын гомумтөрки күренеш дип әйтергә мөмкин. Мондый конструкцияләр башка төрки телләрдә дә шактый еш очрый.

Күргәнебезчә, *-ганда* формасы вакыт һәм шарт мәгънәләре арасында торучы мөнәсәбәт барлыкка китерә, шуңа бәйле рәвештә кондициональ-темпораль дип санала ала.

Каузаль семантика да имплицит рәвештә белдерелә ала. Гадәттә, бу очракта идарә итеп булмый торган ситуация турында хәбәр ителә. Мондыйларга, мәсәлән, табигать күренешләре һәм кешенең психик-эмоциональ яки физиологик халәте белән бәйле ситуацияләр керә. Мәсәлән: *Көннәрнең иң кыска чагы, бик тиз караңгы төште* (Ә. Еники); *Төнлә ишеп кар яуган, җир өсте ап-ак иде* (Х. Сарьян); *Аның биленнән еш кына радикулит китереп тота, иелеп эш эшләү аның өчен авыр иде* (Х. Сарьян); *Анда корыган үлән шактый куе һәм биек иде, кышкы көтү өчен аннан да яхшырак җирнең булуы да мөмкин түгел иде* (Н. Фәттах).

Имплицит рәвештә сәбәп-нәтиҗә белдерүче идарә итеп булмый торган ситуацияләргә җәмгыятьтә кабул ителгән кагыйдәләрне тасвирлау да керә. Мәсәлән: *Аларның кайгыруын хатын-кыз читтән генә карап тын торды, хатын-кыз тавышы белән мәрхүмнең рухын рәнҗетергә ярамый иде* (Р. Зәйдулла).

Күргәнебезчә, мондый теркәгечсез кушма җөмләләрнең беренче өлеше чагыштырмача мөстәкыйль. Икенче предикатив берәмлектә шулай ук бәйлелекнең формаль күрсәткечләре юк. Компонентлар бәйләнеше җөмләнең гомуми эчтәлегеннән чыгып билгеләнә.

Татар телендә бер үк бәйләүче чаралар төрле мәгънә мөнәсәбәтләрен белдерү өчен кулланыла алалар. Әйтик, фигыльнең юклык формасы кушымчасы кире шарт мәгънәсен дә, шарт мәгънәсен дә белдерә. Мәсәлән: *Күпме как**ма**, ничек типкәлә**мә**, Тайпылмадым туры юлдан мин* (М. Хөсәен) (кире шарт). Әлеге форманың шарт мәгънәсен белдерүе паремияләрдә еш очрый, әмма аларда, мисалларны анализлаудан күренгәнчә, сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтен дә күрергә була: *Кешене карга**ма**, үзеңә төшәр*; *Гаепсез аш эзлә**мә**, ач калырсың; гаепсез дус эзлә**мә**, ялгыз калырсың.*

Татар телендә вакыт мәгънәсен белдерә торган теркәгеч ролендә килгән сүзләр сәбәп-нәтиҗә яки шарт мөнәсәбәтен күрсәтә ала. Мондый конструкцияләрдә сәбәп-нәтиҗә һәм шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтләре грамматик аерылмый. *Кулында китап бул**ган**ның башында гыйлем булыр* (Мәкаль); *Сүз хикмәтен бел**мәгән** кешенең михнәте күп* (Мәкаль) тибындагы мисалларны да ике төрле аңлатып була: *Кулында китап бул**са**, башында гыйлем булыр*; *Кеше сүз хикмәтен бел**мәсә**, михнәте күп* яки: *Кулында китап булган**лыктан**, башында гыйлем булыр*; *Сүз хикмәтен белмәгән**лектән**, кешенең михнәте күп.*

Татар телендә, гадәттә, вакыт мәгънәсен белдерә торган *-гач* хәл фигыль формасы сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтен дә, шарт семантикасын да күрсәтә ала. Мәсәлән: *Һич уенда юк кызык, дәрсем хәзерләп куйма**гач*** *(*Г. Тукай) җөмләсендә – сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәте, ә *телә**гәч*** *сынасыннар* (Р. Миңнуллин) мисалында шарт мәгънәсе белдерелә.

Кондициональлек сынамыш һәм ышануларның нигезен тәшкил итә. Мисалларны анализлаудан күренгәнчә, табигать күренешләре белән бәйле паремияләрдә еш кына нәтиҗә-вакыт мәгънәсе була: *Салават күпере төньягында чыкса, яңгыр бул**маска***; *Баткан урын ачык булмаса, яңгыр бул**ырга***; *Ай чалкан туса, көннәр аяз**ырга***; *Болыт кыйблага таба барса, көн аяз**ырга**.*

Максат-вакыт мәгънәсе вакытка мөнәсәбәтле максатчан эшчәнлекне белдерә: *Әлеге конференция галимнең **100 еллыгына** оештырылды* тибындагы мисалларда эш-хәлнең билгеле бер срокка тәмамлануына омтылыш төсмере бар.

Шулай итеп, күренешләрнең эчке бәйләнеше булган хәл мөнәсәбәтләренең семантикасы җөмлә яки контекстның мәгънәви эчтәлеген логик анализлау юлы белән ачыклана. Татар телендә бик еш мәгънәви мөнәсәбәтләрнең үзара керешүе күзәтелә. Аларны аеру бер үк

формаль күрсәткечләрнең, бәйләүче чараларның төрле семантика белдерүдә кулланылуы белән дә катлаулана.

**Әдәбият**

*Дмитриев Н.К.* Грамматика кумыкского языка. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1940. 205 с.

Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. һәм автор М.З. Зәкиев. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2017. III т. 536 б.

*Хабибуллина Л.Г.* Смысловые отношения в татарском языке: сравнительно-типологический аспект. Казань: ИЯЛИ, 2017. 256 с.

***Хәбибуллина Лениза Газинур кызы,***
*филолоия фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының диалектология һәм лексикология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 801.82

*И.Г. Гомәров*

# БОЛГАР ЧОРЫ ӘДӘБИЯТЫН ӨЙРӘНҮДӘ ЯҢА ЯЗМА ЧЫГАНАК: СӨЛӘЙМАН БИНЕ ДАУД СУВАРИНЫҢ «ЗӨҺРӘТ ӘР-РИЙАЗ...» ӘСӘРЕ

Данная статья посвящена исследованию малоизученного письменного памятника периода Волжской Булгарии – «Зухрат ар-рийаз...» Сулеймана бин Дауда Сувари. На основе многочисленных литературных и исторических источников автор раскрывает роль Сулеймана бин Дауда Сувари в формировании литературы Волжской Булгарии.

**Ключевые слова:** литература Волжской Булгарии, Таджаддин Булгари, Большой тирйак, фармакогнозия, Сулейман бин Дауд Сувари, Зухрат ар-рийаз, медиевистика, исламское богословие.

This article is devoted to the study of a little-studied written monument of the period of Volga Bulgaria – «Zukhrat ar-riyaz...» by Suleiman bin Daoud Suvari. Based on numerous literary and historical sources, the author reveals the role of Suleiman bin Daoud Suvari in the formation of the literature of Volga Bulgaria.

**Keywords:** Literature of Volga Bulgaria, Tajuddin Bulgari, Big Tiryak, pharmacognosy, Suleiman bin Daoud Suvari, Zuhrat ar-riyaz, Medieval studies, Islamic theology.

Быел киң җәмәгатьчелек Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу тарихи датасын билгеләп үтәргә җыена. Әлеге чара тагын бер кат дөнья цивилизацияләре тарихында татарларның ата-бабалары нигез салган Болгар дәүләтенең тоткан урынын һәм әһәмиятен барларга, Болгар чоры мәдәниятенең, шул исәптән сүз сәнгатенең үзенчәлекләре турында сөйләшергә уңай форсат тудыра.

Бүген Идел буе Болгар дәүләтенең икътисади-мәдәни алгарышы хакында нәшер ителгән күпсанлы фәнни язмалар, фәнни-популяр басмалар белән танышырга мөмкин. Шәрык һәм Европа галимнәре хезмәтләрендә, Шиһабеддин Мәрҗани (1818–1889), Морад Рәмзи (1855–1934), Ризаэддин Фәхреддин (1859–1936) кебек татар галимнәре язмаларында телгә алынган дистәләрчә болгар галимнәре, рухани һәм язучыларының исемнәре татар-төрки тарихы буенча мәгълүматы булган укучыга яхшы таныш. Алар арасында X–XIV гасырлар аралыгында яшәгән Ягъкуб бине Ногман Болгари, Хуҗа Әхмәд Болгари, Әбелгаля Хәмид бине Идрис Болгари, Ибраһим бине Хозыр Болгари, шәех Мөхәммәд Болгари, Таҗеддин бине Йуныс Болгари, Ибраһим бине Йосыф Болгари, Садреддин бине Галәведдин Болгари, Хәсән бине Гомәр Болгари һ.б. күренекле шәхесләрнең исемнәре бар.

Урта гасырлар мөселман дөньясында бу затларның күпчелеге мөхтәрәм голямалардан саналган, аларның шәригать кануннары, әдәп-әхлак мәсьәләләре, тарих һәм тыйб гыйлемнәренә мөнәсәбәтле төрле хезмәтләр язып калдырганлыклары мәгълүм. Мисал өчен, Болгарда казый булып торган Ягъкуб Болгариның әлеге ил тарихына багышланган китап язуы хакында билгеле. Шулай ук Хуҗа Әхмәд Болгариның «әт-Тарикать», «Фәваид әл-Җаваһир», «әл-Җамигъ» хезмәтләре, шәех Мөхәммәд әл-Болгариның «Хәзинәт әл-голяма вә зиннәт әл-фөкаһә», Ибраһим бине Йосыф Болгариның «Шәрх Адәб әс-сәхаиф», Ибрахим бине Хозыр әл-Болгариның «Осул әл-Хөсами» исемле хезмәтләре булуы турында Мөхәммәд әл-Бәздәви (1010–1089), Гобәйдулла әл-Мәхбүби әл-Бохари (Садр әш-Шәрига әл-Әсгар, 1346–1347 елларда вафат), Хаҗи Хәлифә (Кятиб Чәләби, 1609–1657) кебек мәшһүр дин галимнәре язып калдырганнар [Рәмзи, б. 317–329].

Борынгы чор һәм Урта гасырлар язма сүз сәнгатенең үзенчәлекләре турында ышанычлы һәм төпле фикер тудыру өчен, иң беренче чиратта, шул гасырларда иҗат ителгән текстларның булуы шарт. Болгар чоры мәдәнияте турында сөйләгәндә, әлеге җирлектә туган яки бу төбәктән чыккан шәхесләр каләменнән төшкән ядкярләрнең бик аз күләмдә генә сакланып калуы күзгә ташлана. Узган гасырның туксанынчы елларына кадәр болгар-татар мәдәниятенең югары үсешкә ирешкәнлегенә ышанычлы дәлил вазифасын Кол Галинең «Кысса-и Йосыф» дастаны үтәп килде. Шагыйрьнең сәнгати осталыгы, әсәрнең нигезенә яткан идея-эстетик фикерләрнең фәлсәфи тирәнлеге, рухани әдәбиятка ныклы бәйләнеше һәм үзеннән соңгы татар сүз сәнгатенә көчле тәэсире җәһәтеннән әлеге ядкяр болгар-татар сүз сәнгатен өйрәнүдә текстлар җитешмәү мәсьәләсен икенчел планга күчерергә ярдәм итте. Дөрес, XIX гасырда ук Шиһабеддин Мәрҗани татарлар тарафыннан яратып укылган берничә әдәби әсәрне, шул исәптән, «Кисекбаш» китабын Болгар чорында иҗат ителгән әсәр буларак телгә алган иде. Әмма ул заманда да, аннан соңгы дәвердә дә әдәбият галимнәре тарафыннан Мәрҗани карашларын тәфсилле раслаган яки дәлилле рәвештә кире каккан фикерләр әйтелмәде.

Узган гасырның туксанынчы елларында татар галимнәре тарафыннан Болгар чорында язылган ядкярләрне барлау хәрәкәте активлашып китә. Әлеге эшчәнлек нәтиҗәсендә 1996 елда университет профессоры М.Г. Госманов Иран архивларында сакланып, безнең көннәргә килеп ирешкән «Әт-Тирйак әл-кәбир» (Зур тирйак[1]) кульязмасының копияләрен алдыра. XIII гасырның беренче яртысында яшәгән Болгар табибе Таҗеддин Болгариның фармакогнозия өлкәсенә караган әлеге хезмәтен күренекле шәрыкшенас Ә.Б. Халидов гарәп теленнән рус теленә тәрҗемә итә һәм аерым бер китап рәвешендә бастырып чыгара [Таджаддин ал-Булгари]. Шул рәвешле Идел буе Болгар дәүләте мәдәниятенә бәйләнешле тагын бер хезмәтнең тексты

[1] Тирйак – агулануга каршы дәва, дару.

фәнни әйләнешкә тәкъдим ителә. Шунысы мөһим, әлеге әсәр кульязмасының Иран архивларында саклануы турында галим Габдрахман Таһирҗанов 1979 елда ук «Тарихтан – әдәбиятка» исемле китабында искәртеп уза. Күргәнебезчә, бары тик ике дистә елга якын вакыт үткәннән соң гына, «Әт-Тиръяк әл-кәбир» ядкяре кабат фән мәйданына кайтарыла. Таҗеддин Болгариның тыйб гыйлеменә караган тагын ике рисаләсе – «Мохтасар фи мәгърифәт әл-адвийә» (Гади даруларны ясау турында кыскача трактат) һәм «Әл-Адвиййә әл-муфрада» (Гади дарулар) исемле хезмәтләре белгечләр тарафыннан текстологик эшкәртелеп, рус һәм татар телләренә тәрҗемә ителү чиратын көтә бирә. Бу – һичшиксез, борынгы язма мирасыбызны кайтару һәм таныту өлкәсендәге төп бурычларыбызның берсе.

«Әт-Тиръяк әл-кәбир» кебек үк барлыгы мәгълүм, әмма тулы тексты бүгенгә кадәр фән мәйданына куелмаган тагын бер чыганак – Сөләйман бине Дауд Суваринең «Зөһрәт әр-рийаз вә нөзһәт әл-колүб әл-мирадз» (Бакчаларның матурлыгы һәм авыру күңелләрнең юанычы) исемле әсәре.

Әлеге әдипнең иҗаты турында беренче мәгълүматлар госманлы галиме Хаҗи Хәлифәнең «Кәшф әз-зөннун...» исемле китабында китерелә. Урта гасырларның ышанычлы библиографик чыганакларыннан саналган бу хезмәттәге мәгълүматлардан Сөләйман бине Дауд Суваринең башта фарсы телендә вәгазь жанрына караган «Бәһҗәт әл-әнвар мин хафият әл-әсрар» (Күңел серләрен яктырткан нурлар чаткысы) исемле әсәр язуы, аннан аны «Нөзһәт әл-колуб әл-мирадз» (Авыру күңелләрнең юанычы) исеме астында гарәп теленә тәрҗемә итүе, соңыннан, текстка Коръән аятләре һәм хәдисләр өстәп, бу хезмәтен «Зөһрәт әр-рийаз» исеме белән атавы аңлашыла [Хәлифә Хаҗи, б. 257].

Сөләйман бине Дауд Суваринең «Зөһрәт әр-рийаз...» исемле әсәр язганлыгы мәгълүм булса да, аның кульязмалары XX гасыр азагына кадәр татар медиевистикасы фәне өчен билгеле булмый. Дөрес, Шиһабеддин Мәрҗани әлеге әсәрнең бер нөсхәсе үз кулында булганлыгын хәбәр итә, Морад Рәмзи *«Мәккәдә яшәгән вакытымда «Зөһрәт әр-рийаз...»ның таркау һәм борынгы бер кульязмасын үзем дә күрдем. Аның һәр мәҗлесе остазы һәм шәехе Хәмид казый тарафыннан сөйләнгән хәдис белән башлана, шуннан мин дә берсен үземә күчереп алган идем»*, дип искәртә [Рәмзи, б. 325]. XX гасырның соңгы чирегендә Төркиянең Төп Капу музеенда бу ядкярнең бер күчермәсе саклануы мәгълүм була. Шушы ук вакытларда тарихчы галим Сөләйман Рәхимов тарафыннан Төркиянең «Сөләймания» китапханәсе фондларында «Зөһрәт әр-рийаз...»ның берничә кульязма нөсхәсе барлыгы ачыклана һәм араларыннан иң борынгысының копиясе алына. Тәбриз шәһәрендә 1329 елда Госман бине Мөхәммәд әр-Рухи әл-Әнкари исемле кеше тарафыннан күчереп язылган бу нөсхәнең күчермәсе бүген Татарстан Милли китапханәсе фондларында саклана. Моннан тыш Россия, Төркия, Иран, Мисыр, Голландия, Франция, Германия кебек илләр

архивларында бу әсәрнең өч дистәгә якын кулъязма күчермәләре барлыгы ачыкланды [Гомәров, б. 50–54]. Аларның кайберләре тулы вариантта, кайберләре исә мөнтәхәб, ягъни кыскартылган яки сайлап тупланган шәкелдә күчерелгәннәр. Әйтик, Төркиядә аларның саны дистәдән артып китә: иң борынгы нөсхәсе – югарыда телгә алынган «Сөләймания» китапханәсендә «Tirnovali 968» шифры белән саклаучы кулъязма.

Сөләйман бине Дауд Сувари яшәгән һәм иҗат иткән чор Идел буе Болгар дәүләтенең монгол яуларына кадәрге дәверенә туры килә. Хаҗи Хәлифә кулында әлеге әдипнең туган, үлгән еллары турында төгәл мәгълүматлар булмаган, күрәсең, шуңа ул «Кәшф әз-зөннун» китабында аның вафат булу датасын күп ноктала белән генә искәртеп уза. Шулай да Сөләйман бине Дауд Суваринын яшәгән чорын, аның үз әсәрендә китерелгән аерым бер мәгълүматларга нигезләнеп, якынча билгеләргә мөмкин. «Зөһрәт әр-рийаз»ның кайбер мәҗлесбүлекчәләре Болгар иленең казые, галим Әбел Галя Хәмид бине Идрис әл-Болгари тарафыннан җиткерелгән хәдисләр белән башлана. Сөләйман бине Дауд Сувари аны үзенең остазы дип атый, әсәрендә китерелгән күп кенә хикәятләрне аннан ишеткәнлеген искәртә. Бу шәхеснең һиҗри ел исәбе белән 500 – милади белән 1106/07 елларда әле исән булуы мәгълүм [Мәрҗани, б. 79]. Хәдисләрне җиткерүчеләр чылбырына игътибар итсәк, Болгар казыеның аларны XII гасыр башында әле исән булган Әбү Бәкер Мөхәммәд бине Гомәр әл-Баззар (1106 елда үлгән), Әбү Бәкер Мөхәммәд бине Хәсән бине Мансур эн-Нәсәфи әл-Гавидни (1111 елда үлгән), Әбү әл-Мөгыйн эн-Нәсәфи (1114 елда вафат), Әбү Бәкер Мөхәммәд бине Габдулла әс-Сәрхәкәти (1123 елда вафат) кебек мәшһүр галим һәм мөхәддисләр – хәдис җыючылар авызыннан ишеткәнлеге күренә. Димәк, Әбелгаля Хәмид бине Идрис Болгарига хәдисләрне шушы галимнәр тапшырса, Сөләйман бине Дауд Сувари аларны үз остазыннан ишеткән булып чыга. Шуннан чыгып, Сөләйман бине Дауд Сувари яшәгән һәм иҗат иткән чорны XII гасырның беренче яртысына тәгаенләргә мөмкин. Шулай ук ул мөрәҗәгать иткән авторларга күз ташласак та, аларның мөселман дөньясының төрле төбәкләрендә XII гасырга кадәр яшәгән һәм иҗат иткән шагыйрьләр булуы ачык күренә. Җаһилият чоры шагыйре әл-Хансә (Тумадир бинте Әмр әс-Суламия, 575–645), өммәвиләр һәм габбасилар дәвере гарәп шигърияте мәктәбе вәкилләре Күсәйир Газзә (660–723), Әбү Сахр әл-Һузили (699 елда вафат), Габбас бине әл-Әхнәф (750–808), Халид бине Йәзид әл-Багдади (882 елда вафат) һ.б. әнә шундыйлардан.

Җыеп әйткәндә, югарыда искәртелгән фактлар Сөләйман бине Дауд Суварины ислам диненең асыл нигезләрен, Коръән һәм сөннәтне, шәригать кануннарын, классик гарәп шигъриятен яхшы белгән рухани һәм әдип буларак таныта, шул ук вакытта «Бәһҗәт әл-әнвар...», «Зөһрәт әр-рийаз...» әсәрләрен Болгар чоры татар сүз сәнгатенең бүген фәнгә мәгълүм беренче язма ядкярләреннән дип карарга мөм-

кинлек бирә. Дөрес, тарихи чыганаклар бу чорда язылган башка хезмәтләр булуы турында да хәбәр итәләр. Әйтик, 1135–1136 елларда Болгарда булып киткән гарәп сәяхәтчесе Әбү Хәмид әл-Гарнатый (1080–1170) үзенең мәгълүм хезмәтендә бу илнең казые Ягъкуб бине Ногман белән очрашуы, аның «Тәварихе Болгария» (Болгар тарихы) исемле әсәр язуы турында искәртә, аннан кайбер мәгълүматлар китерә [Путешествие..., с. 31, 61]. Кызганыч ки, бу әсәрнең тексты бүген фәнгә мәгълүм түгел.

X–XII гасырларда Идел буе Болгар дәүләте, икътисади-сәяси һәм дини-мәдәни үсеш җәһәтеннән караганда, шул чордагы Европа һәм Шәрык дәүләтләре арасында алдынгы илләрнең берсе санала. Утрак тормыш, ислам байрагы астында монотеистик фәлсәфәнең идарәчелек нигезенә ятуы, Хәзәр дәүләте йогынтысыннан арыну, Европа һәм Шәрык илләре, рус кенәзлекләре белән тыгыз сәүдә һәм дипломатик мөнәсәбәтләрдә тору бу төбәктә икътисади һәм дини-мәдәни алгарыш өчен уңай җирлек тудыра. Биредә ике йөзгә якын эреле-ваклы кала һәм салаларның яшәп килүе, аларда һөнәрчелек һәм сәүдәнең чәчәк атуы илнең сәяси һәм икътисади-мәдәни үсеш ягыннан алга китүе хакында сөйли. Әлеге шартларда сүз сәнгатенең югары дәрәҗәгә ирешүе, тәгаенләп әйткәндә, руханият, гыйлем һәм әдәбият мәйданында Ягъкуб бине Ногман Болгариның «Тәварихе Болгария», Сөләйман бине Дауд Сувариның «Зөһрәт әр-рийаз...», Таҗетдин бине Йуныс Болгаринең «Әт-тиръяк әл-кәбир» кебек хезмәтләре барлыкка килү гайре табигый хәл түгел, әлбәттә. Кол Галинең бер гасыр соңрак язылган мәшһүр «Кыйсса-и Йосыф» әсәрен дә энә шул чорда формалашкан мәдәни алгарыш традицияләре нигезендә иҗат ителгән ядкяр дип карау дөрес булыр.

«Зөһрәт әр-рийаз» әсәренең композицион корылышы Урта гасырлар Шәрык әдәбияты традицияләре кысаларында башкарылган: ул кереш, алтмыш җиде мәҗлес һәм йомгак өлешеннән гыйбарәт. Мәҗлесләрнең исемнәре тәртип саннары һәм Коръәннән китерелгән аятьләр белән тәгаенләнгән. Мисал өчен, тәүге бүлек «Аллаһы Тәгаләнең «Тәхкыйк, Без Адәмне саф балчыктан яраттык» сүзләре турында беренче мәҗлес», унберенче бүлек «Аллаһы Тәгаләнең «Муса үзенең кавеме өчен су сорады...» сүзләренә карата унберенче мәҗлес», кырык тугызынчысы «Аллаһы Тәгаләнең «Сезгә үз арагыздан бер Рәсүл килде» дигән сүзләре хакында кырык тугызынчы мәҗлес» дип атала. Мәҗлесләрнең эчке төзелешендә дә билгеле бер тәртип, хикәяләнү рәвеше өстенлек итә. Һәр мәҗлес исемдә яңгыраган Коръән аятьләрендәге фикерне дәлилләү өчен китерелгән хәдис – Мөхәммәд пәйгамбәрнең сүзләре белән башланып китә. Әйтик, җиденче мәҗлеснең исемендә Коръәннең «Гыймран» сүрәсеннән алынган *«Әйт: «Әгәр Аллаһны яратсагыз, минем арттан барыгыз»* аяте урын алган. Бу аятьнең асыл нигезендә яткан «ярату» төшенчәсен тулырак ачу өчен бүлек башында *«Иманга килмичә, сез җәннәтле була алмассыз, ә бер-берегезне яратмый торып, иманлы була*

*алмассыз. Сезгә бер-берегезне яраттыра торган изге гамәлне күрсәтергәме икән? Үзегез арасында сәламнәрне таратыгыз»* дигән хәдис китерелә. Алга таба автор тарафыннан мөселманнар арасында булырга тиешле яхшы мөгамәлә, бер-береңә игътибарлы булу, һәрдаим ярдәм итешеп яшәү, туганнар арасындагы яхшы мөнәсәбәтләрнең күркәм сыйфатлары хакында сөйләнә. Сөләйман бине Дауд Сувари үз фикерләрен Мөхәммәд пәйгамбәрнең эш-гамәлләрен үрнәк итеп китерү юлы беләнраслый, *«Рәсүлуллаһ (аңа Аллаһның сәламе булсын) Сәгъ бине әр-Рәбигъ һәм Габдрахман бине Гәуф арасында кардәшлек мөнәсәбәтләре урнаштырды. Бу намуслылыкта һәм тәкъвалыкта, гөнаһлардан һәм дошманлыктан саклануда бер-береңә булышу өчен, чит кешеләр арасында кардәшлек урнаштыру мөмкинлегенә ишарә булып тора»,* дип белдерә.

Сөләйман бине Дауд Сувари фикеренчә, югарыда искәртелгән күркәм әхлак сыйфатларының нигезендә ярату хисе ятарга тиеш. Ислам динендәге ир һәм хатынның бер-берсен яратуы, ата-ананың балаларына мәхәббәте, туганнарның бер-берсен якын итүләре, Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сахабәләрен ярату – болар барысы да инсанның Аллаһы Тәгаләгә карата булган риясыз һәм чиксез мәхәббәтенең чагылышлары. *«Кодрәтле һәм бөек Аллаһ әйткән: «Дөреслектә, иманучылар – кардәшләр». Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе булсын) әйткән: «Аллаһы Тәгаләнең яшерен серләренең берсе – Кодрәтле һәм бөек Раббыңның ризалыгы өчен башка кешене яратып, иманлы булуның рәхәтен табу». Аллаһка мәхәббәт дигәндә, Аның ризалыгын китереп чыгаручы бар нәрсәгә карата мәхәббәт күздә тотыла: Аның гүзәл фатыйхасына, матур бүләкләренә, изгелекләргә рәхмәтенә, күндәмлеккә әҗеренә. [...]*

*Аллаһтан килгән изгелек – мәңгелек. Калган бар нәрсә – вакытлы күренеш. Бар ярату кодрәтле һәм бөек Аллаһ ризалыгы өчен, ул бу дөньяда да, теге дөньяда да бар һәм булачак. Бары тик Аллаһ кына хакыйкатьне ачыклый һәм гүзәл әҗерен җибәрә. Әгәр дә ярату Аллаһ ризалыгы өчен түгел икән, ул дошманлыкка әверелә»*, дип белдерә әдип.

Мәхәббәт төшенчәсен шушы рәвештә аңлау һәм аңлату аның Урта гасырлар ислам дөньясында киң таралыш алган суфичылык идеясендәге иляһи мәхәббәт концепциясе белән дә аваздаш икәнлеген ачык күрсәтә. Шуңа күрә бу бүлек-мәҗлестә автор тарихта беренче суфилар буларак мәгълүм Зу-н-нун әл-Мысри, Рәбига әл-Гадәвия тарафыннан әйтелгән фикерләргә урын бирә. Соңгысының тасаувыф әдәбиятында еш таралган түбәндәге мәшһүр сүзләрен китерә: *«Рәбига Гадәвия әйткән: «Йолдызлар юкка чыкты, патшалар капкаларын япты, ә синең капкаң ачык, Раббым! Син имансызларга биргән бу дөньядан миндә бернәрсә дә калмады, киләчәк дөньяда да бернәрсәм дә юк, Син аны иманлылар арасыннан баш күтәргәннәргә бирдең. Миңа бу дөньядан да, теге дөньядан да бернәрсә дә кирәк түгел, бары тик Сине күрергә генә булсын».*

Шулай ук Сөләйман бине Дауд Сувари суфичылыкның хәрефчелек юнәлешендәге аерым бер төшенчәләрне гарәп хәрефләренә салынган яшерен мәгънәләр аша ачу алымына да еш мөрәҗәгать итә. *«Мәхәббәт» сүзе дүрт хәрефтән тора, диләр: «мим», «хә», «бә», «һә». Кол башта ике хәрефне әйтә, аннан соң бүләк йөзеннән Аллаһ аңа тагын ике хәреф җибәрә. Колга килгәндә, ул «мим» һәм «хә» хәрефләрен куллана. «Мим» – үзен Барлыкка китерүчегә хезмәт итүен дәвам итәргә теләп сагышлану, «хә» – кол мәхрүм булган гыйлемнәрне уйлап сагышлану билгесе. Һәм Аллаһ аны «бә» хәрефе – вөҗданлылык һәм «һә» хәрефе – туры юлдан йөрү сыйфаты белән бүләкли»*, дип белдерә автор.

Алга таба әлеге мәҗлестә язучы үз фикер-карашларын расларлык берничә риваяти сюжетка мөрәҗәгать итә. Гыймран кызы Мәрьям, мөгаллим һәм аның шәкерте, хуҗа һәм аның хезмәтчесе турындагы кыска-кыска хикәятләр әнә шундыйлардан. Алар барысы да Аллаһы Тәгаләгә карата булган мәхәббәтнең олуглыгын, бар хисләрдән дә өстен булуын исбатлый, фани дөнья тормышының нигезләре шул мәхәббәт хисенә корылырга тиешлеген тәкрарлый.

Әлеге хикәятләрнең каһарман-персонажлары да – Мөхәммәд пәйгамбәр, аның сахабәләре, Гали хәзрәт һәм аның уллары Хәсән һәм Хөсәен, Хәсән әл-Басрый, Рабига әл-Гадәвия кебек тарихи шәхесләр. Мәгълүм ки, бу геройлар Шәрык дөньясында таралган дини-суфичыл эчтәлекле бик күп әсәрләрнең сюжетын хәрәкәткә китерүче төп көчләр булып санала. «Зөһрәт әр-рийаз...» китабында да аларның эш-гамәлләре, уй-фикерләре аша әсәрнең төп идеясе ачыла, әхлакый яктан югары баскычта торган геройларны укучы үзенә үрнәк итә.

Шунысы игътибарга лаек: Сөләйман бине Дауд Суваринең Йосыф һәм Зөләйха мәхәббәте, сахрада коры баш сөяге рәвешендә табылып, үзенең үткәнен риваять итүче Кисекбаш тарихлары алдагы чорларда Урта гасырлар татар әдәбиятында киң таралыш алган сюжетлар рәтендә санала. «Кыйсса-и Йосыф», «Нәһҗ әл-фәрадис», «Җөмҗөмә Солтан» әсәрләренең авторлары Сөләйман бине Дауд Суваринең «Зөһрәт әр-рийаз... » әсәре белән таныш булганнар, андагы риваятьләрдә китерелгән тарихларны үз әсәрләренә сюжет итеп алганнар дип фаразларга нигез бар. Һәрхәлдә, бу юнәлештә алга таба фәнни тикшеренүләр һәм эзләнүләрнең мөһим һәм кызыклы фәнни табышларга китерәсенә шик юк.

«Зөһрәт әр-рийаз»дан алынган хикәятләрнең шулай ук XV гасырда госманлы галиме Ягъкуб бине Сәид Гали язган «Мәфатих әл-җәнан фи шәрхе шәригат әл-ислам» әсәрендә, XVI гасыр ядкяре «Бостан әл-кодес вә Гөлестан әл-өнес»тә, Мөхәммәд Чокыраклызадәнең «Алты бармак» китабында очратырга мөмкин. XIX гасыр татар галиме Хөсәен Әмирханның «Нәҗм әт-тәварих»ында (Тарихлар йолдызлыгы) һ.б әсәрләрдә күрергә мөмкин. Бу исә, Сөләйман бине Дауд Сувари иҗатының Урта гасырлар татар әдәбияты мәйданы белән генә чикләнмичә, барлык мөселман дөньясында киң таралыш алуын тагын бер кат раслап тора.

**Әдәбият**

*Гомәров И.Г.* Татар иляһият гыйлеме традицияләренең билгесез чыганаклары: Сөләйман бине Дауд әс-Сувариның «Зөһрәт әр-рийаз... » хезмәте // Фәнни Татарстан. 2019. № 4. Б. 50–54.

*Мәрҗани Ш.* Әл-кыйсмел-әүвәл мин китаб Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан: Б.Л. Домбровский табегъханәсе, 1897.

Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу. М.: Главная редакция восточной литературы, 1971.

*Рәмзи М.* Тәлфикъ әл-әхбар вә тәлкыйх әл-әсар фи вакаигъ Казан вә Болгар вә мөлүк әт-татар. Бәйрүт: Дар әл-көтүб әл-гыйльмия, 2002 (гарәп телендә).

*Таджаддин ал-Булгари.* Большой тирйак. (Большое противоядие) / Издание текста, пер. с араб., предисл., коммент. А.Б. Халидова; научн. ред. М.А. Усманов. Казань, 1997. 52 с.

*Хәлифә Хаҗи.* Кәшф әз-зөннун ган әл-әсами көтүб вә-л-фөнун. Әл-җильд әл-әүвәл. Бәйрут: Дар Ихъя әт-түрас әл-гарәби. (гарәп телендә).

***Гомәров Илһам Госман улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире*

УДК 82.091

***Л.Х. Дәүләтшина***

# Г. ГЫЙЛЬМАНОВНЫҢ БАЛАЛАР ӨЧЕН ЯЗЫЛГАН ӘСӘРЛӘРЕНДӘ МИФОЛОГИК КАТЛАМ

В статье рассматривается мифологический пласт информации, используемый Г. Гильмановым в литературных сказках и драматических произведениях для детей. В ходе исследования отдельное внимание уделяется литературным сказкам, в которых используются мифологические сюжеты и мотивы, восходящие к фольклорной традиции. В основу литературных сказок автора заложены сюжеты татарских легенд и сказок, соотносящиеся с различными слоями тюрко-татарской мифологии. Драматические произведения писателя рассматриваются в их отношении к актуальным мифологическим персонажам народной традиции (Шурале, Убыр, Хызыр Ильяс и др.). Обращение к мифологическим персонажам позволяет автору раскрыть нравственные проблемы современного общества, сместив полюс отрицательных значений с мифических существ на человека.

**Ключевые слова:** традиция, мифология, фольклор, образ, сюжет, мотив.

The article examines the mythological layer of information used by G. Gilmanov in literary fairy tales and dramatic works for children. In the course of the study, special attention is paid to literary fairy tales, which use mythological plots and motifs dating back to the folklore tradition. The author’s literary fairy tales are based on the plots of Tatar legends and fairy tales, correlating with various layers of Turkic-Tatar mythology. The dramatic works of the writer are considered in their relation to the actual mythological characters of the folk tradition (Shurale, Ubyr, Khyzyr Ilyas, etc.). The appeal to mythological characters allows the author to reveal the moral problems of modern society, shifting the pole of negative meanings from mythical creatures to man.

**Keywords:** tradition, mythology, folklore, image, plot, motive.

Иҗат юлын реализм кысаларында башлаган Г. Гыйльманов 1990 еллар ахыры – 2000 еллар башында татар әдәбиятына килеп кергән гомуми тенденциягә мөнәсәбәтле яңа әдәби юнәлешләрдә каләмен чарлый. Нәкъ бу вакытта төрле мәдәни катламнарга игътибар көчәю, новатор һәм традицион әдәби элементларның синтезы мифология һәм әдәбиятның үзара мөнәсәбәтен үзгәртә. Мифологик образ һәм сюжетларны әсәр тукымасына ничек бар шулай кертү белән янәшә яшерен мифологизм, ягъни сурәтләү процессын мифологик фикерләү схемаларына нигезләү гамәлгә керә [Давлетшина, с. 41]. Г. Гыйльмановның бу юнәлештә язылган әсәрләрендә галәм, яшәеш моделен тасвирлауда «универсальлек»кә омтылу, мифологик детальләр ярдәмендә вакыйгаларның милли масштабка күчерелүе, автор фантазиясенә бәйле мифик галәм сурәте тудырылу, яңа чынбарлык уйлап табу,

образ һәм мотивларны мифологик дәрәҗәдә ачыклау кебек сыйфат-үзенчәлекләр өстенлек ала.

Г. Гыйльмановның прозада үз юнәлешен булдыруы аның балалар әдәбиятында да тиз арада танылуы өчен ныклы нигез булып тора. 1995 елда, Галим Әсәнов псевдонимы астында, аның балаларга атап язылган шигырьләре тупланган «Гөрләвек – Ручеек» исемле рәсемнәр белән бизәлгән китабы дөнья күрә, аннан соң да балалар өчен шигырь, әкият, драма әсәрләре җыентыклары даими басылып тора. «Йөгерек гөрләвек» (1998), «Әбием сихерче бугай» (1999), «Көмеш тарак» (2000), «Алдакчы тукран» (2003), «Самат батыр» (2012), «Илекәй батыр» (2014) исемле китаплары нәни укучылар арасында аеруча популярлык казана.

Билгеле булганча, нәниләргә атап язылган әсәр укучыны дөнья белән таныштыру, белем-мәгълүмат бирү ягыннан гына түгел, сәнгатьчә матурлыгы белән дә үзенә тартып торырга тиеш. Г. Гыйльманов балалар әдәбиятының шушы үзенчәлеген аңлап иҗат итә, ул сабыйларга җитди төшенчәләр турында кызыклы һәм мавыктыргыч итеп сөйли белә. Язучының бу сыйфатына Л.И. Минһаҗева һәм Э.Ф. Гомәрева [Минһаҗева, б. 152; Гумерова, Мингазова, с. 15] игътибар итәләр. Бу өлкәдә ул, бер яктан, татар әдәбияты традицияләренә таяна, икенче яктан, халык авыз иҗатын тирәнтен белү сәбәпле, бала күңеленә тылсымлы ачкычны җай гына ярата ала.

Г. Гыйльмановның балалар өчен язылган әсәрләре арасында аерым урынны әдәби әкиятләр алып тора. Алар – балаларның яшь үзенчәлекләрен, психологиясен белеп язылган, сурәт һәм образларга бай, уку өчен җиңел әсәрләр. «Илекәй батыр» китабында (2014) туплап бирелгән әкиятләрнең күбесе татар халкының мифларына, легенда-риваятьләренә барып тоташа, сюжет җебенең чишмә башы халык ышануларыннан юл ала. Әкиятләрнең күпчелеге күләменең кечкенә булуы белән аерылып тора, ләкин аларның һәрберсе балага тәрбия дәресе бирә, гасырдан гасырга, бер буыннан икенчесенә тапшырыла килгән халык тәҗрибәсен җиткерә.

Язучының игътибар үзәгендә – татар халкының мифологик мирасы, ягъни күп гасырлар элек кешенең үзен әйләндереп алган дөнья, тирәлек турындагы фантастик карашлары нигезендә туган хикәятләре һәм ышанулары. Борынгы төркиләрнең күзаллавында дөньяның вертикаль моделе Югары, Урта һәм Җир асты өлешләреннән гыйбарәт булган. Урта дөнья белән Изге Җир-Су («Ыдук Йер-Суб») хакимлек итсә, Җир асты дөньясы «кешеләрне бер-берсеннән аеручы» һәм аларга «үлем хәбәрчеләрен җибәрүче» Эрлик-ханга буйсынган [Кляшторный, с. 91], ә югары дөнья белән борынгы төрки пантеонның югары алласы – илаһи Күк буларак кабул ителгән Тәңре һәм аның илаһи хатыны Умай идарә иткән. Билгеле булганча, IX–X гасырларда ислам дине рәсми рәвештә кабул ителеп, халык арасында да таралгач, Тәңре Алла исеме белән янәшә кулланыла башлый. Ислам белгечләре фикеренчә, «Тәңре төрки телләрдә Аллаһ сүзе белән бер үк мәгънәдә

кулланыла» [Ислам, б. 151], вазифаларының уртаклыгы тәңречелек тәгълиматының ислам дине белән органик рәвештә керешеп китүенә китерә. Г. Гыйльмановның «Тәңре мәхәббәте», «Җир яралу», «Тәңре сыерлары, Тәңре үгезләре», «Тәңре куагы», «Җан өләшүче Умай хатасы» кебек әкиятләрендә нәкъ менә төрки каганлыклар корып яшәгән дәвердәге гомумтөрки кавем күзаллавында формалашкан мифологик карашлар, аларның соңрак дәвер халык мифологиясендә сакланган эзләре чагылыш таба, балаларга бу дөньяның һәм җир йөзендәге төрле күренешләрнең барлыкка килүенә бәйле мифологик карашлар җиткерелә.

Әкиятләрдә мифологик мирасыбызның икенче төре, ягъни алла статусына ия булмаган ияләр, рухлар һәм зарарлы көчләргә бәйләнешле ышануларны һәм хикәятләрне үз эченә алган түбән мифологиягә дә киң урын бирелгән. Халык ышануларында ияләр табигать объектларының, кеше яши торган торак урыннарының хуҗасы буларак кабул ителәләр һәм, күңелләрен күрә белсәң, кешегә файдалы затлар буларак күзалланалар, ә җен, албасты, убыр, өрәк, шүрәле, шайтан һ.б шундый түбән рухлар адәм баласының тормышында туган күңелсезлек, бәхетсезлек, акылдан язу кебек күренешләрнең сәбәпчесе буларак тасвир ителәләр. Г. Гыйльмановның «Егет белән Шайтан», «Йорт иясе йорт эзли», «Су анасы белән Ялмавыз», «Матча асты – шайтан биләмәсе», «Айсылу белән Шүрәле» кебек әкиятләрендә балалар көндәлек тормыштан инде югала барган мифологик ышанулар белән танышалар, куркыныч дип кабул ителгән затларның асылда кешенең ниятенә бәйле рәвештә я яхшы, я яман якка үзгәрүен аңлыйлар. Балаларга җиңел, йөгерек тел, мавыктыргыч сюжет, кызыклы образлар аша хәзерге татар фольклорында кыйпылчыклары гына сакланып калган мифологик ышанулар дөньясы ачыла. Йорт иясенең йортка бәрәкәт китерүе, җеннәрнең мәкере, җир асты патшалыгына төшү, су анасының адәм балаларына ярдәм кулы сузуы кебек мотивлар бер әкияттән икенчесенә күчә килеп, мифологик дөнья сурәтен барлыкка китерәләр.

Әдәби әкиятләрнең бер өлеше дөньядагы төрле нәрсәләрнең һәм күренешләренең барлыкка килүе белән бәйле легенда текстларын үз эченә ала һәм алар нигезендә яңа сюжет корып балаларны тәрбияләү функциясен башкара. Мифологик һәм сәнгатьчә фикерләү үрелүенә корылган, легенда жанрына яраклаштырылып әдәби эшкәртелгән әкият текстлары күк җисемнәре, кошлар, хайваннар, агачлар, үләннәр һәм башка тереклек ияләренең барлыкка килүе һәм аларга хас булган үзенчәлекләрнең килеп чыгышы хакындагы архаик күзаллаулар белән танышырга мөмкинлек бирә («Күбәләк ничек күбәләк булган?», «Чыршы ни өчен яшел?», «Куяннарның колагы ни өчен озын?», «Чык бөртеге, Ромашка чәчәге һәм Кояш», «Карлыгач – изге кош» һ.б.). Язучы әлеге әсәрләрендә билгеле бер күренешләрнең һәм объектларның барлыкка килүен аңлатып кына калмый, ә бәлки өлкәннәргә мөнәсәбәт, әхлаклылык, дуслык-татулык, тырышлык, куйган

максатыңа ирешү кебек проблемаларның дөрес юнәлештә чишелешенә дә игътибар итә.

Г. Гыйльмановның югарыдагы әсәрләренең күбесе легенда һәм мифологик хикәят сюжетларына корылган булса да, араларында яхшылык явызлыктан өстен торган һәм дөреслек һәрвакыт җиңеп чыга торган халык әкиятләре сюжетына якын текстлар да аз түгел. Аның геройлары әкият кануннары буенча яши, тыңлаучыларны яки укучыны дөньяда һәр явызлыкны җиңеп чыгарлык көч булуына ышандыра. Язучының әдәби әкиятләре кыска сюжетка корыла, әмма халык әкиятләрендәгечә дөнья да, патшалык та, әкиятнең баш герое һәм аның эш-гамәлләре дә гадәттән тыш итеп тасвирлана. «Илекәй батыр», «Илекәй батыр җеннәр патшалыгында», «Илекәй белән Убырлы карчык» һ.б. әкиятләрдә геройның эш-гамәлләре аның үзенә яки гаиләсенә зыян салган дошманга каршы көрәшүгә, ниндидер тылсымлы предметны эзләүгә, гаилә коруына юнәлтелә.

Г. Гыйльманов каләме тудырган әкият текстлары, әлбәттә, тулысы белән мифларга туры килми, автор фантазиясе белән сугарылып, яңа сюжетка корыла яисә, мифологик сюжетны саклап, яңа детальләр белән баетыла, әмма, нигездә, мифологик мотивларга, мифологик персонажларның характеристикасына хилафлык килми, алар төп функцияләрен саклап калалар. Әкиятләрнең сюжет үстерелешенә килгәндә, вакыйгалар мавыктыргыч, кызыклы сурәтләнә һәм, иң мөһиме, халык хәтеренә салынган төп хакыйкать белән каршылыкка керми, ә киресенчә, балага катлаулы мифологик карашларны гадәти образлар аша аңлатып бирү омтылышы ясала. Әкиятләр аша автор балаларны табигать һәм тормыш-көнкүреш шартлары белән таныштыра, кечкенәдән үк бала характерында уңай сыйфатлар формалаштыру бурычын куеп, аларны матур гадәтләргә, хезмәткә өйрәтә, ата-аналарны һәм олыларны хөрмәт итү, гаделлек, намуслылык, батырлык, тыйнаклык һәм башка күркәм сыйфатлар тәрбияләү максатын куя.

Бер үк вакытта Г. Гыйльманов балалар драматургиясендә дә иҗади уңышларга ирешә: халык театрлары, мәктәп драма түгәрәкләре, театр студияләре тарафыннан сәхнәләштерелгән күп кенә пьесаларын яза, аның «Кыш бабайда сер бар», «Шүрәлеләр ни атлы?», «Миңа дус кирәк!» пьесалары буенча телефильмнар эшләнгән. Балалар сәхнәсе өчен иҗат ителгән әсәрләрендә язучы һәрдаим татар халкының мифологик мирасына, ышанулар системасына, фольклорга мөрәҗәгать итеп килә. Сәхнә әсәрләрендә балаларга мәгълүм персонажларның үзенчәлекле ачылуы, кызыклы сюжетлар һәм уйланылган идея-фикер игътибарны үзенә тарта. «Көмеш тарак» китабында (2000) урын алган «Убырлы карчык – әбием», «Кыш бабайда сер бар», «Булат нигә яхшы укый?», «Көмеш тарак», «Шүрәлеләр ни атлы?», «Кәнфитләр патшалыгында» кебек әсәрләрдә әдәп-әхлак, намуслылык-оятсызлык, кешелеклелек-явызлык, аталар һәм балалар мөнәсәбәте мәсьәләләре әкият һәм мифологик ышанулар дөньясыннан килгән персонажлар

ярдәмендә хәл итепә, әкият сюжетындагы кебек төп персонажлар яшәгән дөнья белән янәшә мифологик дөнья булдырыла, аның геройлары кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең дөрес булу-булмавын билгели торган камертонга әверелә.

Сәхнә әсәрләренең сюжеты гади, катлаулы проблемаларга корылмаган, әмма шул ук вакытта мавыктыргыч вакыйгалар барышы ахырга кадәр игътибарны үзенә җәлеп итеп тора һәм көтелмәгән чишелешкә китереп җиткерә. «Убырлы карчык – әбием» әкият-тамашасының сюжеты борынгы дастаннар заманасына алып китсә дә, һәр укучы күңелендә заманга бәйсез вакыйгалар чылбырын барлыкка китерә. Сюжет җебе Нәзир исемле малайның үлем хәлендә яткан әнисенә дәва эзләвен бәян итүгә нигезләнә. «Әнкә җанлы» бала үз гомерен корбан итү бәрабәренә (яшәү көче тупланган үләнне өзгән өчен кемдер һәлак булырга тиеш) Убырлы карчыктан авыру әнисе өчен дару үләне алып кайтырга дип юлга чыга. Сихерле аланда әкият персонажы – Убырлы белән очраша, аны ниятенең изгелегенә ышандырып, дару үләнен әнисенә алып кайта һәм әнкәсен терелтә. Г. Гыйльманов әсәрләрендә очраган әдәби персонажлар әкият геройларын хәтерләтсәләр дә, алар белән чагыштырганда, үзгә сыйфатларга ия булалар, вакыйгалар барышында бары яхшы яктан гына ачылалар. Убырлы карчык та, әкиятләрдәге образыннан аермалы буларак, асылда башка кешеләр кебек яши торган, яхшы күңелле, «урманның бөтенлеген, рухын-җанын сакларга куелган» [Гыйльманов, б. 25] изге җан буларак тәгаенләнә һәм үз гомере бәрабәренә Нәзирнең анасын саклап кала.

«Шүрәлеләр ни атлы?» әкият-пьесасында да табигать белән кеше, адәм балаларының үзара мөнәсәбәте проблемалары күтәрелә. Көндәлек тормышыбыздан рухи кыйммәтләр, гореф-гадәтләр югалып барган чорда Г. Гыйльманов бала күңеленә юл ачуның үтемле чарасын таба – һәркемгә кечкенәдән якын сюжетка мөрәҗәгать итә. Әсәрнең нигезенә салынган Г. Тукайның «Шүрәле» әкияте кешеләр һәм табигать дөньясы арасындагы конфликтны ачу вазифасын башкара. Пьесада, халык иҗаты әсәрләреннән аермалы буларак, төп герой Тәүфикъ Шүрәле урынында кала, һәм әлеге хәл күпләргә сабак бирердәй вакыйгаларны һәм конфликтны барлыкка китерә. Шүрәлеләрне «явыз, ямьсез, йонлач хәшәрәтләр» дип күз алдына китерергә күнеккән укучы алдында мифологик персонажлар бөтенләй икенче яктан ачыла: алар кешеләрнең явызлыгы аркасында караңгы урманнарда качып ятарга мәҗбүр икән бит дигәй уй укучыга тынгы бирми. Пьесаның төп герое – ялкау, тәрбиясез Тәүфикъ нәкъ менә шүрәлеләр ярдәмендә яхшы якка үзгәрә бара. Әсәрнең нигезенә салынган төп проблема исә Ата Шүрәле авызыннан әйтелә: «И кешеләр, кешеләр... Сез һәр җан иясен дошман күрергә күнеккәнсез. Үзегезне әллә нинди акыллы затларга саныйсыз. «Былтыр кысты» дип урман ияләреннән көләсез... Ә үзегез... Очраган бер шүрәледән алданып, «Минтиле!» (Шүрәле исеме) дип кычкырып йөрисез. Без бүген шул хакта гына искәртмәкче булдык: урманда аңлы затлар яши, урман начар-

лык кылырга теләгәннәрне акылга да утырта белә, димәкче булдык» [Гыйльманов, б. 145]. Шул рәвешле, һәр җан иясе – табигать баласы, табигать белән һәм үзара дустанә яшәгәндә генә тыныч-тату тормышка ирешеп була, дигән нәтиҗә калкытыла.

Алдагы әкиятләр һәркемнең тормышында булырга мөмкин гадәти вакыйганы әкият геройлары яисә мифологик сюжет белән бәйләнештә сурәтләсәләр, «Кәнфитләр патшалыгында» дип аталган әкият-тамашада Г. Гыйльмановның бер әсәреннән икенчесенә күчә килгән, архетип дәрәҗәсенә җиткерелгән Ак сакаллы карт – Ак бабай – Хозыр Ильяс образы ярдәмендә автор әкияте тудырыла, икмәк, ризык кадере мәсьәләсе әлеге персонаж белән очрашу вакыйгасы аша чишелә. Язучы биредә дә һәр балага таныш ситуацияне сайлый, чөнки һәрвакыт конфет ашау теләге бер генә баланың да күңеленә килми калмагандыр. Әлеге теләкнең тормышка ашуына нигезләнгән сюжетның чишелеше бала өчен бер дә көтелмәгәнчә хәл ителә: һәр көнне баллы тәм-том ашау туйдыра икән, дөньяда иң кадерле ризык – икмәк икән, дигән фикер балаларга аңлаешлы дәрәҗәдә җиткерелә. «Иң бәхетле кем? – дисезме, Иң бәхетле без икән!» дип сөенгән балалар алга таба үзара тату булмаган, икмәк кадерен белмәгән өчен Хозыр Ильяс тарафыннан җәзалананалар, үз ялгышларын таныганнан соң гына, «Икмәк-нанны җандай күреп, Гел тату яшик бергә...» [Гыйльманов, б. 164], дигән нәтиҗәгә киләләр. Сюжет үстерелешен тотып торган дини-мифологик образ гасырдан гасырга күчә килгән һәм күп кешенең кечкенәдән күңеленә салынган «Хозыр Ильяс адәм заты каршына сынар өчен чыга» дигән ышануга нигезләнә һәм сабыйлар күңеленә тәрбия орлыклары сала.

Г. Гыйльмановның һәр әкият-пьесасы татар халкының борынгыдан килгән ышанулары белән бәйләнештә ачыла, әмма төп фикер автор уйдырмасы ярдәмендә көтелмәгән чишелеш аша җиткерелә. «Убырлы карчык – әбием» әкиятендә төп вазифаны башкарган Убырлы карчык та, «Булат нигә яхшы укый?» дип аталган әкият-тамашадагы Булатка яхшы укырга ярдәм иткән Бүкәй дә, «Көмеш тарак»тагы Айсылуны үги ана газаплавыннан коткарган дию Хәшәр дә, «Шүрәлеләр ни атлы?» әсәрендәге Шүрәле гаиләсе дә традицион рәвештә мифологик ышануларда начар яктан характерлансалар да, автор интерпретациясендә әлеге түбән рухлар асылда кешеләр кебек үк изге күңелле, яхшы ниятле затлар буларак ачылалар, ә аларның явызлыклары бары адәм балаларының килбәтсез кылануларына каршы җавап кына булып тәгаенләнә. Гадәти һәм таныш әкият һәм миф геройлары аша язучы бала күңеленә яхшылык орлыклары иңдерә, аңа һәр кылгын явызлыкның җәзасы була, дигән фикерне сеңдерә һәм әйләнә-тирә дөнья белән дустанә мөнәсәбәттә яшәргә өйрәтә.

Гомумән алганда, Г. Гыйльманов үз иҗатында игътибарын халыкның милли яшәешенә, күркәм гореф-гадәтләренә, борынгы тамырларына юнәлтә, аның әсәрләрен төрле катлам укчылары яратып укый, һәркем үз күңелендә автор-хикәяләүче үткәргән фикер белән

аваздашлык таба. Әсәр структурасына кертелгән миф элементлары татар тормышының төрле якларын һәм аңа гына хас булган үзенчәлекләрен, проблемаларын яктыртып кына калмыйча, әлеге күренешләрне гомумкешелек кыйммәтләре яссылыгына күчерәләр, үзенчәлекле яшәеш энциклопедиясен хәтерләтәләр. Язучы фольклор образларын, мотивларын, сүз байлыгын әсәр тукымасына бик оста, табигый рәвештә кертеп, үзенчәлекле, кабатланмас почергын, стилен барлыкка китерә. Мифологияне тирәнтен белеп эш итү, архетипик образларга, билге-символларга, халык ышануларына, фикерләү калыпларына мөрәҗәгать итү аңа көнкүрешне, халыкның фәлсәфи-эстетик карашларын чагылдырып, милли колоритны тудыруда, психологизмны көчәйтүдә ярдәм итә.

**Әдәбият**

*Гыйльманов Г.* Көмеш тарак: пьесалар, шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. –207 б.

*Гумерова Э.Ф., Мингазова Л.И.* Фольклорные традиции в татарской детской прозе конца XX – начала XXI веков // Вестник ВГУ. Серия: Филология. Журналистика. 2017. № 2. С. 14–17.

*Давлетшина Л.Х.* Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI в. Казань: РИЦ «Школа», 2006. 186 с.

Ислам. Белешмә-сүзлек / Төзүче З. Шәфигый. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 190 б.

*Кляшторный С.Г.* Древнетюркская мифология: к постановке проблемы // Письменные памятники и проблемы истории культуры народов Востока. Ч. 2. М., 1979. С. 91–95.

*Минһаҗева Л.И.* XX гасыр татар балалар әдәбияты: үзенчәлекләре һәм үсеш тенденцияләре. Казан: Хәтер, 2011. 312 б.

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты гыйльми секретаре*

УДК 82.091

*Л.Р. Надыршина*

# ХАРРАС ӘЮП ПОЭМАЛАРЫНДА МИЛЛИ ЯШӘЕШ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

В статье анализируются лирические поэмы Харраса Аюпова, структурированные вокруг проблем национального бытия. Произведения поэта рассматриваются в литературно-историческом контексте, что делает возможным выделить некоторые тенденции развития татарской поэзии в целом. Автор статьи приходит к выводу, что в татарской литературе 1960 – 1980-х гг. актуализируются ключевые национальные коды татарского народа: родной дом, родная земля, нравственно-духовные ценности татарского народа и др., получившие наиболее полное развитие в поэтическом творчестве С. Хакима, С. Сулеймановой, Ф. Яруллина, Х. Аюпова и др. Благоговейная любовь к родной земле и татарской деревне, тоска по утерянным духовным ценностям становится лейтмотивом всего творчества Х. Аюпова. Если в первые два десятилетия своего творческого пути поэт раскрывает его в рамках романтической лирики, ориентированной на напевную интонацию и национальные традиции стихосложения, то в 1980-е гг. он создает ряд поэм, посвященных национальным проблемам. Каждая из поэм представляет собой наполненный тоской и сожалением монолог лирического героя, встревоженного судьбой нации.

**Ключевые слова:** Харрас Аюпов, татарская поэзия, поэма, жанр, идея-проблематика.

The article analyzes the lyrical poems of Harras Ayupov, structured around the problems of national existence. The poet’s works are studied in a literary and historical context. This makes it possible to identify some trends in the development of Tatar poetry as a whole. The author of the article comes to the conclusion that the Tatar literature of the 1960s – 1980s actualizes the key national codes of the Tatar people: home, native land, moral and spiritual values of the Tatar people, etc. These codes were developed in the poetic works of S. Hakim, S. Suleymanova, F. Yarullin, H. Ayupov, etc. Reverent love for the native land and the Tatar village, longing for lost spiritual values becomes the leitmotif of the entire work of H. Ayupov. In the first two decades of his creative career, the poet reveals it within the framework of romantic lyrics focused on melodic intonation and national traditions of versification. In the 1980s, he created a number of poems dedicated to national problems. Each of the poems is a monologue filled with longing and regret of a lyrical hero, concerned about the fate of the nation.

**Keywords:** Harras Ayupov, tatar poetry, poem, genre, idea-problematics.

«Традицион татар шигъриятенең эчтәлек, хис һәм фикерне җиткерү формалары, бигрәк тә әдәби-эстетик хасиятләр ягыннан өр-яңа үзгәреш кичерү вакыты» [Заһидуллина, б. 9] булган 1960 – 1980 елларда әдәби мәйданга чыккан Харрас Әюпнең традиционлыкка, миллилеккә йөз тоткан иҗаты шушы чорда үсеп киткән «салмак лирика»ның әһәмиятле бер өлешен тәшкил итә. Замандашы, каләмдә-

ше Р. Миңнуллин хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, аның «шигърияте дә, тормышы да яшәү рәвеше шикелле үк гади, аңлаешлы, хисләре ташып торса да, билгеле бер кысалардан ташып чыга торган түгел. Шигырьләре үзе кебек үк моңлы, сагышлы, кичерешләре дә тирәнлеге белән әллә каян аерылып тора. Ул <…> формасы белән дә, эчтәлеге белән дә традицион булган шигъриятне өстен күрде» [Миңнуллин, б. 7–8]. Бу хасиятләр Х. Әюпнең узган гасырның 60 нчы елларында матбугатта күренә башлаган беренче шигырьләрендә үк үзен сиздерә, «Туган өй» (1966), «Тәрәзәләр» (1967), «Салават күпере» (1967), «Очратсам бер түбән күңелне...» (1968) һ. б. бик күп әсәрләрендә әни, нигез, туган як, туган авыл, туган җир, табигать кебек милли образлар бер җепкә тезелә, шуларның гүзәллегенә сокланган, үзгә бер моңлы сагынудан сагышланган лирик герой үзәккә куела. Шагыйрьнең аннан соңгы иҗатында да әлеге кыйммәтләр нигез итеп алына, халыкчан фикерләү, көйле тезмә үрнәге рәвешендә укылган һәр шигырендә диярлек Х. Әюп «авыл җырчысы» буларак ачыла [кара: Загидуллина, с. 51]. Гомумән, татар шигъриятенең әлеге чорында актуальләшкән милли традицияләрнең аерылгысыз бер өлеше булган һәм С. Хәким, Роб. Әхмәтҗанов, С. Сөләйманова, Ф. Яруллин кебек шагыйрьләр иҗатында үстерелгән авыл, туган як, туган җир темасы Х. Әюпнең төп илһам чыганагы булып кала.

1980 еллар ахырындаа Х. Әюпнең иҗади офыгы тагын да киңәя: әдип, үзен поэма жанрында сынап, бер-бер артлы «Көзге» (1987), «Авыл җаны» (1988), «Көй эзләү» (1988), «Йөрәк атым» (1988), «Су хәтере» (1989), «Базарлар» (1989), «Биш вакыт намаз» (1994) әсәрләрен иҗат итә. Жанрның эчке закончалыклары шагыйрьгә үзенең романтик лирикасында күтәргән темаларны эпик киңлек белән ачарга мөмкинлек бирә: туган як, туган җир, авыл язмышы турындагы уйланулар милләт яссылыгына күчерелә, хис катламында татар халкының киләчәге хакында борчулы сызланулары алгы планга чыга. Бу чорда милли тематиканы ачуда калкуланган публицистиклыктан баш тартып, Х. Әюп лиро-эпик әсәрләрендә дә үзенең иҗат стилен хасил иткән лиризмга өстенлек бирә. Шуңа бәйле рәвештә, әлеге поэмалары милли шигъриятьнең лириклашуы дулкынында активлашкан лирик поэма үрнәге булып тора. Эпик поэмалардан аермалы буларак, мондый әсәрләрдә эзлекле хикәяләү, вакыйгалылык хис-кичерешләрне сөйләп-шәрехләп бару белән алмашына, яшәеш-чынбарлык вакыйгалары лирик геройның күңеле аша үткәрелә, аның рухи дөньясы алгы планга чыгарыла [кара: Спесивцева, с. 162]. Әйтик, татар авылы образын сызланулы-җирсүле хиссият белән сурәтләгән «Авыл җаны» поэмасы күңел монологы рәвешендә корылган: шагыйрьнең лирик герое «ачы төер» – татар авылының бүгенгесе турындагы ачынулы-шөбһәле гамьнәре белән уртаклаша. *Имәнепләр китәм, күрәмен дә / Авылымның җаны калмаганын* [Әюп, б. 206], – дип өзгәләнеп, ул моның сәбәбен шәһәрләшү процессында күрә. Балалары бәхет эзләп кайсы кая таралышканда, авылда, әлбәттә, ямь калмый, өйләр сирә-

гәя, сабыйлар тавышы тына, гармун моңнары югала, яллар саен кешеләрне берләштереп, барлап торган базарлар туктый... Шулар белән бергә «гореф-гадәтләрен, дөньяви барышка карашын, фәлсәфәсен, вакыт агышын, хезмәт ритмын саклаган җанлы татар авылы» [Харрасова, б. 281] үзе дә бетү куркынычы каршында кала.

Авыл җанының сызланулы-газаплы халәтен ачыклаган хис-кичереш катламы (поэмада авыл җаны елый, сыкрый, зарыга, миһербансыз кулда тыпырчына...) лирик геройның күңел кичерешләре белән янәшә бирелсә дә, асылда, авыл җаны кичергән газапларның һәрберсе аның йөрәгендә тамырлана, ул милли ваемлы, туган җире фаҗигасын бөтен күзәнәге белән тойган борчулы шәхес буларак ачыла. *Игелексез ата баласыдай, / Әллә кая китеп олакканбыз; / Сукырайган ана төсле булган – / Авылның бит җанын елатканбыз* [Әюп, б. 208] – мондый үкенечле өзгәләнүләр лирик геройның даими күңел халәтенә әверелә. Гомумән, үкенү катыш сагыну, җирсү хисе поэмадагы хисләр күчешен бер төенгә туплап торган үзәккә әйләнә. Лирик герой авыллы үткәнендә калган балачак гамьсезлеген, кешеләр арасындагы якты-тату мөнәсәбәтләрне, табигатькә сак карашны һ. б. сагына. Әлеге идиллик үткәнгә каршы куелган чынбарлык ямьсезлеге җәмгыятькә шагыйрь тарафыннан бирелгән бәя булып яңгырый: *Элек болыннарга сыймаган җан, / Кысан ихатадан артмый хәзер; / Күршесендә энә артык икән – / Көнләшүдән көеп, шартлый хәзер. / Ут күршеләр... / Ата-аналары / Бер-беренә элек утка кергән. / Инде хәзер черт та кире чыкмас / Урыс капкалардан, юкка йөрмә! / Кунак-төшем, килем-китем бетте, / Бәйрәмнәрне күпләр онытып бара. / Исән микән әле, тибә микән?! – / Йөрәгеңне, авыл, тотып кара...* [Әюп, б. 210]. Шул рәвешле, Х. Әюп авыллар бетүнең рухи-әхлакый кыйммәтләрне югалтуга китерәчәген әйтеп чаң кага. Авыл туфрагында гасырлар дәвамында үскән гөл – туган тел язмышы да татар авылының киләчәге белән турыдан-туры бәйле икәнлеге искәртелә: шәһәргә өзеп алып кителгән бу гөлгә мәктәп тәрәзә төпләрендә урын кими, җыелышларда безнең йөз гөлебез башкаларның бер гөленнән түбәнрәк куела, телен сатып түрә булганнар бу хакта сүз кузгатырга курка – кыскасы, киная юлы белән Х. Әюп татар теленең язмышы турындагы шөбһәле уйлары белән уртаклаша.

Гомумән, авыл язмышын турыдан-туры милләт язмышы белән бәйләп карап, шагыйрь татар авылларының бетүе милләтнең киләчәген куркыныч астына куя, дигән борчулы нәтиҗәгә килә. Ә милләтнең киләчәге ул тел, әхлак, рухи традицияләрне саклау белән бәйле, болар барысы да – «авыл җаны» гыйбарәсенең асылына салынган кыйммәтләр. Укучысына: *Авылыгызның җанын елатмагыз*, – дип мөрәҗәгать иткән шагыйрь әнә шушы һәр татар кешесе өчен изге төшенчәләрне саклап калырга чакыра, «авылны милләтнең нигез ташларын саклаучы дип шәрехләп, үткәннәр идеал буларак укучыга тәкъдим ителә» [Йосыпова, б. 99]. Әлбәттә, ул замандашларын кискен гаепләү юлына басмый, гражданлык позициясен күрсәтердәй патетик фикерләр

белән дә мавыкмый, аның бу поэмасы сагышлы, эчке сызланулы лирик монолог кебек укыла. Иң беренче чиратта, шагыйрьнең лирик герое авылы бәхетсезлегендә үзен гаепле тоя, нәкъ менә шуңа ачыну аның җанын газаплый: *...Үз-үземә урын табалмыймын – / Кая куйыйм сине, авыл җаны?!.* [Әюп, б. 213]. Шуңа бәйле, шагыйрь Зөлфәтнең: «Харрасның күп кенә шигырьләре миңа кара бер төндә ындыр артына чыгып, күзге озак яңгырларда чыланган салкын, юеш, ялгыз шомырт кәүсәсенә мең төрле уйлардан янган кешенең маңгай терәп өзгәләнүен хәтерләтә» [Зөлфәт, б. 8], – дигән сүзләрен әдипнең «Авыл җаны» поэмасына карата да әйтә алабыз.

Үткәндә калган әхлакый кыйммәтләрне юксыну «Көй эзләү» (1988) поэмасының да үзәгендә тора. Поэма композицион яктан шигъри циклга тартым (гомумән, эзлекле сюжеттан азат лирик поэма өчен бу – гадәти күренеш): ул «үз» көеңне эзләү идеясе белән берләштерелгән җиде бүлектән гыйбарәт. Гармунсыз, көйсез-моңсыз яшәлгән еллар нәтиҗәсе буларак аңланган *гамьсез тынлык* төшенчәсе аша поэмада төп урынны алып торачак җәмгыятькә бәя формалаша башлый: *Әллә нинди гамьсез тынлык баскан / Түгелме соң торган йортымны?! / Гармунсыз да яшәп булган, димәк, / Дөньясында, / Җырсыз-көйсез дә... / Ничек җан сакласаң булмыйдыр ул: / Яшиләр бит уйсыз-нисез дә. / Ничә еллар шуңа өйрәткәннәр...* [Әюп, б. 216]. Шушы гамьсезлектән айнып, кешелекнең үз көен эзләп табарга омтылышы поэмада күтәрелгән тәнкыйди-фәлсәфи фикерләрне аңлауга юл ача.

Шулай итеп, беренче бүлектә калкытылган тын калган гармун һәм кешелек югалткан көй образларының символик эчтәлеккә ия булуы тоемлана, шушында ук аның «ата-баба көе» булуы, гореф-гадәтләр белән бәйлелеге әйтелә. Поэманың калган бүлекләрендә бу төшенчәләрнең яңа мәгънәләре табыла. Әйтик, икенче бүлектә гармун моңы лирик геройның әнкәсе укыган дога-намазларны хәтердә яңарта, әнкәйләр җанындагы изгелекне көй итеп уйнап булса, ягъни дин кануннарын яңартып булса, җиһанда нинди үзгәрешләр булачагын искәртә: *Бер явызлык калмас иде җирдә, / Яулар тынар иде. / Иңәр иде рәхим-шәфкать бары / Кеше күңеленә...* [Әюп, б. 218]. Шул рәвешле, *көй – дин* янәшәлеге барлыкка килә. Өченче бүлектә кайчандыр печән өсләрен бизәгән көй татар халкының бердәмлегенә ишарә итсә, бүгенге көндә чит телдә җыр җырлаган татар авыллары туган тел язмышы хакында уйландыра. Аннан соңгы бүлекләрдә көй образының «рухи ныклык» (*Һәркемнең дә көе буладыр; / Әллә кайчан бөгәр иде язмыш – / Баш имибез шуңа гынадыр* [Әюп, б. 221]), «туган тел» (*Төймәләргә кул тиюгә, / Гармун / «Туган тел»гә таба каера. / Ничә еллар дәшми торган иде... / «Туган тел»не уйнап терелә...*), «үз фикерең булу» (шагыйрь көйне йөрәгенә баскан түрә табанына каршы чыгарлык көч дип саный, «аю»ларны биетердән көй зарурлыгын ассызыклый) кебек мәгънә төсмерләре табыла. Димәк, татар яшәешенең аерылгысыз өлеше булган гармун һәм көй-моң образларының

буыннар арасындагы бәйләнешләр, дин, бердәмлек, туган тел, рухи ныклык, хөр фикерлелек белән турыдан-туры бәйләнеше билгеләнә, онытылган көйне эзләү мотивының да нәкъ менә шушы рухи кыйммәтләрне яңарту омтылышы буларак укылырга тиешлеге тоемлана, *көй – милли хәтер* тәңгәллеге барлыкка килә. Кеше яшәешенең асылы – шушы милли хәтерне, халкыбызның әхлакый-рухи кыйммәтләрен киләчәк буыннарга тапшырып калдыру, нәкъ менә шуңа күрә дә лирик герой: *Үз көеңне эзләү җитми икән, – / Эзлисеңдер улың өчен дә. / Тамагы тук, өсте бөтен, дисең, / Өе җылы – тагын ни кирәк?! / Балалар да кеше икән лә бит – / Аларга да моңлы көй кирәк!* [Әюп, б. 221] – дип өзгәләнә, замандашларын гамьсезлек сөременнән араларга тырыша, моңсыз калдырылган буыннарның әхлаксызлык сазлыгына батып харап булачагы турында ачынып уйлана.

Поэманы кызыл җеп булып иңләп узучы «үз» һәм «ят» көй каршылыгы милли үзтәңгәллек мәсьәләсе белән турыдан-туры бәйләнештә карала: һәр халыкның милли яшәеше нигезен хасил иткән үз көе, үз традицияләре, рухи кыйммәтләре бар, аларны югалту милли асылыңны җуюга тиң, ә андый кешенең ата-бабалар каршындагы җаваплылык хисе, әхлагы бетә: *Өер-өер йөри моңсызлар, / Көпә-көндез кеше үтерәләр...* [Әюп, б. 222].

Поэманың җиденче бүлегендә исә көй эзләү мотивы дәүләт масштабына чыгарыла, бер бозык кылның ил язмышын боза алуы турында искәртелә, ил сәясәтенең бозык көй уйнауга кайтып калуы турында кинаялап әйтелә: *Без бит хәзер – ничә еллар буе / Уйналмаган гармун төслерәк* [Әюп, б. 224]. Шушы сәясәтнең аяныч нәтиҗәләре – түрәләрнең үз мәнфәгатьләрен алга куюы, эчкечелек, ваемсызлык һ. б. санала. Бу очракта көйнең тагын бер мәгънәсе калкытыла: ил-дәүләткә бәйле ул «тәртип, система» мәгънәсендә кулланыла башлый, һәм «көйле яшәү» гыйбарәсе дә иҗтимагый-сәяси төзеклеккә ишарә буларак укыла: *Кемнең генә тыныч икән җаны – / Ил кадәрле илгә көй кирәк!* [Әюп, б. 224]. Шулай итеп, «асмәгънәгә һәм күпфикерлелеккә корылган әлеге әсәр үзгәртеп кору елларындагы кыйбла эзләүне, иманга кайтырга омтылышны, татар халкы һәм аның бер баласы булган шагыйрь күңелендәге кузгалышларны ачык тасвирлый» [Харрасова, б. 283], – дип нәтиҗә чыгара алабыз.

Кыйбла эзләү, асылга кайту мотивлары белән бәйләнгән милләт язмышы проблемасы «Йөрәк атым» (1988) поэмасында да әһәмиятле урын били. Әлеге әсәр татар әдәбиятында киң таралган ат символик образын үзәккә куюы белән кызыклы. Әйтик, Р. Харисның аңа кадәр берничә ел элегрәк язылган «Ат иярләү» (1983) поэмасындагы кебек үк, биредә дә «Ир-егетнең йөрәгендә иярләнгән ат ятар» мәкаленә бәйле ачылган асмәгънәдә иярләнгән атның ир-атка хас батырлык, ватанпәрвәрлек, рух ныклыгы мәгънәсендә килүе ачыклана. Ничә еллар кеше җырын җырлап яшәргә мәҗбүр ителгән милләтнең ирләре шушы сыйфатларын җуйган, «ата-бабаларның йөрәк атыннан» мәхрүм калган. Лирик геройның сызланулы күңел халәтенә дә шул

югалтуны аңлаудан туган үкенеч сәбәпче: *Берәм-берәм барсын күрәм кебек: / Ятим атлар... мескен... кызганыч... / Ни үкенеч – кайчан гына алар / Ирләр йөрәгендә булган ич!* [Әюп, б. 198]. Шул рәвешле элегик сызлану белән сугарылган озын монолог лирик геройның укучыга мөрәҗәгате белән тәгәлләнә: *Ир-ат исмен йөрткәннәргә бүген / Атларының җанын тояр чак. / Атың синең ат шикелле икән – / Киртәләрен бәреп чыгачак! / ...Ирләр йөрәгендә иярләнгән / Атлар ятыр... – Кая атыгыз? / Йөрәктән дә кирәгрәк чагы – / Атыгызны алып кайтыгыз!..* [Әюп, б. 203].

Гомумән, Х. Әюп поэмаларында милли яшәеш белән бәйле ассоциатив-символик образлар зур урын алып тора. Алдагы поэмаларда авыл җаны һәм гармун, көй образлары шундыйлардан булса, «Көзге» (1987) поэмасында, исеменнән үк күренгәнчә, автор караш-фикерләре көзге образына йөкләнгән мәгънә төсмерләрен «чишү» барышында табыла, шуңа бәйле, аның хакыйкать (тарих көзгесе), ирек (ил көзгесе), намус (күңел көзгесе), рухи мирас (нәсел көзгесе) мәгънәләре аерып чыгарыла. Әлеге семантик бөтенлекләрнең һәрберсе милләт яшәешенә кагылышлы олы проблемаларны калкыта. Әйтик, тарих көзгесе турындагы юллар татар халкының яндырылган, ягылган, нахакка каралтылган үткәне белән бәйле ачынулы уйлануларны нигезли: лирик герой «тамырында “Әллүки”ләр аккан» халыкның беркайчан да вәхши була алмавы, иманын югалтмавы, кешелекле, гуманлы булып калуы турында әрнеп уйлана, ялган стереотипларны кискен кире кага. Шушы ноктада бабалардан калган мирас – җыр – милли хәтер чыганагы буларак текстка кертелеп, тарих көзгесе образының эчтәлеген баета: *Башкисәрләр түгел нәселебез: / Җырлый халык – / Җырлар баш кисми! / Яндырылган тарих, туздырылган... / Җыр янмаган. Безгә җыр калган. / Таный алыр бабалары җанын / Бу көзгегә килеп күз салган* [Әюп, б. 189].

«Ил көзгесе» хакындагы гамьнәр исә дәүләт, сәясәт белән бәйле фикер-нәтиҗәләргә килергә мөмкинлек бирә, шагыйрьнең гражданлык позициясе, милли дәүләтчелек турындагы хыял-идеалы кебек укыла: *Ил көзгесе – Ирек! – / Ни булса да / Тапланмасын илнең көзгесе!* [Әюп, б. 186].

Лирик геройның әнкәсеннән калган иске көзге – изге мирас – Х. Әюп иҗатындагы авыл, нигез, рухи мирас кебек төшенчәләрне үзенә туплаган символга – хәтер гәүдәләнешенә әверелә. Нәкъ менә милли асылыңны хәтерләү, нәсел-тамырларыңны җуймау кешене әхлакый кыйммәтләргә хыянәт итүдән саклый, дип раслый Х. Әюп.

«Күңел көзгеләрең сау булсын» дигән гыйбарәне көчле позициядә кабатлап, шагыйрь укучысы белән диалог кора, һәр гамәлне намус бизмәне аша үткәрергә өнди, тарих, ил, нәсел көзгеләренең төзеклеге нәкъ менә аерым кешеләрнең хакыйкатькә тугрылыгы, күңел көзгеләренә тап төшермичә, әхлакый югарылыкка ирешеп гомер итүләре белән алшартлана, дигән фикерне үткәрә, ә инде намусларына хыянәт итүче «көзгесез»ләрне кыйбласызлар, җаны гарипләр

дип атый, андыйлар ата-бабаларның изге исемен онытырга сәләтле, туган телләрендә сөйләшергә оялучы, әхлаксызлыкка күз йомучы буларак бәяләнә. Поэманың бетемендә бу төшенчә тагын да киңәеп, ил-халык намусы дигән гыйбарә кертелә, шуның аша һәр кешенең халкы һәм иле каршындагы җаваплылыгы турындагы идея җиткерелә: *Алларыңда гади көзге түгел – / Ил-халкыңның намусыдыр ул. / Күз караңдай саклап, / Каның белән / Юа-юа карыйсыдыр ул. / Йөзгә таплар куна-нитә калса, / Шул көзгегә карап сөртәсе; / Юкка уйлап тапмагандыр кеше – / Күңелебездә көзге йөртәсе* [Әюп, б. 189].

Х. Әюпнең әлеге поэмасында калкытылган милли тарих, хәтер проблемалары «Су хәтере» (1989) поэмасында лирик геройның күңел монологын бер җепкә тезүче үзәккә әйләнә. Әсәргә эпиграф итеп алган «Суның да хәтере бар...» канатлы гыйбарәсе үткәнен, хәтерен оныткан халыкка үпкәле шелтә кебек яңгырый, әсәр текстында бу фикер кат-кат искәртелә: *Кеше түгел бит ул онытырга – / Хәтере бар суның, хәтере бар, / Безнең ише хәтерсезләр өчен / Кире кайта-кайта әйтере бар* [Әюп, б. 264–265]. Казан ханлыгы чоры белән бәйле сәхифәләргә ялганып киткән якын тарихтагы югалтутетрәнүләрне (шәхес культы, сугыш, авылларны су басу) бер-бер артлы санап китеп, шагыйрь татарның фаҗигасы әнә шул Шаһгалиләр гасырыннан ук килә, дип билгели, *Аккан судай нигә озын булды / Безнең кимлек?* [Әюп, б. 266], – дип өзгәләнә, *Хак дошманың – / үткәнеңне / Онытырга кушканы* [Әюп, б. 270], – дигән нәтиҗәгә килә. Шул рәвешле, халыкның үз тарихын онытырга мәҗбүр ителүен аның иң олы фаҗигасы итеп күрә. Поэманың бетеме үзгәртеп кору елларындагы милли күтәрелеш идеяләрен яңгыратып, киләчәккә өметышаныч белән сугарыла: *Явызлыкта чама беткәч, / Сулар да бер кайтачак. / Су хәтере – безнең хәтер! – / Туфан булып калкачак...* [Әюп, б. 271].

Гомумән, Х. Әюп поэмаларында милли яшәеш проблемалары лирик герой монологының, аның кичерешләренең төп эчтәлеген билгели. Шагыйрьнең безнең тарафтан анализланган һәр әсәрендә үткәннәргә бәйле үкенеч, сызлану, милләтнең киләчәге өчен борчылу хисләре беренче планга чыга. Артык фәлсәфәгә бирелмичә, форма үзгәрешләренә омтылмыйча, шагыйрь милләт язмышына битараф булмаган һәр татар кешесенең күңеленә үтеп керерлек, үзенә хас эчке моңы, көе булган текстлар иҗат итә. Әлеге поэмалар 1960–1980 еллар татар лиро-эпикасында барган лириклашу тенденциясенең үзгәртеп кору чорында да дәвам итүен, лирик поэма жанрының үсешен раслый торган үрнәкләр буларак та әһәмиятле.

**Әдәбият**

*Әюп Х.Г.* Җәяүле буран: шигырьләр һәм поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 385 б.

*Загидуллина Д.Ф.* Татарская поэзия рубежа XX–XXI веков (1986–2015 гг.): эстетические ориентиры и художественные поиски. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. 268 с.

*Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

*Зөлфәт.* Тыелгысыз кош сере // Харрас Әюп: шигырьләр һәм поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 5–8.

*Йосыпова Н.М.* XX гасырның икенче яртысы татар шигърияте: традицияләр һәм яңачалык. Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2021. 296 б.

*Миңнуллин Р.* Харрасның моң чишмәсе // Харрас Әюп. Моңлы бер кыл. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Б. 7–8.

*Спесивцева Л.В.* Жанр лирической поэмы: генезис, развитие, становление // Гуманитарные исследования. 2009. №1 (29). С. 154–162.

*Харрасова Р.Ф.* Харрас Әюп // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 7 т.: 1985–2000 еллар. Казан: Фолиант, 2019. Б. 277–285.

***Надыршина Ләйсән Рәдиф кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82.091

*А.С. Шәрипова*

# XX ГАСЫР АХЫРЫ – XXI ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ХАЛЫК ЯЗМЫШЫ ТЕМАСЫ

## (Т. Миңнуллин, Д. Салихов, Р. Зәйдулла әсәрләре мисалында)

Целью исследования является определение особенностей художественного воплощения темы судьбы народа в татарской драматургии рубежа XX–XXI веков. Как показывает анализ отдельных пьес Туфана Миннуллина, Данила Салихова, Ркаиля Зайдуллы, создание сложных характеров, рассмотрение национальных и общечеловеческих ценностей в общей связке, своеобразное авторское отношение к изображаемым событиям позволили драматургам сформировать философский взгляд на судьбу народа. Авторами сделаны весьма удачные попытки определения векторов дальнейшего развития человеческого общества, способствующего моделированию будущего нации. Это закладывается в качестве основной идеи произведений и передается, в основном, через мировоззрение персонажей. Если герои, являющиеся представителями старшего поколения, видят перспективу в осознании ложности идеалов, покаянии и исправлении ошибок («Баязит» Д. Салихова), в возрождении утерянных национальных и нравственных ценностей, бережном хранении и передаче их следующим поколениям («Зятья Григория» Т. Миннуллина), то молодежь основными предпосылками достойного будущего народа считает силу духа, оптимистический настрой и благородство («Казанская сирота» Р. Зайдуллы, «Родословная» Т. Миннуллина). Приемы мифологизации и символизации, становясь ведущими художественными приемами, способствуют усилению смысловой нагрузки и раскрытию философской идеи произведений.

**Ключевые слова:** татарская драматургия, идея, конфликт, проблема, Т. Миннуллин, Д. Салихов, Р. Зайдулла.

The purpose of the study is to determine the features of the artistic embodiment of the theme of the fate of the people in the Tatar dramaturgy of the turn of the XX–XXI centuries. As the analysis of individual plays by Tufan Minnullin, Danil Salikhov, Rkail Zaidulla shows the creation of complex characters, consideration of national and universal values in a common bundle, a peculiar author's attitude to the events depicted allowed the playwrights to form a philosophical view of the fate of the people. The authors have made very successful attempts to determine the vectors of further development of human society, contributing to the modeling of the future of the nation. This is laid down as the main idea of the works and is transmitted mainly through the worldview of the characters. If the heroes who are representatives of the older generation see a perspective in realizing the falsity of ideals, repentance and correction of mistakes (D. Salikhov's Bayazit), in reviving lost national and moral values, carefully preserving and transferring them to the next generations («Gregory's Sons-in-Law» by T. Minnullin), then the youth considers the strength of spirit, optimistic attitude and nobility as the main prerequisites for a decent future of the people («Kazan orphan» by R. Zaidulla, «Pedigree» by T. Minnullin). The techniques

of mythologization and symbolization, becoming the leading artistic techniques, contribute to strengthening the semantic load and revealing the philosophical idea of the works.

**Keywords:** Tatar drama, idea, conflict, problem, T. Minnullin, D. Salikhov, R. Zaidulla.

XX гасыр башы татар әдәбиятында үзәк урынны алып торган халык, милләт язмышы белән бәйле темаларга һәм проблемаларга кабат әйләнеп кайту XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар драматургиясенә дә хас үзенчәлекләрнең берсе булып тора, бу исә милли яңарыш идеясен өр-яңа югарылыкка күтәрә. «Яшәеш кыйммәтләренең тамырдан үзгәрүе, моңа кадәр ышанган, хәтта табынган идеалларның юкка чыгуы драматургларны үткәннең гыйбрәтле сәхифәләрен, тормышчынбарлыкны, яңа тип геройларны, каршылыклы яшәешне чагылдыруның үзенчәлекле алым-чараларын эзләүгә этәрә» [Закирҗанов, 2019, а, б. 320]; «классик татар драматургиясе традицияләре белән бәйләнешне югалтмаган хәлдә, язучылар XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар әдәбиятын үстерүнең гомуми тенденцияләренә туры килә торган яңа сәнгатьчә формаларны тәкъдим итәләр» [Юсупова, Ибрагимов, с. 130].

Драматургиянең игътибар үзәгендә, халыкның тарихи үткәне һәм бүгенгесе белән беррәттән, аның киләчәк язмышына кагылышлы темалар урын ала, нәтиҗәдә психологик-фәлсәфи карашка нигезләнгән төрле жанрдагы пьесалар иҗат ителә. Татар халкының киләчәген күзаллаганда, авторлар тарафыннан төрле модельләр тәкъдим ителә һәм, алар, нигездә, пьесаларда персонажларның дөньяга карашы аша чагылыш таба: әгәр киләчәкнең нигезен өлкән буын геройларының бер төркеме милли рухны, гореф-гадәтләрне саклау һәм буыннан-буынга тапшыруда, икенчеләре тәүбә итеп, хаталарны кабатламауда күрсә, яшь геройлар исә халык язмышын рух хөрлеге, әхлаклылык һәм мәрхәмәтлелек белән бәйли. Әлеге карашлар танылган татар драматурглары Туфан Миңнуллин, Данил Салихов, Ркаил Зәйдулла һ.б.ның иҗатында ачык чагылыш таба.

Күренекле татар драматургы Туфан Миңнуллинның «Гөргөри кияүләре» этнографик музыкаль комедиясе (1995) бу юнәлештәге пьесалар арасында аерым урын били. Керәшен татарларының җирле сөйләш үзенчәлекләрен исәпкә алып язылган әсәр, авторның «Йөрәк маем» (1996) пьесасы кебек үк, кешенең рухи дөньясын милли яссылыкта сурәтләүгә юнәлтелгән. Әдәбият галиме Ә.М. Закирҗанов билгеләп үткәнчә, әлеге пьесалар «татарларның күп бизәкле, гаять гыйбрәтле, үзенчәлекле яшәү рәвешен торгыза, аерым штрихлар белән бирелгән образлар аша чор рухын, халыкның көчен, эчке рухын чагылдыра» [Закирҗанов, 2019, б. 61]. Бүгенге заман шартларында әхлакый кыйммәтләрне, татар халкының милли үзенчәлекләрен, традицияләрен саклап калып, киләчәк буыннарга җиткерү – әсәрләрнең нигезенә салынган төп идеяләр шулар.

«Гөргөри кияүләре» пьесасы комедияле сюжетка корылган: керәшен татары Гөргөри үзенең унсигез яшьлек кызы Үринәне милли гореф-гадәтләр буенча кияүгә бирергә дигән фикергә килә һәм кияү була алырлык егетләр арасында бәйге оештыра. Аның бу фикере буш урында гына тумый: бу адымга Гөргөрине ике өлкән кызының гаилә тормышлары уңышсыз булу этәрә. Үзәк геройның ышануы буенча, бары милли традицияләргә, әхлакый кыйммәтләргә тугрылык кына гаилә тормышының ныклыгын тәэмин итә ала. Әсәрдә әлеге фикерне тирәнәйтүгә, төп этник атрибутлар буларак, милли киемнәр һәм халык җырлары хезмәт итә, бу геройларның диалогларында да ачык күренә:

*Ү р и н ә . Нигә киерттегез боларны?*

*Г ө р г ө р и . Алар безнең киемебез булган. Исеңә төшерер өчен. Шушы киемне киеп кияүгә бер чыккач, шул киемеңне сандыгыңа салып, ирең белән аерылмый яшәр өчен* [Миңнуллин, 1996, б. 235].

Комедиянең сәнгати-эмоциональ тәэсире характерларның халыкчанлыгына да бәйле. Гөргөри, Палый, Өүдеки пьесада милли гореф-гадәтләрне, мәдәниятне һәм туган телне буыннан-буынга җиткерүчеләр буларак сурәтләнә. Драматург тарафыннан буыннар арасындагы мөнәсәбәтләрне идеальләштереп сурәтләү өлкән буын вәкилләренең зирәклеген һәм тормыш тәҗрибәсен тану буларак кабул ителә. Автор шул рәвешле әсәрдә үзара хөрмәткә, хезмәт сөюгә, мәрхәмәтлелеккә, гаделлеккә нигезләнгән идеальләштерелгән тормыш моделен тәкъдим итә һәм әлеге сыйфатларның татар халкы киләчәгенең асылы булырга тиешлеген ассызыклый.

Милләт язмышы темасын Т. Миңнуллин үзенең «Шәҗәрә» (1998) драмасында тагын да киңәйтә, фәлсәфи тирәнәйтә. Татар халкының аерым бер катламын тәшкил иткән морзалар нәселенең язмышын сурәтләү аша автор укучыны милләтнең үткәне һәм бүгенгесе хакында фикерләүгә этәрә. Вакыйгалар аша сурәтләнгән чор киңлеге, берничә сюжет сызыгы үрелеп баруга бәйле килеп туган күпкатламлылык авторга XX гасырның киң масштаблы тулы картинасын тудыру мөмкинлеген бирә.

Әсәрнең сюжеты мавыктыргыч: яшь егет Сәет Шәрәфетдинов әтисенең гозере буенча шәһәргә килә, аның максаты – бер гасыр элек бабасы Гарәфетдин, кучер булып эшләгәндә, Хәсәнбәк Сәетбәковтан бурычка алып торган акчаны Сәетбәковларның нәсел дәвамчыларына тапшыру. Егет әлеге нәселнең бер вәкиле булган Сәлимә исемле яшь кыз белән танышып, аның туганнарын барлый башлый. «Г. Камал традицияләрен дәвам итеп, кинокадр лентасын хәтерләткән күренешләрне бер-бер артлы тезеп, автор морза нәселенең төрле вәкилләре тормышын гаять гыйбрәтле вакыйгалар аша күрсәтеп кенә калмый, бәлки аларны үзара якынайту, берләштерү юлларын да эзли» [Закирҗанов, 2019, б. 60].

Геройлар арасында төрле яштәге һөнәр ияләре – пенсиядәге укытучы Халисә, галим Юныс, бизнесмен Азат, татар интеллиген-

циясе вәкилләре Артур һәм Эльза, элеккеге тоткын Сәлимә һ.б. бар. Пьесаның композицион структурасы һәр геройның язмышын аерым сюжет линиясе буларак карау һәм, халык язмышы һәм милли яшәеш мәсьәләләре кебек проблемалар белән беррәттән, бүгенге җәмгыятьтә гаилә кыйммәтләре югала бару, туганлык бәйләнешләре өзелү, иҗат кешеләренең рухи кризисы, социаль тигезсезлек кебек көнүзәк социаль проблемаларны калку итеп куярга мөмкинлек бирә. Төп теманы үстерү аша тарихи үткәнгә һәм җәмгыятьнең хәзерге торышына бәйле җитди социаль-сәяси мәсьәләләр күтәрелә. Шунысы әһәмиятле: аларның күбесе татар халкы язмышына турыдан-туры йогынты ясаган фаҗигалы тарихи вакыйгалар белән бәйле. Бу фикер «халык дошманы баласы» ярлыгы белән совет төрмәсендә туган Сәлимә Сәетбәкованың катлаулы язмышы аша халык фаҗигасы буларак киң яңгыраш ала.

*Сәлимә. ... Мин берни дә онытмадым. Телемнән биздергәннәр иде – өйрәндем, бабайларымның моңыннан биздергәннәр иде – өйрәндем. Яшим әле мин. Оныттырырга теләләр, берсен дә онытмыйм. Бу пычрак тарихның шаһиты мин* [Миңнуллин, 2003, б. 202].

Шул ук вакытта, драматург халык язмышы мәсьәләләрен тарихи вакыйгаларга гына кайтарып калдырмый, ә кешеләрнең үзаңы белән дә тыгыз бәйләнештә карый һәм автор позициясен философ галим Юныс Сәетбәков сүзләрендә чагылдыра: *Кеше маймылдан түгел, киресенчә, маймыл кешедән килеп чыккан. Үзенең асылын югалткан кешеләрдән эволюция нигезендә маймыл барлыкка килгән. (...) Әгәр дә кешелек дөньясы шушы юл белән баруын дәвам итсә, җир өстендә бары тик маймыллар гына калачак* [Миңнуллин, 2003, б. 192].

А.М. Саттарова билгеләп үткәнчә, «җәмгыятьтәге кыйммәтләрнең, кешеләрнең рухи камиллеккә омтылышы һәм хакыйкатьне танып-белүгә ихтыяҗы үзгәргән, әдәбиятта йомшак характерлы, максатлары һәм үз-үзенә ышанычлы булмаган геройларны сурәтләүгә өстенлек бирелгән чорда билгеле бер дәрәҗәдә маяк булырлык персонажлар булдыру зарурлыгы туа» [Саттарова, с. 102–103]. Т. Миңнуллинның «Шәҗәрә» драмасында үзәк урынны идеальләштерелгән яшь геройлар били: унҗиде яшьлек Сәет әсәрдә мәрхәмәтле, гадел, милли гореф-гадәтләрне хөрмәт итүче ышанычлы егет буларак тәкъдим ителә, уналты яшьлек Сәлимә шигъри күңелле, күңеле матурлыкка тартылучы, шат күңелле кыз итеп тасвирлана. Идеальләштерелгән яшь геройлар галереясын әсәрнең соңгы күренешендә генә килеп кергән яңа өйләнешкән яшь пар – Алимбәк белән Гөлгенә тулыландыра. Драматург нәкъ менә аларны Сәетбәковлар нәселенең лаеклы дәвамчылары буларак тәкъдим итә, шунлыктан пьеса бурыч акчасын өметле яшь татар гаиләсенә тапшыру белән тәмамлана. Шул рәвешле драматург, «уңай герой итеп, татар милләтенең киләчәге булырлык физик һәм психологик яктан сәламәт яшьләр»не күрә» [Саттарова, с. 104].

Д.Ф. Заһидуллина язганча, «XX гасыр ахырына татар әдәбияты үзенең кыйбласын таба: милләт темасы үзәккә куела, совет идеоло-

гиясен һәм тоталитар режимны тәнкыйтьләү, советчыл мифны җимерү һәм кызыл идеологияне абсурд чигенә җиткереп сурәтләү, үткән, хәзерге һәм киләчәккә нисбәтле хакыйкатьне эзләү, тормышны камилләштерү мөмкинлекләрен барлау алгы планга чыга» [Заһидуллина, б. 11]. Т. Миңнуллинның «Шәҗәрә» драмасында милли, фәлсәфи, социаль проблемаларны күтәрү аша татар халкының киләчәге моделе формалаша: тарихи үткәнне белү, туган телне, милли традицияләрне саклау һәм аларны киләчәк буыннарга тапшыру, гомумкешелек кыйммәтләренә тугрылык җәмгыять үсешенең төп нигезе буларак күрсәтелә.

М.И. Громова билгеләп үткәнчә, «шартлы хәлләрне, хәтта тулы бер шартлы дөньяларны модельләштерү, әлеге акылсыз реаль дөньяга туры килгән аерым бер “идеяләрне” җиткерү өчен махсус сәнгать чаралары булдыру хәзерге заман театры һәм драматургиясенә хас үзенчәлекләрнең берсе булып тора» [Громова, с. 128]. Әлеге сыйфат Данил Салиховның «Баязит» (2010) драмасында ачык чагылыш таба. Әсәрдә чынбарлык һәм кыю фантастик уйдырманың тыгыз үрелеп баруы үзәк герой – кайчандыр бик абруйлы булган, бүгенге көндә ялгызлыкта гомер итүче өлкән яшьтәге язучы Баязитның күңел халәтен, эчке каршылыкларын ачуга хезмәт итә. Инде күптән тышкы дөньядан аерылган геройның хәтерендә үткәне яңара, һәм ул, дөньяга бүгенге карашыннан чыгып, үз тормышын яңадан күңеле аша үткәрә.

Әсәрнең сюжеты Баязитның хыялында барган диалогларга корылган: ул мифик герой Пәри, инде күптән бакыйлыкка күчкән хатыны Хәтирә, уллары Ислам һәм Хисам, үз әсәрләренең персонажлары белән күңеленнән сөйләшә-бәхәсләшә. Күренештән күренешкә үзәк геройның язмышы тулырак ачыла бара: яшь чагында якты киләчәк төзү уе белән янып йөргән Баязитның үз чорының күп кенә канлы фаҗигалары шаһиты булуы, авыл мулласын атып үтерү, әтисен кулак буларак читкә сөрү кебек вакыйгаларда башлап йөрүе, соңрак үзенең дә «халык дошманы» булып танылуы һәм Колымага сөрелүе турында мәгълүм була. Бер-бер артлы хатынын, улларын югалткан геройның чор идеологиясенә бәйле әсәрләренең дә бүгенге җәмгыятьтә кыйммәтен җуюы ачыклана: Пәри сүзләре белән әйткәндә, китаплары инде «таба астына куярга гына» ярый. Ялган идеалларга табынып яшәгән язучы хакыйкатьне соңлап аңлаудан вөҗдан газабы кичереп яши *(Үткәннәрдән качасым килә минем, сеңлем, үткәннәрдән* [Салихов, б. 28]. Шул рәвешле, драматург пьесада «совет системасының идеологик кысаларында буталган һәм аны үз иҗатында сурәтләргә омтылучы язучының язмышын яңа яссылыкта ача» [Закирҗанов, 2011, а].

Драманың сюжеты Баязитның тормышка карашларының чагылышы буларак кабул ителгән мифик Пәри образына бәйле рәвештә төзелгән, әлеге образ авторның фәлсәфи концепциясен формалаштыруга хезмәт итә. Ә.М. Закирҗанов фикеренчә, «Пәри – әсәрдә төп герой Баязитның күңелен, рухи дөньясын ачучы, аңарда барган җан бәргәләнүенә төшенергә, шуны тоемларга ярдәм итүче мифик

образ. Драмада ул хакыйкатьне яклаучы, намус сакчысы буларак бирелә» [Закирҗанов, 2005, б. 76]. Г.И. Тарханова карашынча, «Пәри – Баязитның капма-каршылыклардан торган җанының чагылышы ул, аның идеаллары да, намусы да, үткәне һәм бүгенгесе дә» [Тарханова]. Безнең фикеребезчә, Пәринең үтәгән вазифасы үзәк геройның тормышындагы аерым чорларга, вакыйгаларга бәйле рәвештә үзгәреш-үсеш кичерә. Баязит яшь чакта Пәри аның идеологик карашларын чагылдырса (*Пәри. Мин синең белән көрәшмәдем түгел, көрәштем. Ике улыңны, Ислам белән Хисамыңны югалттырдым. Хәтирәңне. Атаң белән анаңа каршы бардырттым* [Салихов, б. 30]), сөргендәге чорда ышаныч-өметләренең җимерелүен символлаштыра (*Мифтахетдин. Сатылды синең Пәриең. (...) Шәхес культы елларында Колымада үтереп кайттың син аны* [Салихов, б. 47]), гомеренең соңгы елларында исә иманының чагылышына әверелә (*Пәри. Мин, мин – Пәрие аның – иманы* [Салихов, б. 50]).

Идеологик кысалардан котылу Баязитның әхлакый-фәлсәфи тирәнлектәге уйлануларына юл ача, бу исә әсәрдә кеше гомеренең мәгънәсе, яшәешнең асылы, тормышның максаты нидән гыйбарәт дигән сораулар җавап эзләү рәвешен ала. Драманың нигезенә үкенү, сызлану мотивы салынган, ул сюжетка геройның әсәрләрендәге персонажлар килеп керү аша тагын да көчәйтелә. «Төп конфликт Баязитның эчке күңелендә барган көрәш белән бәйле. Ул исә ике катламдагы, әмма үзара бик тыгыз бәйләнгән каршылыкларда ачыла. Берсе – Баязитның шәхси тормышы белән бәйле булса, икенчесе ул язган әсәрләрнең тормышчанлыгы, аларның заман сынавын үтү-үтмәве, яңа буын кешеләргә кирәк булу-булмавы турындагы бәхәсләр белән бәйле» [Закирҗанов, 2011, б., б. 183]). Шул рәвешле фәлсәфи фикергә корылган, әзерлекле укучыга атап язылган драмада, лейтмотив буларак, кеше гомеренең мәгънәсе турындагы уйлану тәкъдим ителә, бу исә халык язмышы, аның киләчәге турындагы фикерләргә барып тоташа. Драматург Баязитның күңелендә барган каршылыклар, үз-үзе белән булган бәхәс аша, үткәннәрне барлап, хаталарны төзәтмичә, тәүбә итмичә киләчәккә юл юк дигән фикерне җиткерә (*Узганыңны саклау – хәтереңне яңарту ул. Узганнарны онытып киләчәккә барып булмый* [Салихов, б. 29]), ә моңа исә, автор карашынча, шәхси инануларга тугры булганда гына ирешергә мөмкин.

Татар халкының киләчәгенә үзенчәлекле караш бүгенге көннең әйдәп баручы драматургы Ркаил Зәйдулланың «Казан ятиме» («Приют», 2012) драмасында тәкъдим ителә. Пьесада балалар йортында барган вакыйгалар сурәтләнә. Автор әхлаксызлык, явызлык күренешләре тамыр җәйгән ятимнәр приютын җәмгыятьнең шартлы моделе буларак тәкъдим итә. Бер яктан, балалар йортында тәрбияләнүчеләрнең рәхимсезлеге язмышларына ачулы яшүсмерләрнең психологик халәте буларак аңлашылса, икенче яктан, приют хезмәткәрләренең миһербансызлыгы белән кушылып, бүгенге вазгыятьнең чагылышы буларак кабул ителә.

Пьесаның үзәк герое – башка персонажлардан холкының ныклыгы, уй-ниятләренә тугрылыгы, ireккә омтылышы белән аерылып торган яшүсмер егет Камил Акку. Драманың беренче күренешенннән үк укучы / тамашачы аның башкаларга охшамавына, теләсә кайсы шартларда да үзе булып кала алу сәләтенә игътибар итә:

*К а м и л . Белмим. Алар минем күңелемдә актарына, алар минем хыялымны үтерергә тели.*

*К л а р и с а . Син аларга охшамаган. Шуңа күралмыйлар.*

*К а м и л . Мин колоннада йөри алмыйм, хорда җырларга хурланам. Мин аларның телен дә аңламыйм!* [Зәйдулла, б. 56]).

Әсәр Камилнең балалар йортыннан качарга маташуы белән башланып китә. Бу вакыйга Камил белән приют җитәкчелеге арасындагы каршылыкның тагын да кискенләшүенә сәбәп була. Драманың сюжет сызыгы егеткә яшьтәшләренең, приют һәм полиция хезмәткәрләре, спонсор кебек тышкы дөнья вәкилләренең тискәре мөнәсәбәте көчәюне сурәтләү аша үсеш ала. Пьесада конфликт геройларның «хыял», «ирек», «тормыш», «киләчәк» кебек төшенчәләргә карата мөнәсәбәтләре төрле булуга нигезләнә. Әсәрнең мифологик катламы, реаль һәм хыялый күренешләрнең үрелеп баруы яшәеш мәгънәсе турында фәлсәфи карашларны ачуга хезмәт итә. Җирдә кешеләрнең барлыкkka килүе хакында автор тарафыннан тудырылган миф әсәр тукымасына кертеп җибәрелә, һәм драманың төп структур элементына әверелеп, татар халкының геннарында сакланган рух хөрлеге, ireккә омтылу кебек сыйфатларны торгызу зарурлыгы турындагы идеяне көчәйтә. Бу фикер фантастик образ – Клариси сүзләрендә яңгыраш ала: *Күңелеңдә булсын ирек! Иң мөһиме шул, Камил. Күңелеңдә зиндан икән, син ирекне беркайдан да таба алмассың. (...) Азат рухлы кешеләр бик сирәк, Камил* [Зәйдулла, б. 55]).

Пьесага уңышлы кертелгән канат символы төп геройның тормышта үз урынын табарга тырышуын дәлилли. Кешеләргә очарга мөмкинлек биргән канатлар хакында вахтер Дедал карт сөйләгән хикәят Камилдә киләчәккә ышаныч-өмет уята, нәкъ менә күңелендәге хыялы биюче егеткә яшәү көче өсти *(Хыял... Әйе, әйе, хыял. Ул да булмаса, мин үләр идем. Миңа ирек, ирек кирәк!* [Зәйдулла, б. 55]), тормыш караңгылыгын оныттыра:

*К а м и л . А, якты!*

*К л а р и с а . Бу синең күңелең яктысы.*

*К а м и л . Кем син? Бу караңгы карцерны яктыртучы кем син?*

*К л а р и с а . Әйтәм ич, бу – синең күңел яктысы. Мин үзем якты эзләп килдем. Аңа әле тагын бик күпләр килер* [Зәйдулла, б. 55]).

Пьесада аутизм белән авыручы кыз – Умай образы аерым бер урын били. Умай да, Камил кебек үк, яшьтәшләреннән ихласлыгы, саф күңеллелеге, эчкерсезлеге белән аерылып тора. Әлеге образ әсәрдә тормышның тискәре якларын калку итеп сурәтләүгә хезмәт итә, милли һәм гомумкешелек кыйммәтләреннән баш тарткан халык язмышы турында фәлсәфи уйларга этәрә. Кызның исеме килеп чы-

гышы ягыннан борынгы төрки мифологиясе белән бәйле: ул гаилә җылысын, балаларны яклаучы-саклаучы илаһи затка барып тоташа. Иҗтимагый-сәяси, гомумкешелек проблемаларының сәбәпләрен күрсәтүдә автор нәкъ менә Умай образына мөрәҗәгать итә:

*Умай. И Җир-ана! Кичер үзеңнең игелексез улларыңны, хыянәтче кызларыңны. Алар сине онытты. Шуңа да анасыз калдылар, атасыз калдылар. Мондагылар да, андагылар да... Улларыңның тамыры корыды, кызларыңның карыны кипте. И Җир-ана! Ә син Аккуга көч-дәрманыңны бир, тамырыннан үзеңнең сутыңны агыз. Ул – яхшы ирән. Бәлки, ул коткарыр безне?* [Зәйдулла, б. 58].

Пьеса приютта тәрбияләнүче яшүсмерләрнең бәрелеше, Гайдар һәм Миляның фаҗигалы үлеме белән тәмамлана. Әсәрдә караңгы буяулар өстенлек итсә дә, үзәк урынны ирекkә омтылу, өмет мотивы алып тора. Тормыштагы хаоска Камил образы мисалында идеаль герой каршы куела. Әлеге әсәре белән автор киләчәкнең нинди булуы һәркемнең үз кулында, ул ихтыяр көченең ныклыгына, рух хөрлегенә, дөньяга карашка бәйле дигән фикер үткәрә.

Мәгълүм булганча, татар драматургиясе, формалашкан чордан башлап, һәрвакыт милли геройлар, милли тормыш сурәтен тудырырга омтыла. Т. Миңнуллин, Д. Салихов, Р. Зәйдулланың аерым пьесаларын анализлау күрсәткәнчә, «ярты гасырдан артык вакыт дәвамында совет идеологиясе тәэсирендә әлеге темадан читләшергә мәҗбүр булган татар сәхнә әдәбияты XX–XXI гасырлар чигендә җитди сыйфат үзгәрешләре кичерә: милли үзаң үсү, тарихи үткәнгә мөнәсәбәт, кыйммәтләр системасы үзгәрү нәтиҗәсендә милләт тарихы, аның бүгенге яшәеше, киләчәге, халык язмышында аерым шәхеснең урыны кебек мәсьәләләр янә алгы планга чыга» [Шәрипова, б. 205]. Әсәрләрдә үткән хаталарны танып тәүбә итү, милли рухны, гореф-гадәтләрне саклау һәм буыннан-буынга тапшыру, гомумкешелек кыйммәтләренә тугрылык идеяләре үзәк урынны били, халыкның киләчәге рух хөрлеге, әхлаклылык, гаделлек һәм мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар белән бәйләп карала башлый. Мифлаштыру, символик образларга мөрәҗәгать итү әсәрләрдә фәлсәфилекнең, психологизмның тирәнәюенә һәм интеллектуаль драматургия юнәлеше активлашуга китерә.

**Әдәбият**

*Громова М.И.* Русская современная драматургия [Электронный ресурс]: учеб. пособие для студентов-филологов, учащихся средних учебных заведений гуманитарного профиля. 4-е изд. М.: Флинта, 2013. 160 с.

*Закирҗанов Ә.М.* Баязит нигә өзгәләнә? // Мәдәни җомга. 2011. 19 янв.

*Закирҗанов Ә.М.* Драматургия // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 7 т.: 1985–2000 еллар / төз. Р.Ф. Рахмани; фәнни мөх.: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов. Казан: Фолиант, 2019. Б. 320–346.

*Закирҗанов Ә.М.* Иҗат шатлыгы // *Закирҗанов Ә.М.* Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 176–188.

*Закирҗанов Ә.М.* Т. Миңнуллинның XX гасыр ахыры иҗатында әдәбиэстетик эзләнүләр // Фәнни Татарстан. 2019. № 3. Б. 57–64.

*Закирҗанов Ә.М.* Хәзерге татар драматургиясендә мифологизм // Tatarica. 2005. № 2 (5). Б. 61–80.

*Заһидуллина Д.Ф.* Әдәби хәрәкәт // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 8 т.: 2001–2020 еллар / төз. Р. Ф. Рахмани; фәнни мөх.: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов. Казан: Фолиант, 2021. Б. 11–41.

*Зәйдулла Р.* Приют (Казан ятиме) // Яңа татар пьесасы. Альманах. Уникенче кисәк. Казан: Идел-Пресс, 2014. Б. 48–91.

*Миңнуллин Т.* Гөргөри кияүләре // *Миңнуллин Т.* Ай булмаса, йолдыз бар: Пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 209–246.

*Миңнуллин Т.* Шәҗәрә // Татар драматургиясе (1980–2000 еллар): Сайланма пьесалар. Казан: Татарстан Респуликасы «Хәтер» нәшрияты (ТаРИХ), 2003. Б. 160–210.

*Салихов Д.* Баязит // Казан утлары. 2015. № 4. Б. 27–53.

*Саттарова А.М.* Современная татарская драматургия: 1985–2000 гг. (концепция эпохи и героя). Дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 162 с.

*Тарханова Г.И.* Язучы җаны нигә сызлана? Электрон ресурс. URL: http://www.tarkhanova.ru/node/289. Мөрәҗәгать итү датасы – 29.01.2022.

*Шәрипова А.С.* XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар драматургиясендә милләт тормышына яңача караш / Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика: I Международный научно-практический семинар. 2–3 декабря 2021 года, г. Казань: сб. материалов / сост.: Ф.Г. Файзуллина, Г.А. Хуснутдинова, Э.М. Галимзянова. Казань: ИЯЛИ, 2021. С. 201–205.

*Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И.* Современная татарская драматургия / Национальные литературы республик Поволжья (1980–2010 гг.): коллективная монография / науч. ред. В.Р. Аминева. Барнаул: ИГ «Си-пресс», 2012. С. 124–132.

***Шәрипова Алсу Сәмигулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының инновацион эшчәнлек һәм тышкы элемтәләр буенча урынбасары*

УДК 82.091

***М.И. Ибраһимов***

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫНДА МИЛЛИЯТ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

В статье исследуется дискурс идентичности в научных трудах и публицистике Галимджана Ибрагимова. На основании анализа лингвистических, литературоведческих, исторических работ и статей устанавливаются взгляды писателя и ученого на национальное и его репрезентацию в языке, литературе и искусстве. Определяется роль Галимджана Ибрагимова в формировании татаризма в интеллектуальной культуре начала XX века.
**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, нация, национальная идентичность, татарский язык, татарская литература, история татар.

The article examines the discourse of identity in the scientific works and journalism of Galimjan Ibragimov. Based on the analysis of linguistic, literary, historical works and articles, the views of the writer and scientist on the national and its representation in language, literature and art are established. The role of Galimjan Ibragimov in the formation of tatarism in the intellectual culture of the early XX century is determined.
**Keywords:** Galimjan Ibragimov, nation, national identity, Tatar language, Tatar literature, history of Tatars.

*«Бу соңгы унтугызынчы гасыр тарихында иң мөһим роль уйнаган фикер, һич шөбһәсез, милләт фикере булды... Хәлбуки, милләт фикере – бөтен җир йөзендә бер дәрәҗә таралган бер куәтле фикердер, яхуд фикер-куәттер... Милләт фикере нинди зур вакыйгаларда гамәл булганын санап бетерү мөмкин түгел. Әле һаман да ул үзенең хөкемен йөртеп тота. Мин уйлыйм ки, истикъбальдә һәм бик озак заманнар, бик күп гасырлар эчендә милләт фикере кешелек тарихында хөккям (өстенлекле) фикерләрдән бере булачактыр».* 1913 елны күренекле татар җәмәгать һәм сәяси эшлеклесе Садри Максуди тарафыннан әйтелгән бу сүзләр милли үзаң мәсьәләсенең XX гасыр башы Россия иҗтимагый-сәяси, мәдәни һәм гаклый (интеллектуаль) тормышында нинди зур әһәмияткә ия булуын тагын бер тапкыр дәлилли ала. Милли үзаң рус фикер ияләре Н. Бердяев, Н. Трубецкой, Г. Шпет, П. Струве, С. Булгаков, Д. Овсянико-Куликовский, Бодуэн де Куртенэ һ.б.ның фәлсәфи һәм фәнни эзләнүләрендә үзәккә куела. Бу мәсьәләгә татар зыялылары Р. Фәхреддин, Г. Гобәйдуллин, Җ. Вәлиди, Г. Шәрәф, Г. Рәхим һ.б. да мөрәҗәгать итә.

Әлеге фикер ияләре арасында Галимҗан Ибраһимов шәхесе аерым бер урын тота. Беренчедән, язучы, галим, публицист, сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе буларак, ул үз эшчәнлегенең төрле тармакларында милли тел, әдәбият, тарих, татарларның милли

үзаңы, үзбилгеләнүе мәсьәләләренә зур игътибар бирә. ХХ гасыр башы татар зыялылары арасында милли аң проблемасын иңләү киңлеге ягыннан Г. Ибраһимов белән тиңләшерлек кеше, бәлки, юктыр да.

Икенчедән, ХХ гасыр башы татар вакытлы матбугаты битләрендә башланган татар үзаңы хакындагы бәхәсләрдә Г. Ибраһимов үзен татарчылык әйдаманы, эзлекле рәвештә «татар» этнонимын һәм төрки телләрнең мөстәкыйль үсүен яклаган шәхес итеп таныта. Күп кенә язмаларында ул гомумтөрки әдәби тел идеяләрен хуплаучыларга (И. Гаспринский, Р. Фәхреддин һ.б.) каршы чыга, бу идеяләргә төрки телләрнең күптөрлелеге фикере белән җавап бирә.

Өченчедән, 1920 елларда милли мәдәнияткә нисбәтле яңа дискурс формалашуга карамастан, Г. Ибраһимов милли мәдәниятләрнең һәм телләрнең төрлелеге идеясеннән баш тартмый, аларның үз үсеш юлларын мөстәкыйль билгеләвен яклап чыга.

1910 елларда Г. Ибраһимов «Шура» журналы битләрендә татарларның милли үзбилгеләнүе турында кабынган бәхәсләрдә актив катнаша. Ш. Мәрҗани фикерләрен дәвамчан үстереп, ул «татар» этнонимын төркичелек һәм болгарчылык тарафдарлары һөҗүмнәреннән яклый: *«Егерменче гасыргача “татар” дип аталып килгән бер кавемне “Инкыйраз” иясе егерме икенче гасырда “болгар” ясап мөнкариз кыйлды. Гәзитә вә журналларымыздан күбесе “төрекчә” яки “җәридәи төркиядер” дип йөртеләләр. Шагыйрьләремездән бәгъзеләр берничә еллар “татар” дип язып килгән иде, бөекләремездән берәүнең танбиһе саясендә, “татар” дигәнне “төрек”кә алыштырды»* [Ибраһимов, 2021, 11 т., б. 160].

Татарларны «төрки» дип билгеләүчеләр белән сүз көрәштергәндә, Г. Ибраһимов төп дәлил итеп «татар» этнонимының бөтен җирдә таралуын, киң кулланылуын телгә ала: *«Дөнья безне татар дип атый. Бер эш эшләгән булсак, безнең хакта: “Татарлар фәлән итә!” – дип сөйләгәннәр һәм сөйлиләр»* [Ибраһимов, 2021, 11 т., б. 163].

Бер ел узгач, «Шура» журналының 9 нчы санына Г. Ибраһимов «Без кем?» бәхәсе» дигән зур булмаган мәкалә урнаштыра, анда үзенә карата әйтелгән тәнкыйть сүзләренә җавап бирә. Асылда, «Без – татармыз» мәкаләсендә китерелгән дәлилләрне кабатлый: *«Әмма аңа карап, һичбер вакыт бездән «татар» дигән сүз алына алмас... Андый бер мәртәбә бирелгән исемләрне, яңлыш булса да, әүвәлгечә дәвам иткәнлегенә адәмләрдә, фәнни истилахларда, милләтләрнең, мәмләкәтләрнең – хәтта Америка шикелле бөтен бер кыйтгаларның – исемләрендә дөнья тулы мисал. Шуңа күрә ул моназәрәне үзенең фәнни җәһәтенә хазир кыйлып, “безне татар димәгез” җәһәте күптән сөкүт итәлергә иде. Юк гауга, җирне күчәреннән бераз читкә чыгару планыннан да ераграк хыял!..»* [Ибраһимов, 2021, 11 т., б. 177].

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, Г. Ибраһимов татарларның төрки дөньяның аерылгысыз өлеше булуын кире какмый, аның сүзләренчә, ул дөнья – славян, алман яки романнарныкы кебек үк –

төрле: *«Төрек наме – славян, герман, романнар кебек – гомуми бер исем булып, соңгылар эчендә төрле исемләр белән йөргән әллә ничә милләт булдыгы кебек, төрек (төркеме) дә төрле исемләр белән йөртелгән кавемнәргә аерылган»* [Ибраһимов, 2021, 11 т., б. 163]. Бер үк вакытта төрекчелекне татарларның милли үзбилгеләнүенә яный торган куркыныч дип күрсәтә: *«Димәк, хас исемебезне ташлап, «төрек» дип атала башласак, без башка төрек кабиләләре белән исемдә аерыла алмыйбыз»* [Ибраһимов, 2021, 11 т., б. 163].

И. Гаспринский, Р. Фәхреддиннең һәм аларның фикердәшләренең, татарлар аерым милләт буларак таңгалләшкән очракта, төрки әдәбиятара (мәдәниятара) бердәмлекнең таркалу ихтималы уңаеннан борчылулары да Г. Ибраһимовка нигезсез тоела: *«Исмәгыйль бәк буны: "Татар, казакъ" вә фәлән дип аерылачак булсак, Яубашы белән Стәрлебашының һәрбере үзенә бер әдәбият, "үзенә бер мәдәният тудырырга калкышачак", – дип тәгъбир итә. Риза казый: "Татар әдәбияты дигән аерым бернәрсә вөҗүдкә килсә, мондый шивә аерылуның зарури нәтиҗәсе уларак, башкорт әдәбияты, мишәр әдәбияты, типтәр, нугай вә башка аерым әдәбиятлар туачак" – ди»* [Ибраһимов, 2019, 7 т., б. 52].

Г. Ибраһимов аерым этник төркемнәрдәге (мишәр, башкорт, нугай һ.б.) уртак татар үзаңын (татарлыкны) географик (гомуми яшәү урыны), сәяси (бердәм дәүләт – Россия кысаларында тормыш) факторларга, шулай ук Урал-Идел буе төрки халыкларының матди һәм рухи тормышына йогынты ясаучы икътисади һәм мәдәни үзәк буларак Казанның тарихи статусына таянып аңлата.

1911 елның ноябрендә «Вакыт» газетасында Г. Ибраһимовның Ф. Кәриминең «Мохтәсар тарих гомуми» дәреслегенә язган рецензиясе дөнья күрә. Гомумән алганда, рецензент хезмәтне уңай бәяләсә дә, авторның борынгы чор тарихи шәхесләренә – Атилла, Чыңгыз хан, Аксак Тимергә карата тискәре мөнәсәбәтен аның төп җитешсезлеге итеп күрсәтә. Г. Ибраһимов фикеренчә, укучыларга адресланган китап аларда үз халкының үткәненә карата горурлык хисе тәрбияләргә тиеш: *«Мондый китап язучы кеше иң әүвәл үзенең татарлыгын хәтергә алырга, шуңа күрә тарихын татар баласына татарлыкга мәхәббәт иттерерлек кыйлып эшләргә тиешле...»* [Ибраһимов, 2021, 11 т., б. 172].

Бу рецензиягә җавап итеп, тарихчы Газиз Гобәйдуллин «Шура» журналында (1912, № 6) «"Тарих гомуми" тәнкыйтенә каршы» мәкаләсен бастыра, анда Г. Ибраһимов карашларында тар милләтчелек күзәтелә дип белдерә. «Ихтиляф вә риваять» («Шура», 1912. № 10) мәкаләсе белән бу гаепләүләргә җавап биреп, Г. Ибраһимов болай ди: *«Һәр милләт "үзем!!!" ди. Һәр милләт үзен күтәрә. Бу күтәрүгә әдәбиятны да, фәнне дә, фәлсәфәне дә, мәдәниятне дә корал итә. Тарихны да шуңа хезмәтче ясый. Бу – заманның, әлбәттә, ямьсез булган бер агымы. Ул булмаска тиеш иде. Ләкин бар. Ләкин ул – факт. Шуны күрә торып, инде бу бичара татарлар гына, юк*

*ул "тар милләтчелек" дип, киң күңеллелек күрсәтәмезме?»* [Ибраһимов, 2021, 11 т., б. 181].

Романовлар династиясенең 300 еллыгы уңаеннан, Г. Ибраһимов «Рус, төрек вә татар тарихыннан» дигән зур мәкалә әзерли. Киевта язылып, «Йолдыз» газетасында (1913 ел, 3, 5, 17 март номерлары) дөнья күргән язма төрле халыклар тарихында хәрәкәткә китерүче көчләрне чагыштыру тәҗрибәсе кебек тоела. Рус тарихын төрки-татарлар тарихы белән чагыштырганда, ул төркиләрдә тарихи процессны хәрәкәткә китерүче төп көч булып аерым шәхесләр (Атилла, Чыңгыз хан, Батый, Аксак Тимер) тора, ә русларда – халыктагы руслык тойгысы, дигән нәтиҗәгә килә: *«Русия рус дәүләте дә, рус шәүкәте үзенең хәзерге бөек мәртәбәсен алуда, аерым шәхесләрдән бигрәк, рус халкының рухына, халыкның руслык куәтенә бурычлыдыр. Әмма безем бөтен тарихыбыз, бигрәк тарихыбзның шәүкәтле минутлары, гомумән, беренче куәтнең аерым шәхсиятләремез дә була килгәнен күрсәтәләр. Безнең тарихыбызда халык куәте, халык рухы дигән мәфһүм үк юк»* [Ибраһимов, 2021, 11 т., б. 196]. Шунысы игътибарга лаек: Г. Ибраһимов тарих белән генә чикләнми, мәкалә ахырында ул әдәбият турында фикер белән уртаклаша, рус әдәбиятын югары бәяләп, анда милләт (халык) рухының ачык чагылышын билгели: *"Милләт рухы вә милләт табигатенең көзгесе булган әдәбиятка күз салсак, рус кавемендә халык, халык куәте дигән мәфһүмнең ни дәрәҗәдә тирән тамыр җәйгәнлеген, халыкчылык боларның канына сеңгәнлеген ачык күрәчәкмез»* [Ибраһимов, 2021, 11 т., б. 198].

Г. Ибраһимов позициясенә тәнкыйть күзлегеннән карарга да мөмкин (татар әдәбиятында да халык рухын чагылдырган әсәрләр аз түгел бит). Әмма биредә язучының тарихны ниндидер объектив көч һәм закончалыклар гамәле итеп, позитивизм кысаларында аңлатудан котылырга омтылуы мөһим. Әлеге тәгълиматка каршы килеп, Г. Ибраһимов тарихның менталь нигезләренә кагыла, анда (әдәбияттагы кебек үк) милли характерларның тасвир-сурәтен таба.

Революциядән соң аның гыйльми карашларында бу фикер югала: 1910 ел ахыры – 1920 елларның беренче яртысы социаль-сәяси процессларында актив катнашкан Г. Ибраһимов татар тарихына һәм иҗтимагый хәрәкәтенә караган хезмәтләрендә инде марксистик методология тарафдары буларак чыгыш ясый.

Мәсәлән, «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» («Безнең юл», 1922, № 1–2) мәкаләсендә ул татар җәмгыяте һәм әдәбияты барышының өч баскычлы картинасын тәкъдим итә: Борынгы заман (Урта гасырлар), Мәгърифәтчелек чоры (аның чишмә башы – татар мәгърифәтчеләре Курсави, Мәрҗани, Акмулла һ.б. эшчәнлеге), Инкыйлаблар дәвере (1917 елның Февраль революциясе вакыйгаларыннан башлана). Бу хәрәкәт Г. Ибраһимов тарафыннан алга китеш, үсеш итеп күзаллана, һәр киләсе этап җәмгыять һәм мәдәниятнең узган чорына караганда югарырак баскыч дип бәяләнә.

Г. Ибраһимов хезмәтләрендә тел үзтәңгәллеге мәсьәләләре мөһим урын алып тора. Морфология, синтаксис, татар теле орфографиясе буенча шактый хезмәтләр авторы буларак, галим күп кенә мәкаләләрендә татар һәм башка төрки телләрнең мөстәкыйльлеге, аларның тигез хокуклылыгы идеясен эзлекле рәвештә яклый. Бу яктан «Фәнни истиляхлар» («Аң», 1913, 18 декабрь) мәкаләсе аеруча кызыклы. Анда татар телендә фәнни терминология булдыру мәсьәләсе алга куела. Асылда, Г. Ибраһимов махсус фәнни тел булдыру кирәклеге турында яза һәм бу бурычны милләт төзелешенә бәйләп куя: *«Бер төркем халыкның аерым бер милләт мәртәбәсенә күтәрелүе өчен, – дип яза ул, – ана телендә әдәбияты булу гына җитми, аның үз телендә фәне дә булырга тиеш»* [Ибраһимов, 2019, 9 т., б. 166].

Татар телендә фәнни терминологиянең кирәклеген нигезләсә дә, Г. Ибраһимов гарәп телендәге барлык терминнарны татар телендәге вариантлар белән алыштырырга теләгән галимнәргә кушылмый (лингвистикада, мәсәлән, гарәп терминнарының татар эквивалентларын кертергә тәкъдим иткән Гыймад Нугайбәк). Татар теленең өстенлеген таныган хәлдә, Г. Ибраһимов бары тик татар телле терминнар куллануны бердәнбер дөрес юл дип карамый: аның өчен милли тел – башка телләр белән (шул исәптән фәнни терминология өлкәсендә дә) үзара бәйләнештә үсә торган ачык система. Шуңа күрә Г. Ибраһимов тел үсешенең үз тенденцияләрен исәпкә алмаган ясалма лингвистик төзелмәләргә каршы чыга.

Бу турыда ул, татар теленең чисталыгын саклау яклыларга беркадәр ирония белән төрттереп, «Татар теле һәм татарча язу хакында бер-ике сүз» («Йолдыз», 1910, 30 март) мәкаләсендә искәртә: *«Татарча язу вә садә телдә язуның мәгънәсенә һичбер чит лөгать кертмәү дип аңлау билкөлли хата идеке мәгълүм булса кирәк. Садә телнең төп максаты һәркем аңларлык ачык язудан гыйбарәт булып, баш кагыйдәсе – мәҗбүрият булмаган урында тәкәллефан чит лөгатьне кертмәү ләзем димәктән гыйбарәт идеке дә мәҗһүл дәгелдер»* [Ибраһимов, 2019, 9 т., б. 34]. Телнең чисталыгын тикшерүчеләрнең урынсыз гамәлләренә бер мисал итеп, ул тәрҗемә әсәрләрендә еш очрый торган «мөтәрҗим» (тәрҗемәче) сүзен татар телендә «татарлаштыручы» дип үзгәртү очрагын китерә: *«Менә бу бичара бәндәләр “татарча язу тиеш” дигән сүзне яңлыш аңлаучылардыр. Әгәр дә әдәбият мәсьәләләреннән вә ана телендә язуның мәгънәсеннән хәбәрләре булса, бондый тел әйләнми (торган), ишетергә мәкруһ һәм кирәкмәгәнчә озын вә килешсез сүзләрне әдәбиятка кертмәсләр иде. Һәр әдәбият үзен мондый тәнаферләрдән саклый вә боларга урын бирмидер. Безгә дә боны онытырга ярамый»* [Ибраһимов, 2019, 9 т., б. 33].

Телләрнең күптөрлелеге идеясе «Телләре башка булса да, күңелләр бер» («Аң», 1916, № 5) мәкаләсендә чагылыш таба, анда Г. Ибраһимов телләрнең милли тәңгәллеген бетерүгә, халыкка нинди дә булса башка телне көчләп тагуга каршы чыга: *«Һичбер халыкның авызына һичбер вакытта, аның табигый телен тартып алып, үзең*

*теләгән яңа бер тел куяр хәл юк*» [Ибраһимов, 2019, 7 т., б. 117]. Татар һәм казакъ тел белеме арасындагы мөнәсәбәтне татар галиме аларның үзара бәйләнышы, бер-берсен баетуы дип карый: казакъларның үзенчәлекле халык авыз иҗатын өйрәнү, Г. Ибраһимов фикеренчә, татар әдәбиятының милли хәзинәсен баетырга мөмкинлек бирәчәк: «*Безгә, казакъларны татар теле вә татар әдәбияты астына кертү хыялыннан бигрәк, әдәби хәзинәмезне баету өчен казакъ халкы әдәбиятын киң рәвештә өйрәнү тиешледер*» [Ибраһимов, 2019, 7 т., б. 118]

Г. Ибраһимов хезмәтләрендә милли тел проблемасы аны укыту мәсьәләсе белән дә тыгыз бәйләнгән. Аның методик хезмәтләре үзенең укытучылык тәҗрибәсенә нигезләнә: 1915–1917 елларда Г. Ибраһимов Уфаның «Галия» мәдрәсәсендә укыта (бу мәдрәсәдә ул 1906–1908 елларда үзе дә белем алган була).

«Татар телен ничек укытырга» (1916) мәкаләсендә Г.Ибраһимов, тел һәм фикерләү бәйләнеше турындагы идеяне теоретик нигезгә алып, туган тел дәресләрен укучыларда милли үзаң үстерүнең төп факторларыннан берсе буларак карый: «*Тел вә миллият адәмдә табигый. Боларның орлыгы һәркемнең табигатендә бар. Ләкин яхшы тәрбия ителмәсә, йирдә булган орлыкларның йимеш бирми калуы, бирсә дә начар булуы бик мөмкин. Төп максаты – хәятка хәзерләүдән гыйбарәт булган мәктәп бу мәсьәләдә тик торып кала алмый, бу йә теге якка үзенең тәэсирен күрсәтә*» [Ибраһимов, 2022, 9 т., б. 242]. Г. Ибраһимов өчен тел – халык рухының, аның фикерләренең һәм хисләренең тупланмасы, олы бер мирас. Туган тел дәресләрендә ул, барыннан да элек, баланы милли тормышның рухи нигезләренә җәлеп итү, якынайту мөмкинлеген күрә.

Телне, әдәбиятны, сәнгатьне милләтнең рухи нигезләре дип билгеләп, Г. Ибраһимов аларның үсешенә зур өлеш керткән татар мәдәният әһелләренә, зыялыларга аерым игътибар бирә. Әмма аерым шәхесләрнең татар халкы иҗтимагый һәм мәдәни тормышындагы ролен билгеләве һәрвакытта да дөреслеккә туры килми. Әйтик, ул татар әдәбиятында Г. Тукайның урынын аңлауда субъективлыктан котыла алмаган (бәлки, бу очракта, Г. Тукай белән ике арадагы аңлашылмаучанлыклар да тәэсир иткәндер). Татар мәдәниятенең 1917 ел революциясеннән соң эмиграциягә китәргә мәҗбүр булган күренекле вәкилләрен (Г. Исхакый, С. Максуди, Ф. Туктаров һ.б.) совет идеологиясенә туры китереп каралтып күрсәтүдән дә читтә тормаган. Бер үк вакытта Г. Ибраһимов татар халкы язмышында, аның гаклый һәм рухи тормышында хәлиткеч роль уйнаган шәхесләрне – Ә. Курсави, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Р. Ибраһимов, З. Камали, М. Вахитов һ.б. – югары күтәрә, аларның эшчәнлеген татар телен, әдәбиятын, сәнгатен, иҗтимагый һәм милли аңны үстерүгә керткән өлешләреннән чыгып бәяли.

Ш. Мәрҗани – Г. Ибраһимов өчен галим-реформатор гына түгел, ә иң элек татарларның милли үзтәңгәллеге, үзбилгеләнүе мәсьәләсен беренче булып көн тәртибенә куйган тарихчы.

Каюм Насыйри – татар тел белемендә тамырдан үзгәреш булдырган шәхес (ул аның бөеклеген татар теленең, халык әдәбиятының мөстәкыйль, бөтенлекле үзтәңгәллеккә ия кыйммәтләр булуын раслауга юнәлдерелгән фидакяр хезмәтендә күрә).

Р. Ибраһимовны ул, М. Бигиев, З. Камали, бертуган Бубилар һ.б. белән беррәттән, татарларның милли үзаңында дини тәңгәллекнең аерылгысыз булуын аңлаган мөселман лидерларының берсе буларак югары бәяли.

Революциядән соң Г. Ибраһимовның күп кенә татар зыялыларына карашы-мөнәсәбәте тамырдан үзгәрә. Сүз яңа идеологияне кабул итмәгән, аны татарларның милли һәм дини үзтәңгәллеген җимерә дип санаган язучылар, җәмәгать эшлеклеләре турында бара (Г. Исхакый, М. Бигиев, Ф. Туктаров, С. Максуди һ.б.). Революциядән соңгы аерым хезмәтләрендә (мәсәлән, «Кара маяклар»да) Г. Ибраһимовның бу шәхесләргә карата сөйләме агрессив төс ала, төрлечә бәяләү штамплары («панисламистлар», «контрлар», «кәләпүшләр һәм фәсләр кигән «милли» акгвардиячеләр» һ.б.) белән чуарлана. 1920 еллар башында барлыкка килгән мондый сөйләм стиле бөтен җирдә дошманлык, сыйнфый нәфрәт уята торган тел формалашуны күрсәтә. Совет власте ягында революциядән соңгы сәяси процессларда актив катнашучы Г. Ибраһимов та бу риторикага еш мөрәҗәгать итә. Менә тагын бер мисал.

РКП(б) Өлкә комитеты секретариатының 1925 елның 20 февралендә узган утырышы беркетмәсе нигезендә Г. Ибраһимовка, «карт язучы һәм аның (Р. Фәхреддин) белән шәхсән таныш иптәш буларак», «мөселман интеллигенциясе белән мөнәсәбәтләргә, Хәлифәт һәм Көнчыгыштагы дини вазгыятькә кагылышлы кайбер мәсьәләләрне ачыклау өчен шәхси әңгәмә оештыру бурычы йөкләнә». Үзенең РКП(б) Өлкә комитетына тапшырган Р. Фәхреддин белән очрашу турындагы хисабында (документка 1925 елның 27 феврале датасы куелган), Г. Ибраһимов болай дип яза: *«Бу ике сөйләшүдән мин түбәндәге нәтиҗәләргә килдем: мөселман руханилары артык комсыз, алар Совет власте рус руханиларына биргән өстенлекләр белән генә канәгатьләнмиләр. Асылда, идеологик фронтның чын хуҗалары булырга һәм мөселман-татар өммәте өстеннән хакимлек итәргә телиләр. Монысы – һичшиксез. Хәер, алар бу хакта ачыктан-ачык әйтмиләр, әмма бу һәрнәрсәдә сизелә. Шуңа күрә минем фикерем: әлеге мәсьәлә белән җитди шөгыльләнә башларга һәм аларның үтенечләренә карата бернинди йомшаклык күрсәтмәскә кирәк»* [Ибраһимов, 2022, т. 15, б. 249–252].

Г. Ибраһимовның мәдрәсәләрдә төпле белем алуын, кайчандыр борынгы ислам мәдәнияте турында күләмле хезмәт язуын («Борынгы ислам мәдәнияте») белгән укучыга мондый бәяләр сәер тоелырга мөмкин. Әмма Совет власте дошманнарына каршы идеологик көрәшкә кушылган язучы яңа хакимият тарафыннан ят идеология тарату куркынычы дип каралган руханилар турында башкача сөйли алмаган, күрәсең.

Хәер, ике ел узуга, Г. Ибраһимов үзе дә, «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән китабы дөнья күргәч, партия һәм мәдәният әһелләренең каты тәнкыйть утына эләгә (1927 елның 25 гыйнварында Г. Ибраһимов ВКП(б) Татар өлкә комитетының киңәйтелгән утырышында «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән темага доклад ясый. Соңрак ул аерым китапчык булып басылып чыга).

*«Интернационалист пролетариат хәрәкәте, пролетариат революциясе һәм социализм эчендә аерым милли мәдәниятләрнең язмышы ни булачак? Болар үзләренең милли төсләрен югалтачакмы? Яки шул нигездә үскән хәлдә интернационал максудлар өчен хезмәт кылачакмы?»* – Г. Ибраһимов үз мәкаләсендә менә шундый мәсьәләләр куя.

Аларга җавап биреп, ул туган телле мәдәниятне (беренче чиратта, мәгарифне) үстерү зарурлыгына игътибар бирмәүче совет эшлекләрен тәнкыйтьли. Мондый позицияне кире кагып, Г. Ибраһимов аны патша Россиясендәге милли телләргә караш белән чагыштыра. Заманасы өчен абруйлы В.И. Ленин, И. Сталин, тарихчы-марксист М.Н. Покровский хезмәтләренә мөрәҗәгать итеп, пролетар революция милли телләр һәм мәдәниятләр өчен ачкан яңа киңлекләр турында сөйләгәндә, Г. Ибраһимов яңа татар мәдәниятенең милли үзтәңгәллеге турындагы мәсьәләне күтәрә: *«Татарлар, бу пролетариат хәрәкәте нигезендә милли мәдәният үстереп, социализмга баручы милли мәдәниятләр кәрванында аерым бер отряд булып дәвам кылырлармы, әллә татар хезмәт халкы мәнфәгате ягыннан караганда, башка берәр мәдәни хәрәкәт эченә кушылып китү файдалырак булачакмы? Кушылса, кемгә? Чувашкамы, французгамы, башкорткамы, урыска яки үзбәккәме?»* [Ибраһимов, 2019, 10 т., б. 260]. Әлеге сорауларга җавап биргәндә, галим телнең милли мәдәният нигезе булуыннан чыгып эш итә. «*Без югарыда мәдәниятнең баш коралы – тел икәнен күргән идек. Бичара татар теле үзен саклауда, үзен үстерүдә дә зур мәшәкатьләр, газаплар кичерде. Иске замандагы мирзалар һәм муллалар карашы турында тукталмыйм; миссионерларның бу телгә һәм татар язуына ни дәрәҗәдә ачу белән карап, бетерү өчен чаралар эзләгәненә кайтып тормыйм. Патшачылык хөкүмәтенең мәшһүр руслаштыру сәясәте аркасында татар теленең нинди кысрыклыкларга төшүен сөйләргә дә керешә алмыйм,* – дип яза Г. Ибраһимов. – *Менә болар һәммәсе татар теленә киртә булдылар. Бердән, аның таралуына, икенчедән, үзенең үсүенә, эшләнүенә юл куймадылар. Югарыда без Октябрь революциясе соңында татар теленең рәсми хокуклы дәүләт теле булганын күрдек. Гамәлгә керүен дә тикшердек. Әгәр без бу телнең, бу мәдәни коралның үзенең эшләнүенә килсәк, бу бездә тик Насыйри бабайдан гына башлана. Әмма революциядән соң бу эшләнү бик зур адымнар белән алга атлап, татар мәдәниятенең баш коралы камилләшү юлына төште*» [Ибраһимов, 2019, 10 т., б. 275].

Автор кыска гына вакыт эчендә татар теленең төрле дәрәҗәдәге рәсми учреждениеләрдә, мәгариф, фән системасында актив кулланылуын (рус теле белән беррәттән) раслый торган ышандырырлык

дәлилләр китерә (Ибраһимов 1925–1927 елларда үзе җитәкләгән Татнаркомпрос каршындагы Академүзәкнең татар телендә фәнни терминология булдыру, сүзлекләр әзерләү өлкәсендә актив эшчәнлеге турында сөйли). Бер үк вакытта мәктәп программаларында милли мәдәнияткә кагылышлы мәгълүматларны киңәйтү-тирәнәйтү кирәклеген дә искәртә: *«Әле монда зур җитешмәгәнлекләр бар. Әле идеалдан ераклар, ләкин бернәрсә факт – милли мәдәният революция аркасында урта мәктәпләрне бөтенләй үз элементы белән тутырып бара, көннән-көн үсә, тирәнәядер. Киләчәктә мәсьәлә тагы югарырак куелачак»* [Ибраһимов, 2019, 10 т., б. 274]

Г. Ибраһимовның татар мәдәниятенең бүгенгесенә һәм киләчәгенә кагылышлы бу чыгышы рәсми партия органнары тарафыннан тәнкыйтькә дучар ителә: 1927 елның 14 июнендә ВКП(б)ның Татар Өлкә комитеты бюросында Г. Ибраһимов тезисларында җитди кимчелекләр барлыгы ассызыклана, алар арасында – милли мәдәниятнең мөстәкыйльлеген арттырып күрсәтү, пролетариатның ролен кимету (милли интеллигенциянең ролен арттыру белән бергә) аерып әйтелә.

Г. Ибраһимовның брошюрасы дәүләт хакимиятенең үзәк органнары эшлеклеләре игътибарыннан да читтә калмый. ВКП(б) ҮК политбюросы әгъзасы Михаил Калинин үз чыгышында, аның эчтәлегендәге «яшерен шовинизмга» ишарәләп, республика партия җитәкчелеген аны бастыруда, дөньяга чыгаруда гаепли. «Бу тезисларның башка бер куркыныч ягы да бар: татар теле Көнчыгышның барлык халыклары өчен дә аңлаешлы. Шуңа күрә бу тезислар алардагы партактивлар арасында фикер төрлелеге тудырырга, «рус мәдәниятеме яки милли мәдәниятме» дигән сорауны калкуландырырга мөмкин, – дип яза М. Калинин [Ибраһимов, 2022, т. 15, б. 279–280].

Моның белән чагыштырганда, Г. Ибраһимовның кайбер татар зыялылары, аерым алганда, аның тезисларын милли мәдәният мәсьәләләрен яктыртканда сыйнфыйлыктан баш тартуда, вак буржуаз либерализмда гаепләгән Г. Толымбайский тарафыннан тәнкыйтьләнүе күпкә радикальрәк тоела.

Авыруының көчәюе һәм, шуңа бәйле, Кырымга дәваланырга китеп баруы, күрәсең, язучыны 1920 еллар ахырында кулга алынудан коткара. Бу фаҗига 10 елдан соң, татар зыялыларына каршы канлы һөҗүм белән билгеле 1937 елда баш калкыта. Г. Ибраһимов кулга алына, этап белән Казанга озатыла, 1938 елның 21 гыйнварында төрмә хастаханәсендә вафат була.

Г. Ибраһимов шәхесенә төрлечә карарга, аның фикер-карашларын төрлечә бәяләргә мөмкин. Кемнәр өчендер ул – XX гасыр башында татарларның милли үзбилгеләнүен, аларның мөстәкыйль милләт дип аталу хокукын яклаган татар әйдаманы; кемдер аны 1920 еллар урталарында татарны өйрәнү белемен мәйданга чыгару өчен үзе җитәкләгән Академүзәктә күп көч куйган академик фәнне оештыручы буларак таный; кемдер революциядән соң татар милләте төзелешенә керткән өлешен югары бәяли. Әмма бер нәрсә ачык: Г. Ибраһимов

өчен эшчәнлегенең барлык чорларында да милли тел, әдәбият, мәдәният, тарих мәсьәләләре өстенлекле булган.

**Әдәбият**

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 15 томда. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018–2021:

7 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1915–1916) / [төз.: Г.М. Ханнанова, З.Г. Мөхәммәтшин; текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Г. Мөхәммәтшин; кушымта һәм исем. күрсәт. әзерл. Г.М. Ханнанова; кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина]. 2019. 375 б.

9 т.: Татар тел белеменә һәм телне укыту методикасына караган хезмәтләр / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Ә.Х. Алиева; кереш сүз авт. Б.Э. Хәкимов]. 2019. 383 б.

10 т.: Татар тел белеменә һәм телне укыту методикасына караган хезмәтләр / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Ә.Х. Алиева, Ф.Г. Фәйзуллина, Э.М. Галимҗанова]. 2019. 351 б.

11 т.: тарихка һәм иҗтимагый фикергә караган хезмәтләр (1909–1920) / [төз. Ә.Х. Алиева: текст., иск. һәм аңл. әзерл. Ә.Х. Алиева һ.б.; кереш сүз авт. К.Г. Әхсәнов]. 2021. 462 б.

15 т.: документлар һәм хатлар / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Г.Н. Зәйниева, Ф.Г. Фәйзуллина; кереш сүз авт. М.Х. Ибраһимов]. 2021. 599 б.

***Ибраһимов Марсель Илдар улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82.091

***Ф.Х. Миңнуллина***

# Г. ИБРАҺИМОВ ТӘНКЫЙТЕНДӘ ЗАМАН ДРАМАТУРГИЯСЕНӘ МӨНӘСӘБӘТ

Галимджан Ибрагимов оставил ценное наследие как ученый литературовед и критик. Он является одним из основоположников татарской литературной критики, которая начала формироваться в начале XX века. В данной работе рассматриваются литературно-критические статьи Г. Ибрагимова, посвященные татарской драматургии. На примере отдельных статей выявляются основные принципы и приемы анализа произведений.

**Ключевые слова:** критика, татарская драматургия, писатель, литературно-эстетическая концепция

Galimjan Ibragimov left a valuable legacy as a literary scholar and critic. This paper examines literary and critical articles devoted to Tatar drama. He is one of the founders of Tatar literary criticism, which began to form in the early 20th century. Using the example of individual articles, the basic principles and techniques of analyzing works are revealed.

**Keywords:** criticism, Tatar drama, writer, literary and aesthetic concept.

Татар әдәбияты классигы, энциклопедист-галим, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов (1887–1938) – XX гасыр башы татар дөньясында әһәмиятле урын тоткан, әдәбиятыбыз һәм мәдәниятебез тарихында тирән эз калдырган, үз чорының әдәби-мәдәни һәм иҗтимагый-сәяси тормышында зур урыны булган шәхес. «Г. Ибраһимов – Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан кебек мәшһүр талант ияләре белән берлектә Көнчыгыш традицияләренә нигезләнеп үскән татар әдәбиятын Европа һәм рус сәнгате казанышлары белән баетып, аны югары баскычка күтәргән олуг әдипләребезнең берсе» [Ганиева-Гыйниятуллина, 2018, б. 118]. Әдип калдырган мирас гаять бай һәм киң тармаклы. Ул әдәби тәнкыйть һәм публицистика өлкәсендәге эшчәнлегендә татар әдәбиятының барышына, аерым жанрларның үсешенә, татар матбугатына, сәнгатькә, милли театрга, әдәби телгә, тарихка бәйләнешле мәсьәләләрне күтәрә. Үз чоры әдәби процессына, замандашлары, каләмдәшләре иҗатына бәйле мәкаләләр язып, әдипләрнең иҗат йөзен, стиль үзенчәлеген күз алдына бастыра. Әдәбиятның эчтәлеген һәм сәнгати формасын баетуда халык авыз иҗатының әһәмиятен күрсәтә, татар зыялыларын, халык массаларын рус, Шәрык һәм Европа классик әдәбиятлары байлыкларына тарту кирәклеген ассызыклый. «1910 ел – Г. Ибраһимов җитди рәвештә татар әдәбияты тарихы, теориясе, тәнкыйте белән шөгыльләнә башлаган вакыт. Аның газета-журналларга тәкъдим ителгән язмаларында әдәбият фәненең төрле юнәлешләренә караган аерым мәсьәләләр игътибар үзәгенә алына» [Я жизнь искал..., с. 60].

Мәгълүм булганча, XX гасыр башында татар драматургиясе формалашу, аякка басу чорын кичерә, яңа жанрларга байый, чынбарлыкка нисбәтле җитди мәсьәләләргә игътибар итеп, аларны чагылдыруда яңадан-яңа алым-чаралар эзли. Г. Ибраһимов та әдәбият белән бергә сәнгатьнең башка төрләре, аерым алганда, театр сәнгате, драматургия белән кызыксынып яшәгән. Татар драматургиясенә, театрына мөнәсәбәтле язмаларында ул режиссер һәм артистлар уенына ачык, тәфсилле бәя бирә. Шунысын да әйтеп узарга кирәк, Г. Исхакыйның «Өч хатын берлән тормыш» (1900) һәм «Ике гашыйк» (1903) пьесалары сәхнәгә җитди яңалык алып килә. Г. Ибраһимов та «Милли матбугатыбыз» (1911) мәкаләсендә Г. Исхакыйның «Знание» нәшриятында «Өч хатын берлән тормыш», «Алдым бирдем» әсәрләренең рус телендә басылып чыгуын олы вакыйга дип бәяли. Шуннан соңгы елларда, төрле субъектив сәбәпләр аркасында, Г. Ибраһимов Исхакый әсәрләренә бәясен кискен үзгәртә. Татар әдәби-эстетик, тәнкыйди фикерендә кызу бәхәсләр уяткан «Мөгаллимә» драмасы дөнья күргәч, бигрәк тә сәхнәгә куелып, киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителгәч, матбугатта шактый бәхәсләр туа. Күп кенә язмаларда әлеге әсәрнең Г. Исхакый иҗатына яңарыш алып килүе турында да хәбәр ителә. Мәсәлән, Ш. Әхмәдиев татар драматургиясе тарихында да яңа чор башлануын ассызыклап үтә. Ә. Мөхетдиния «Кем ул мөгаллимә Фатыйма?» дип аталган мәкаләсендә драманы романтизм иҗат принциплары яктылыгында бәяли. 1915 елда Г. Ибраһимовның «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән» исемле мәкаләсе дөнья күрә. Мәкалә авторы Г. Исхакыйның моңа кадәрге иҗатына бәя биреп, аны идея бөтенлегенә ирешә алмаган автор дип бәяли. Г. Исхакыйны рус, Европа әдәбияты вәкилләре Толстой, Арцибашев, Байрон, татарлардан публицистлар Риза казый, Рәшид казый, И. Гаспринскийлар белән чагыштырып, *«Гаяз әфәндедә бер мәсләк – идея юк»* [Ибраһимов, 2019, 7 т., б. 78], ди. Тәнкыйтьче драманың исеменнән чыгып, *«әсәрдә мөгаллимләрнең типик тормышы сурәтләнергә, татар мөгаллимәсенең авыр язмышы» проблемасы күтәрелергә тиеш, дигән фикерне алга сөрә. «"Мөгаллимә" – укып җуаныр өчен күңелле бер әсәр. Әмма әдәби вә иҗтимагый кыйммәте (хәятнең көзгесе була алмаганга) нульгә якын»* [Ибраһимов, 7 т., б. 81], дигән ялгыш нәтиҗәгә килә.

XX гасыр башында язылган тәнкыйть мәкаләләрендә драма, нигездә, өч позициядән бәяләнә: идея-эчтәлеге, төп герой яңалыгы һәм әсәрнең иҗат принциплары мәсьәләсе күтәрелә [Юсупова, б. 425]. «Мөгаллимә» драмасының иҗат методы мәсьәләсе дә бәхәсләр тудыра. Ә. Мөхетдиния югарыда искә алынган мәкаләсендә романтик принципларны алга чыгара, драманы шул яссылыкта тикшерә. Җ. Вәлиди драмага, нигездә, романтизм иҗат принциплары ноктасыннан якын килә. Тәнкыйтьче татар әдәбиятында реализм һәм романтизм иҗат юнәлешләренең бер-берсенә кушылып китүе, үзенчәлекле үсеш алуы турындагы фикерне алга чыгара. Г. Ибраһимов «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән» мәкаләсендә әсәрнең әдәби

кыйммәтен ике яктан бәяләргә тәкъдим итә: романтик принципларны алга куйган хәлдә, «матур вә мәгънәле хыял тудырмак», ди. Автор иҗат юнәлешләренең бурыч-максатларын берьяклырак аңлый, аларның үзара керешеп китүен, синтез күренешен кире кага. Аның фикеренчә, ике иҗат методы арасында чикләр төгәл билгеләнгән булырга тиеш. «*Мөхәррир йә матур вә мәгънәле хыял язсын, яки үзенең тугры тасвиры белән тормышның авыр җәрәхәтләреннән берен укучы алдында ачып салып, халыкны шул хакта уйланырга, авыр язмышны җиңеләйтү турында чаралар күрә башларга, һич булмаса, шуны бер мәсьәлә итеп мәйданга салырга мәҗбүр»* [Ибраһимов, 2019, 7 т., б. 81]. Гомумән, автор драмага реалистик әсәрләргә куела торган таләпләрдән чыгып бәя бирә һәм түбәндәге максатлардан чыгып эш итү кирәклеген белдерә:

*«1) Хәят сәхифәләрен, хәятның тудырган мәгънәле типларын вакыйгада бар көенчә тасвир итмәк.*

*2) Матур вә мәгънәле хыял тудырмак»* [Ибраһимов, 2019, 7 т., б. 77].

Күренә ки, биредә әдәби әсәрне романтизм яисә реализм позицияләреннән чыгып бәяләү хакында сүз бара. Г. Исхакыйның бу пьесасында Г. Ибраһимов җәмәгатьчелектә борчу уятырлык реаль тормышны күрергә тели. Автор Фатыйма образының типиклыгы мәсьәләсен дә кузгата. Типиклыкның асыл хасиятен тәфсилләп аңлатканнан соң, тәнкыйтьче ахырда *«пьесада күп нәрсә, күп нотыклар, озын-озын хаталар бардыр. Ләкин күпчелегенең язмышы шул югарыдагыча булган татар мөгаллимә тибы юк»* [Ибраһимов, 2019, 7 т., б. 80], дигән нәтиҗә ясый. Билгеле булганча, бу дәвердә сәхнә әдәбияты, сан һәм сыйфат үзгәрешләре кичереп, чынбарлык күренешләрен романтизм юнәлешенә хас алым-чараларда чагылдыруга килә. Бу исә драматургиядә хисчәнлекне, геройның рухи дөньясын киңрәк, тулырак ачуны үстерә. Нәкъ менә романтик юнәлештәге әсәрләрдә милләт язмышына караган мәсьәләләрнең киң чагылыш табуын Й. Нигъмәтуллина «идеяләр романтизмы» дип атый [Нигматуллина, с. 137]. Әнә шундый шартларда Г. Исхакыйның «Мөгаллимә»се (1913) киң җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим ителә. Биредә хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе, халыкчылык идеяләре белән кушылып, җитди яңгыраш ала. Үз вакытында зур кызыксыну, бәхәсләр тудырган әсәре белән Г. Исхакый татар дөньясының төрле катлауларына бердәм булып милләт мәнфәгатенә хезмәт итү кирәклеге турында аваз сала [Закирҗанов, б. 62].

«Шәрык клубы»нда татарча театр («Ямьсез тормыш» пьесасы, 1915)» язмасында автор Ф. Сәйфи-Казанлының «Шәрык клубы»нда уйналган «Ямьсез тормыш» исемле сәхнә әсәренә үз карашын белдерә. Мөхәммәт образына бәя бирү барышында, милли мәсьәләләргә тукталып, аерым кешеләрне аны үз мәнфәгатьләрендә файдалануда гаепли. *«...Милли шагыйрь, милли әдәбият, милли театр – болар безнең каршыда хәятнең биргән вә бирәчәк нәрсәләренең иң газизләреннәндер.*

*Һәрбер мөкаддә идеяне үзенең кадерле мөнбәреннән урамга өстерәп чыгарып, үзләренең шәхси мәнфәгатьләре юлына хезмәт кылдыручылар һәркайда, һәр заманда була килгән кебек, без дә дә “милли” дигән сыйфатны хәзер сүи истигъмаль (явыз ният белән) итә башладылар. Сатучы үзенең малын үткәрү өчен, аны “милли” дип тәкъдим итә, һөнәрче үзенә күбрәк кеше тарту өчен, ничек булса да бер “милли” дигән кушамат табарга тырыша... Бу – бер.*

*Икенче яктан, бертөрле җилбәзәкләр, биш-ун кеше җыелып, милләт турында шәп сүзләр шаулашалар да, шуның белән милләт өчен зур эш кылгандай булып йөриләр»* [Ибраһимов, 7 т.. б. 57]. Автор фикеренчә, Мөхәммәт исә әлеге типларга каршы иҗат ителгән, милли буяуга буялып буш сүз сөйләүчеләрдән түгел. Ул – идеалист-халыкчы. Автор халыкка хезмәт итүне әһәмиятле мәсьәлә дип саный. Пьесаның үзәк герое Мөхәммәт яшәү максатын халыкка хезмәт итүдә күрә. Г. Ибраһимов үзенең бәяләмәсендә милләткә хезмәт итә алмаган персонажларга да туктала, тәнкыйть күзлегеннән бәя бирә. Шул рәвешле ул милли әдәбият һәм милли әдип нинди булырга тиешлегенә ачыклык кертә. Мәкалә авторы әсәрнең сәнгатьчә эшләнешенә дә игътибар итә: драманың композициясе төзек булмавына туктала, артистлар уенына да бәя бирә.

Г. Ибраһимовның татар әдәбияты теориясе юнәлешендәге уй-фикерләре «Әдәбият дәресләре», «Әдәбият кануннары» дип исемләнгән хезмәтләрендә тулы чагыла. Аның «Әдәбият дәресләре» (1916) исемле язмасында әдәбият кагыйдәләре татар әдәбиятыннан мисаллар, әсәрләрне анализлау белән үрелеп бара. Әдәбиятның төр һәм жанрларга бүленеше мәсьәләләрендә «бөтендөнья әдәбияты» дигән төшенчә аша татар әдәбияты жанрларын дөнья әдәбияты фонында күзәтү омтылышы ясала. Бу өлкәдә төзек бер система тәкъдим итмәсә дә, татар әдәбиятында пәйда булган жанрларны мисаллар китереп күзәтеп уза [Заһидуллина, 2019, 7 т., б. 27]. Зур хезмәтнең икенче бүлеге әдәбиятның төр һәм жанрларга бүленеше мәсьәләсенә багышлана. Драматургиягә бәйле өлештә әлеге төрнең, мәйданга килгәннән алып, үсеш-үзгәреш тенденцияләре, традиция-яңачалыклар һ.б. җентекле тикшерелә. Драма төре турында сүз алып барганда, язучы драмада табылырга тиешле булган төп сыйфатларны күрсәтә:

*«1) Вакыйганың эш вә хәрәкәтләр аркылы ачылып җитүе.*

*2) Мөндәриҗәдә берлек.*

*3) Каһарманнарның сүз вә эшләре үзләренең характерларына муафыйк булсын.*

*4) Диалог вә монологлар табигый булсын»* [Ибраһимов, б. 207].

Г. Ибраһимов драматургиянең өч жанрын атый: *«Драма өчкә бүленә: 1) трагедия; 2) комедия; 3) тар мәгънәсендә алынган драма»* [Ибраһимов, 2019, 7 т., б. 208]. Әдип драма, комедия, трагедияләрдәге жанр ачыклыгын билгеләүне төп таләпләрнең берсе итеп куя. *«Хәзер әдәбият мәйданында трагедия сирәк язылa. Комедия белән драманың да соңгысы алда йөри»*, дигән нәтиҗә чыгара.

Җыеп әйткәндә, Г. Ибраһимов 1917 елга кадәрге фәнни-тәнкыйди эшчәнлегендә 1905 елгы инкыйлаб нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзгәрешләр, яңа әдәбиятның формалашуы, әдәби тәрҗемә, мәктәптә милли әдәбият укыту, милли театр, нәшрият эшчәнлеге кебек мәсьәләләрне яктырта. 1917 елдан соң Г. Ибраһимов сәяси көрәш вакыйгаларында кайнап яши. «1917 ел инкыйлабыннан соң татарлар арасында революцион хәрәкәтне сәяси, иҗтимагый, идеологик яктан җитәкләүче әйдәманнарның берсе булуына карамастан, Г. Ибраһимов гыйльми-тәнкыйди эшчәнлеген дә дәвам итә» [Заһидуллина, 2019, 8 т., б. 8]. Язучылар иҗатына игътибарын киметми, татар мәдәниятенең, әдәбиятының киләчәк юлы, перспективалары турында яза. Әдипнең Октябрь инкыйлабыннан соң язылган байтак хезмәтләренең үзәгендә үткән чорларның мәдәни мирасына мөнәсәбәт, яңа чор татар әдәбияты үсеше мәсьәләләре тора. Г. Ибраһимовның әдәбиятка, аның максаты һәм вазифалары, әсәрләрне бәяләү критерийлары мәсьәләләренә карашы үзгәреш кичерә, сыйнфыйлык рухы көчле яңгыраш ала. «Пролетариат әдәбияты турында» исемле хезмәтендә, мәсәлән, мәдәни мирас мәсьәләсенә аерым тукталып, бу өлкәдә дә Г. Ибраһимов гаять кырыс, алга таба татар әдәбиятын өйрәнүгә тискәре йогынты ясаган сүзләр әйтә: *«Һичбер марксист «Сәлимә», «Мәгыйшәт» яки «Зөләйха»ларны эшче-крәстиян массасының, яшь буынның фикер, тойгы, хыял, мәгънә тәрбияләренә ярдәм бирә, сыйнфый аңнарын оештыра торган әсәрләр исемлегенә кертмәячәк»* [Ибраһимов, 2019, 8 т., б. 221]. Мәкалә каләм ияләрен пролетариат әдәбияты тудырырга чакыру белән тәмамлана. 1921 елны язылган «Яңа әсәрләр» язмасында яңа идеологияне яктырткан сәхнә әсәрләре итеп, үзенең «Яңа кешеләр», Ф. Сәйфи-Казанлының «Дошманнар» драмасын күрсәтә. «Дүртенче елга кергәндә» мәкаләсендә автор үз дәвере сәхнә әсәрләре турында: *«Сәхнә өчен басылды – "Яшь йөрәкләр", "Беренче адым", "Канлы көннәрдә", тәрҗемәләрдән "Яңа көчләр" – болар һәркайда уйналалар»* [Ибраһимов, 2019, 8 т., б. 64], – дип яза. Аерым пьесаларга багышланган мәкаләләрендә исә Г. Ибраһимов аларның төп сыйфатларын, әдәби барышка алып килгән яңалыкларын, җитешсезлекләрен төгәл күрсәтә. 1922 елда «Татарстан хәбәрләре»нең 31 гыйнвар санында Галимҗан Ибраһимовның «"Янгура" уйналуы мөнәсәбәте белән» исемле мәкаләсе басылып чыга. Анда Афзал Таһировның әлеге драмасы көчле тәнкыйть утына тотыла. *«...Һәртөрле дини фанатизм нокталарын бик артык куе краска белән чыгарулары аркасында, әсәр сәяси яктан да зарарлы бер төс алды: халыкны юк-бар дини хыяллар белән агулый торган бер нәрсә булып чыкты. Тарихтагы төп сыйнфый факт бөтенләй сизелмәде»* [Ибраһимов, 2019, 8 т., б. 68.], дип белдерә. Янгура тарихи образ буларак та игътибарга лаек. Афзал Таһиров та архив чыганаклары белән таныш булып, аларны өйрәнеп язганлыктан, биредә төп игътибарны милләт язмышына юнәлтә [Бәдретдинов, б. 172]. Г. Ибраһимов төп геройларны халыкка җиткерә алмаган артистлар өчен дә борчылуын

белдерә. А. Таһиров исә Галимҗан Ибраһимовның бу әсәргә карата әйтелгән тәнкыйди фикерләренә мөнәсәбәтен белдереп: *«...Әсәр тәмам булгач, артист Мортазин укырга алды. Табигый, ул, артистлар гадәтенчә, минем кульязманы күчертеп алып, сәхнәгә хәзерләгәндә бөтенләй үзгәртеп, Дутов хакимияте чорында Оренбурда куярга хәзерләгән... Сездә уйналган Янгура әнә шул булса кирәк»* [Ибраһимов, 2019, 8 т., б.109], – дип җавап хаты яза. Г. Ибраһимовның «Татар сәхнәсе» исемле мәкаләсендә күтәрелгән тәнкыйди карашларга килсәк, биредә сүз күбрәк драманың үзе түгел, ә сәхнәдә куелуы, тамашачыга күрсәтелүе хакында бара.

Г. Ибраһимов матур әдәбияттагы яңа күренешне тиз тотып ала. Аның М. Фәйзинең «Галиябану» драмасына карата язылган ««Галиябану» хакында бер-ике сүз» (1922 ) язмасы – шуларның берсе. Биредә әсәрнең төп үзенчәлекләре, татар әдәбиятына алып килгән яңалыгы алга чыга. Халык иҗаты белән язма әдәбият арасындагы бәйләнешләр, сүз сәнгатен баетуда фольклорның роле кебек мәсьәләләргә игътибар ителә. Г. Ибраһимов әдәби әсәрнең яңа сыйфаты хакында болай дип яза: *«Галиябану»ның бөтенләй яңа хасиятләреннән берсе – аның бездә беренче мәртәбә сәхнәгә музыканы, җырны, бер иттифакый зиннәт ясап кына түгел, бәлки төп матди итеп, асыл мөндәриҗә кыйлып кертүедер. Буны «Галиябану» башлап җибәрде»* [Ибраһимов, 2019, 8 т., б. 108]. Әсәрне совет әдәбияты эчтәлегенең төп категориясе буларак тәкъдим ителгән сыйнфыйлык ноктасыннан якын килеп бәяли. *«Беренче мәртәбә диярлек һичбер буяусыз, саф булганча, үзләренең уен-көлкеләре, җырлары, музыкалары, гыйшыклары, интригалары, бәетләре, көрәшләре белән крәстиян егетләре, крәстиян кызлары бу әсәр аркылы безнең театр галәменә килеп керәләр»* [Ибраһимов, 2019, 8 т., б. 109].

Гомумән, Г. Ибраһимов әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче сыйфатында кыйммәтле мирас калдырды. Язучының татар драматургиясе яшәешенең бик күп якларына, аеруча аның сәнгати дәрәҗәсенә басым ясап, чор әдәби процессын анализлаган җитди күзәтүләре, жанрларның хасиятләре турындагы нәзари тикшеренүләре әһәмиятле. Әдип һәр фикерен теоретик планда аңлатып кына калмый, уй-фикерләрен теге яки бу авторның иҗатын җентекле тикшерү аша дәлилләп тә бара.

**Әдәбият**

*Алиева Ә.Х., Зәйниева Г.Н.* Г. Ибраһимовның яңа басмасы // Фәнни Татарстан. 2019. № 1. Б. 33–47.

*Бәдретдинов Р.Ф.* Галимҗан Ибраһимов һәм Афзал Таһиров // Г. Ибраһимов мирасы һәм төрки дөнья: Г. Ибраһимовның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (17 апрель, 2012 ел). Казан, 2012. Б. 172–174.

*Вәлидов Җ.* «Мөгаллимә (Гаяз Исхакый әсәре)» // Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 8 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. Б. 209–218.

Галимджан Ибрагимов: «Я жизнь искал, смысла в жизни искал...». – Казань: ИЯЛИ, 2017. 333 б.

*Ганиева-Гыйниятуллина А.* «Яшь йөрәкләр» романының фәлсәфи-психологик үзенчәлекләре // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале ХХ века: материалы Международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина. Казань: ИЯЛИ, 2018. С. 118–122.

*Закирҗанов Ә.М.* Гаяз Исхакый һәм ХХ йөз башы татар драматургиясе // Фәнни Татарстан. 2018. № 2. Б. 60–66.

*Заһидуллина Д.* Галимҗан Ибрһимов – марксистик әдәбият фәне тудыруның үзәгендә // Ибраһимов Г. Әсәрләр: 15 томда. 8 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1918–1933). 2019. Б. 8–31.

*Ибраһимов Г.* «Галиябану» хакында бер-ике сүз // Әсәрләр: 15 томда. 8 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1918–1933). 2019. Б. 107–109.

*Ибраһимов Г.* «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән // Әсәрләр: 15 томда. 7 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1915–1916). 2019. Б. 72–82.

*Ибраһимов Г.* «Янгура» мөхәрриренең изахы // Әсәрләр: 15 томда. 8 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1918–1933). 2019. Б. 109–110.

*Ибраһимов Г.* «Янгура» уйналуы мөнәсәбәте белән // Әсәрләр: 15 томда. 8 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1918–1933). 2019. Б. 66–69.

*Ибраһимов Г.* Әдәбият дәресләре // Әсәрләр: 15 томда. 7 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1915–1916). 2019. Б. 122–241.

*Ибраһимов Г.* Пролетариат әдәбияты турында // Әсәрләр: 15 томда. 8 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1918–1933). 2019. Б. 191–236.

*Ибраһимов Г.* Шәрык клубында татарча театр // Әсәрләр: 15 томда. 7 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1915–1916). 2019. Б. 57–61.

*Ибраһимов Г.* Яңа әсәрләр // Әсәрләр: 15 томда. 8 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1918–1933). 2019. Б. 64–66.

*Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. 190 с.

*Юсупова Н.М.* Г. Исхакыйның «Мөгаллимә» драмасы әдәби тәнкыйтьтә (ХХ йөз башы тәнкыйди материаллары нигезендә) // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале ХХ века: материалы Международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина. Казань: ИЯЛИ, 2018. С. 424–430.

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 081/82.091

***Ф.Г. Фәйзуллина***

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫ – АКАДЕМИК БАСМАДА

Статья написана по случаю издания 15-томного академического собрания сочинений классика татарской литературы, литературоведа, видного государственного деятеля, историка, публициста и педагога Галимджана Ибрагимова. Большое внимание уделяется его ранее не опубликованным материалам.

**Ключевые слова:** Г. Ибрагимов, татарская литература, академическое издание, 15 томное издание Г. Ибрагимова, текстология.

The article was written on the occasion of the publication of a 15-volume academic collection of works by the classic of Tatar literature, literary critic, prominent statesman, historian, publicist and teacher Galimjan Ibragimov. Much attention is paid to his previously unpublished materials.

**Keywords:** G. Ibragimov, Tatar literature, academic edition, 15-volume edition of G. Ibragimov, textual studies.

XX гасыр башы татар прозасын үстерүгә зур өлеш керткән язучы, әдәби-нәзари фикерен үзгәртүгә катнашкан әдәбият галиме, тел белгече, иҗтимагый хәрәкәтләрдә күренекле урын тоткан җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, үз халкының үткәне белән кызыксынган, киләчәген кайгырткан тарихчы, матбугат битләрендә ялкынлы язмалары белән танылган актив журналист, публицист, балалар укытуга шактый көч куйган педагог Галимҗан Ибраһимов калдырган иҗади мирас гаять бай һәм күпкырлы.

Әле үзе исән вакытта ук аның хезмәтләренең күптомлы басмаларын әзерләү эшенә керешелә: 1929–1931 елларда 7 томлык итеп уйланылган «Галимҗан Ибраһимов әсәрләре»нең 2 нче (1929), 5 нче (1931) һәм 6 нчы (1930) томнары нәшер ителә, 1933–1934 елларда 5 томлык «Сайланма әсәрләр»е, 1936 елда 4 томлык итеп күздә тотылган «Сайланма әсәрләр»енең 2 нче һәм 3 нче томнары дөнья күрә. 1956–1957 елларда 3 томлы «Сайланма әсәрләр»е басылып чыга.

1970 еллар – текстологик тикшеренүләр яңа баскычка күтәрелгән чор. Бу елларда XX гасыр башы классикларының тулырак басмаларын төзү мәсьәләсе беренче планга чыга. 1974–1987 елларда бер төркем әдәбият галимнәре Р.Р Гайнанов, А.Ш. Шамов, С.Х. Алишев, М.Х. Хәсәнов, Х.Я. Гобәйдуллин, Г.К. Камалиев, Л.Р. Гайнанова, Ф.С. Фәсиевләр тырышлыгы белән Г. Ибраһимовның 8 томлык «Әсәрләр» басмасы һәм, шуңа өстәп, 2000 елда әдипнең хатларын, документларын эченә алган 9 нчы том басыла. Әлеге басманың 1 нче томына кереш сүзендә Г. Ибраһимов иҗатын тирәнтен тикшергән галим Мансур Хәсәнов: «Табигый, Ибраһимов әсәрләре-

нең бу басмасы аларның бөтенесен дә сыйдыра алмаган», – дип яза [Ибраһимов, 1974, б. 17]. Бу фикерне куәтләп, «Гәрчә бу эш совет цензурасы күзәтчелеге астында алып барылса да, текстолог-әдәбиятчылар теге яки бу әдипнең мирасын мөмкин кадәр тулырак чагылдырырга, текстларны авторлары ихтыярына туры китереп, комментарийларны да тулырак бирергә омтылдылар. Шулай да ул чорда әле текстларны бернинди кыскартуларсыз урнаштыру мөмкин булмады, кайберләре нәшриятка тапшырылгач алып ташланды (мәсәлән, М. Гафуриның 1917 елгы «Татар байрагы» шигыре). Г. Ибраһимов томнарында текстлар 200 ләп урында кыскартылып бирелде», – ди әдәбият галиме-текстолог З. Рәмиев [Рәмиев, 2019, б. 113].

Г. Ибраһимов мирасының берничә тапкыр «Сайланма әсәрләр» рәвешендә басылып чыгуы үз чоры өчен фәнни яктан да, әдипнең әсәрләрен халыкка җиткерүдә дә уңышлы адым булып тора.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы рухи, мәдәни мирасыбызны төрле чикләүләрсез халыкка кайтаруда яңа фәнни мөмкинлекләр ачты. Совет чорында яшәп килгән киртәләр алып ташлану үткәндәге язма байлыкларны өйрәнү офыкларын киңәйтте. Төрле фәнни тикшеренүләрдән соң, Г. Ибраһимовның фәнни әйләнешкә кертелмәгән, киң катлау укучыларга билгеле булмаган мәкаләләре, хезмәтләре шактый күп булуы ачыкланды. Аның бай гыйльми һәм иҗади мирасын текстологик яктан эшкәртеп, «Академик басма»сын әзерләү заман таләбе буларак калкып чыкты. Яңа мөмкинлекләрдән чыгып, «Академик басма»да әдипнең тормыш һәм иҗатын бөтен төгәллегендә, тулы тарихи мохит эчендә яктырту максат итеп куелды.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан 2016 елда башланган әлеге эшнең күркәм нәтиҗәсе – 15 томлык академик басма дөнья күрде. Бу күптомлыкта Г. Ибраһимовның бүгенге көнгә мәгълүм һәм табарга мөмкин булган иҗат мирасы укучыларга тәкъдим ителде.

Академик басманың 1–5 нче томнары 2018 елда, 6–7 нче томнары 2019 да басылып чыкты. Шушы уңайдан «Фәнни Татарстан» журналы битләрендә бу томнарга күзәтү рәвешендә язылган әтрафлы мәкаләләр инде дөнья күргән иде [Алиева, Зәйниева, 2019; Заһидуллина, 2020]. Аларга яңадан нечкәләп тукталып тормыйча, кыскача гына әйтсәк, 1–5 нче томнардагы хронологик тәртиптә бирелгән әдәби әсәрләре аша Г. Ибраһимовның иҗат эволюциясе ачык күренеп тора. Әдипнең әдәби мирасы 9 томлыкта дүрт томны тәшкил итсә, академик басмада исә алар биш томны били, ягъни, 1 нче томда – башлангыч чор (1907–1916) хикәяләре («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы», «Гыйшык корбаннары», «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә», «Яз башы», «Диңгездә», «Йөз ел элек», «Сөю-сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Карак мулла», «Карт ялчы», «Көтүчеләр», «Табигать балалары», «...мәрхүмнең дәфтәреннән», «Габдрахман Салихов») һәм «Казакъ кызы» (1924) романы; 2 нче томда – «Татар

хатыны ниләр күрми» повестенең (1910, 1929) ике варианты, чөнки әсәрнең бу ике варианты бер-берсеннән күләме һәм эчтәлеге ягыннан бик нык аерылалар, «Яшь йөрәкләр» (1912) романы; 3 нче томда – «Кызыл чәчәкләр» (1921), «Алмачуар» (1922), «Тирән тамырлар» (1928) әсәрләре һәм «Адәмнәр» (1923) повесте, «Яңа кешеләр» (1920) драмасы; 4 нче томда – «Безнең көннәр» романының моңа кадәр хәзерге графикада басылмаган 1919 елгы варианты; 5 нче томда – «Безнең көннәр» романының 1934 елдагы, авторның, мәгълүм шартларга туры китереп, үзе тарафыннан үзгәртелгән яңа варианты урнаштырылды.

Әсәрләрдәге сюжет үзгәрешләре, авторның проблемага карашлары үзгәрүне чагылдырган вариантларны янәшә бирү илдә хөкем сөргән яңа идеология тәэсирендә Г. Ибраһимовның фикер үсешен һәм аның иҗат лабораториясен күзалларга ярдәм итә. Бу ысул Г. Ибраһимов басмаларында беренче мәртәбә тәкъдим ителә.

Академик басманың 6–8 нче томнарында урын алган 1910–1933 еллар аралыгында язылган әдәбият, сәнгать темасын яктырткан мәкаләләрдә, хезмәтләрдә Г. Ибраһимовның көрәшче милләтпәрвәр, зур фикер иясе булып җитешүе ачык күренә.

Аерым алганда, 1910–1914 еллар – Г. Ибраһимов иҗатында эзләнү дәвере буларак бәяләнә ала. «Бу чорда яшь иҗатчы әдәбият теориясе һәм тәнкыйтен эшләүнең зарурлыгына төшенә, шушы өлкәдә фикер туплый, позиция булдыра» [Заһидуллина, 2020, б. 120]. 1915–1916 еллар – «Г. Ибраһимовның татар әдәбияты теориясе өлкәсендәге галим, фикер иясе булып җитешү дәвере» [Ибраһимов, 2019, 7 т., б. 9]. Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә әдәбият укыту тәҗрибәсенә нигезләнеп язылган «Әдәбият дәресләре» (1916) хезмәте аның нәзари эзләнүләренең төп нәтиҗәсе булып тора.

Революцион хәрәкәтләрнең идеологик җитәкчеләреннән берсе булган Г. Ибраһимов 1917 елгы инкыйлабтан соңгы елларда да үзенең фәнни эшчәнлеген туктатмый. 1918–1933 елларда язылган әдәбият һәм сәнгать турындагы хезмәтләре академик басманың 8 нче томында урын алдылар. «Бу дәвердә Г. Ибраһимов татар әдәбияты тарихын марксизм ысулы (методы) кулланып өйрәнү, бәяләү концепциясе тәкъдим итә... Моннан Г. Ибраһимовның милләтне үстерү өчен революцияне файдалану омтылышы ачык күренеп тора» [Ибраһимов, 2019, 8 т., б. 8].

«Искене җимереп, яңа азат тормыш төзүдә кызыл штык, чүкеч һәм урак белән бер дәрәҗәдә хезмәт йөкләтелгән кызыл каләм үз өстендәге бурычны үти алсын өчен, эшче-крәстияннең авыр канлы көрәшендә үткен корал белән кызыл каләмгә киң юл ачылсын өчен, һичнәрсәне яшермәскә, авыруны бөтен куркынычы белән ачып бирергә мәҗбүрбез» [Ибраһимов, 2019, 8 т., б. 33], дип, Г. Ибраһимов каләм ияләре алдына яңа бурычлар һәм максатлар куя. Бу чорда Г. Ибраһимов инде 1910 елда ук «Татар матбугаты» мәкаләсендә башлап җибәргән әдәбият, матбугат торышы хакындагы күзәтүләрен дәвам итә. Ел саен

диярлек «Дүртенче елга кергәндә. (Әдәбият, матбугат хисабы урынында)» (1920), «Татар әдәбияты. (Хисап урынында)» (1922), «Татар әдәбияты. (Еллык хисап урынында)» (1924) кебек мәкаләләрдә Г. Ибраһимовның шактый киң бәяләмәләре басылып тора.

Г. Ибраһимов «чыккан әсәрләрне белдерү, аларның телләре, мөндәриҗәләре, хаталары, яхшылыклары белән эшче-крәстиян иптәшләрне таныштыра башларга бик вакыт инде» [Ибраһимов, 2019, 8 т., б. 60], дип, газеталарда «Яңа әсәрләр» бүлеге ачарга тәкъдим итә. Аерым әсәрләргә багышланган мәкаләләре нәкъ шулай атала да. Аларда аерым әдипләр хакында бәяләр урын алган. Г. Ибраһимов коммунист шагыйрь Ф. Борнашның дин рухыннан бөтенләй котылмавын рухында, хыялында аталардан калган зур хаталарның чыгып бетмәвеннән күрә [Ибраһимов, 2019, 8 т., б. 62]. Фатих Сәйфи, Гыйлемдар Баембәтов, Вәли Шәфигуллин кебек исемнәре киң укучылар дөньясына танылган язучылар белән беррәттән Мөхәммәт Парсин, Нур Сәйфи, Зәйнәп Бәширова, Ченәкәй кебек яшь иҗатчыларның каләм тибрәтүләре дә, Фатих Әмирхан һәм Галиәсгар Камалның авыруы да Г. Ибраһимов игътибарыннан читтә калмавы аның әдәби-мәдәни дөнья белән хәбәрдар булганлыгы турында сөйли.

1920 еллардан соң Г. Ибраһимов әдәбият тарихы мәсьәләләренә дә ныклы игътибарын юнәлтә («Берничә сүз» (1921), «Аңларга тырышыгыз! (Татар әдәбиятында өченче дәвер.) (1922), «Татар әдәбияты тарихының мөндәриҗәсен билгеләү мәсьәләсе» (1922), «Татар әдәбияты тарихына материаллар» (1923) һ.б.).

Гомумән алганда, «1917 елдан соң Г. Ибраһимовның һәм сәяси, һәм әдәбият-сәнгатькә, аларның максаты һәм вазифалары, әсәрләрне бәяләү критерийлары мәсьәләләренә карашы, тамырыннан булмаса да, шактый үзгәреш кичерә, сыйнфыйлык рухы белән сугарыла» [Ибраһимов, 2019, 8 т., б. 29]. Академик басманың 8 нче томына кергән мәкаләләр Г. Ибраһимов иҗатындагы барлык үзгәрешләрне күз алдына китерергә ярдәм итәләр.

Моңа кадәрге басмалардан укучылар Г. Ибраһимовны телче-галим буларак таныткан аерым мәкаләләре һәм кайбер хезмәтләренең («Татар сарыфы» (1911), «Татар нәхүе» (1911), «Татар имлясы» (1914), «Татар телен ничек укытырга?» (1916)) зур булмаган өземтәләре белән генә таныш булсалар, әлеге басма галимнең тел гыйлеменә караган барлык дәреслек китаплары, татар теле фонетикасы, алфавит һәм орфография, морфология, синтаксис, терминология мәсьәләләрен эченә алган мәкаләләре, мәктәптә тел фәне укыту методикасына багышланган барлык хезмәтләрен тулысы белән укучылар игътибарына тәкъдим итә.

Г. Ибраһимовның 1910–1928 елларда язылган тел белеменә һәм телне укыту методикасына караган хезмәтләре академик басманың 9 нчы (1910–1917 еллар) һәм 10 нчы томнарында (1918–1928 еллар) туплап бирелде.

Татар теленең грамматик төзелешен тикшерүгә багышланган «Татар сарыфы» (1918), «Тел сабаклары. Беренче китап (әлифбаны үткәч тә яздыра башлау өчен» (1918), «Тел сабаклары. Икенче китап (гамәли имля – иншага, сарыф, нәхүгә хәзерлек) (1919) дәреслекләре тулысынча кириллицада беренче тапкыр дөнья күрәләр.

«Татар сарыфы»ның 1911 елгы беренче басмасы 9 нчы томга, 1918 елгысы 10 нчы томга кертелде. Г. Ибраһимовның әлеге дәреслеге басылып чыгу белән татар мәктәпләрендә рөшди сыйныфлар (4–7) өчен дәреслек буларак кабул ителә һәм тиз арада таралыш ала. Шуңа күрә дә ул, беркадәр кыскартулар, аз гына үзгәрешләр белән, 1913, 1915, 1916 елларда кабат-кабат нәшер ителә. Бу еллар арасында, әлбәттә, тел белеменә караган башка хезмәтләр дә басыла. Галим үзе дә бу хакта китапның «Сүз башы»нда: «“Татар сарыфы”ның дөньяга чыгуына 6–7 ел үтте... Тел-әдәбиятның баштагы өч баскычы булган имля, сарыф *(морфология)* һәм нәхүдә *(синтаксис)* байтак яңа хезмәтләр, яңа әсәрләр туды. Җамалетдин Вәли, Габдрахман Сәгъди, Мөхетдин Корбангали һәм Фатих Сәйфи иптәшләрнең әсәрләре шул җөмләдәндер», – дип, хезмәтне яңадан эшләргә алынуының сәбәпләрен күрсәтә һәм 1918 елда термин-атамаларга, грамматик төркемләүгә шактый үзгәрешләр кертеп, хезмәтнең бөтенләй яңа вариантын эшләп бастыра. Томга үзенең төзелеше һәм мәгънә ягыннан «Бөтенләй яңадан эшләнгән бишенче басмасы» алынды.

«Татар сарыфы», «Татар нәхүе» «хәзерге татар лингвистикасы өлкәсендәге фәнни-теоретик хезмәтләр өчен генә түгел, мәктәп дәреслекләре өчен дә мөһим чыганак, беренче үрнәк булып торалар» [Ибраһимов, 2019, 9 т., б. 17].

Томлыкларда беренче тапкыр урын алган методик хезмәтләр – «Тел сабаклары» дәреслегенең Беренче китабы (1918) һәм Икенче китабы (1919), Г. Ибраһимовның совет чоры өчен каршылыклы булган «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» исемле китабы һәм «“Иҗтимагый икътисад” гыйлемендә беренче тәҗрибәләр» мәкаләсе дә шулай ук Г. Ибраһимовның тел белеменә бәйле иҗат мирасында мөһим урын биләп торалар һәм томның эчтәлеген тагын да баеталар.

Әлеге хезмәтләре белән Г. Ибраһимов XX гасыр башы татар тел белемендә гаять зур роль уйный. Галим, беренчедән, әдәби тел нормаларын халыклаштыруны, терминологияне татар укучысына аңлаешлы итүне төп максат итеп куйса, икенчедән, китапларының басылу белән үк мәктәпләрдә дәреслек буларак кулланыла башлавы аның тел укыту методикасына нигез салучы булуын раслый.

Г. Ибраһимов халкыбызның тарихи үсеш юлын яктыртуга багышлап та шактый күп хезмәтләр язган.

Академик басманың 11 нче томында галимнең 1909–1920, 12 нче томында 1922–1932 еллар аралыгында басылып чыккан тарихка караган һәм милләтебезнең иҗтимагый фикер үсешен чагылдырган хезмәтләре урын алды. Элеккеге тупланмада басылганнарга өстәп,

Г. Ибраһимовның 2 хезмәте: «Борынгы ислам мәдәнияте» (1909), «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан кечкенә бер хатирә» (1922) һәм тагын 20 мәкаләсе кулланылышка кертелде.

Көнчыгыш галиме Җирҗи Зәйдан һәм Көнбатыш авторы Гюстав Лебон хезмәтләренә таянып язылган күләмле «Борынгы ислам мәдәнияте» хезмәтенең үз заманы татар укучысы өчен әһәмияте зур булган. Биредә Г. Ибраһимов ислам мәдәниятенең җаһилият чорыннан башлап VIII гасырга кадәр тарихын, гомумдөнья цивилизациясе үсешенә керткән ролен ачыклый. Шул рәвешле, революциягә кадәр Г. Ибраһимовның татар милләтенә, аның тарихына карашы татарларның ислам мәдәниятенә якын булуларын тану, шул ук вакытта аларның төрки кавемнең аерым бер вәкиле, әмма үзенә бер милләт – татар халкы булуы идеясенә нигезләнә [Ибраһимов, 2021, 11 т., б. 11].

Халкыбызның тарихын эзлекле өйрәнүнең мөһимлеген алга сөргән «Ихтиляф вә риваять» (1912), «Рус, төрек вә татар тарихыннан» (1913) кебек мәкаләләрдә, нигездә, татар тарихын тикшерү принциплары яктыртылган. Г. Ибраһимов үзенең язмаларында татар тарихына, аерым тарихчыларга һәм аларның хезмәтләренә мөнәсәбәтле рәвештә үз фикерләрен җиткерү белән генә чикләнеп калмый, тарихны ничек язарга кирәклегенең нигезләренә төшендерә. «Милли тарих» (1912) мәкаләсе белән, беренчеләрдән булып, милли историографиягә нигез сала. Ул милли тарихны өйрәнүче татар галимнәрен барлый (Р. Фәхреддин, М. Рәмзи, Г. Әхмәров, Х. Габәши, Һ. Атласи, Й. Акчура, З. Вәлиди һ.б.), аларның хезмәтләренә кыскача күзәтү ясый.

1918–1920 елларда язылган мәкаләләре инкыйлабка кадәр нәшер ителгән язмалардан аерылып тора. Революция елларында формалаша башлаган яңа идеология Г. Ибраһимов иҗатында да күзәтелә. Шул ук вакытта галимнең революциядән соң беренче еллардагы язмаларында тематик төрлелек саклана («Мәркәз мөселман комиссариатының мәрхүм Милли Идарә эшләре хакындагы хисабы мөнәсәбәте илә бер-ике сүз». (1918), «Шәрыкның бөек революционеры “Мулланур иптәш Вахитов”» (1919), «Сарайларга – сугыш, фәкыйрь өйләргә – туганлык!» (1920), «Париж пролетариатының диктатурасы» (1920)).

Галимҗан Ибраһимов матбугат битләрендә заманының көндәлек вакыйгаларына үзенең карашын, мөнәсәбәтен белдереп барган язмалары белән ялкынлы публицист буларак та танылa. Аның публицистик эшчәнлеге шактый зур вакыт аралыгын үз эченә ала. Бу еллар – идеологик яктан да кискен үзгәрешләр кичергән чор. Шуңа күрә әлеге басмада инкыйлабка кадәр язылган мәкаләләр (1907–1918) 13 нче томга һәм инкыйлабтан соң язылганнары (1919–1931) 14 нче томда урын алды.

Г. Ибраһимов «Әлислах», «Йолдыз», «Аваз», «Аң» (Казан), «Вакыт» (Оренбург), «Тормыш», «Ирек», «Безнең юл» (Уфа) кебек газета-журнал битләрендә басылган мәкаләләре белән инде революциягә кадәр үк үзен публицист итеп таныта, соңрак аның эшчәнлеге тагын

да активлаша, язмалары шул чорда чыккан «Эш», «Татарстан хәбәрләре» («Татарстан», «Кызыл Татарстан»), «Кызыл Шәрык», «Кызыл Шәрык яшьләре», «Безнең байрак», «Октябрь яшьләре», «Кызыл Армия», «Эшче» һ.б. матбугат битләрендә дә дөнья күрә. Г. Ибраһимов мәкаләләрен төрле имзалар белән («Әлислах мөхбире», «Мөхбиреңез», «Габди», «Г. И.», «Г-җан», «Гыйрфанзадә», «Джанъ», «Тыңлаучы» һ.б.) бастыра. Бу имзаларның анықы булуы алдагы басмаларда да, төрле галимнәрнең аерым хезмәтләрендә дә инде расланган.

Г. Ибраһимовның матбугат битләрендә урын алган беренче публицистик мәкаләләре мәдрәсәләрдәге иске тәртипләрне яктыртуга юнәлдерелгәннәр. Шул рәвешле ул мәдрәсәләрдәге иске тәртипләргә каршы көрәшкә күтәрелә. Яшь публицист «Мәдрәсә хәбәрләре» рубрикасында газета укучыларны мәдрәсә хәлләре белән даими таныштырып килә. Моңа кадәрге басмалардан билгеле булган «Уфа мәдрәсәләре» (1907), «Шәкертләр аһ-зары» (1908), «Мәдрәсә чуалулары» (1913) исемле мәкаләләренә өстәп, укучыларга «Кыешкы мәдрәсәләре» (1908), «Шәкертләр һәм уку» (1908), «Уфа, мәдрәсәи Галиядә тентү» (1909) мәкаләләре дә тәкъдим ителде.

1909–1916 еллар матбугатында Г. Ибраһимов күптөрле темалар белән чыгыш ясый. Аның 1911 елда Казанда китап басу эшенең торышын яктырткан «Казан китапчылары» («Вакыт»), «Казан китапчыларының рәддиясе *(кире кагуы)* хакында», «Дәгъвәт» («Йолдыз») мәкаләләре игътибарга лаек.

Г. Ибраһимовның публицистикасында милләт мәсьәләсе зур урын алып тора. Шулай ук хатын-кыз темасы да аның каләменнән читтә калмый. «Хатын язмышы» («Аң», 1913), «Хатын-кыз дөньясы» («Тормыш», 1914) язмаларында автор үзен кызыксындырган сорауларга җавап эзли.

1917 елгы Февраль инкыйлабы Г. Ибраһимов публицистикасын яңа кыйблага юнәлтә. 1917 елгы Октябрь инкыйлабын ул бәйсез фикерле ялкынлы публицист буларак каршы ала.

Галимҗан Ибраһимов инкыйлабтан соң, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе буларак, илдә барган зур үзгәрешләр үзәгендә була, публицистик язмаларында шул вакыйгаларда катнашучы һәм аларга үз мөнәсәбәтен белдерүче шәхес буларак та ачыла. Ул катлаулы вакыйгаларны читтән торып күзәтүче генә түгел, ә иҗтимагыйсәяси вакыйгалар эчендә үзе дә кайный. «Дошманнар арасында дүрт ай» (1919) мәкаләсендә дә ул Себердә йөргән чакта күргәннәрен сөйли.

1920 еллар башында Г. Ибраһимовның Татарстан җөмһүрияте төзелүе уңай яктан бәяләнгән берничә мәкаләсе дөнья күрә («Икенче елга кергәндә» (1921)).

«Ислам тирәсендә» (1923), «1 нче Май уйлары» (1924) исемле мәкаләләрдән 1917 елдан соң аның дингә карашы тискәре якка үзгәрү чагыла. Мулла сүзен ул искелек, тупаслык белән тиңләштерә, совет бәйрәмнәрен дини бәйрәмнәргә каршы куя.

«Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар» (1924) Г. Ибраһимовның Совет чоры публицистикасында аерым урын алып тора. Анда чит илләрдә яшәгән М. Бигиев, Г. Исхакыйларның совет хакимиятенә каршы язылган китапларына тәфсилле күзәтү ясалган һәм алар авторның каты тәнкыйть утына эләккән.

Академик басмада укучыларга Г. Ибраһимовның моңа кадәрге күптомлыкларына кермәгән 74 публицистик мәкаләсе тәкъдим ителде. 13, 14 нче томнарда урын алган публицистик язмалар фикер иясенең дөньяга карашын яңача ачарга ярдәм итә.

Әдипнең автобиографияләре, хатлары, тормышы һәм эшчәнлегенә мөнәсәбәтле документлары 15 нче томга тупланып бирелде. Моңа кадәр 2000 елда Г. Ибраһимовның 8 томлы басмасына өстәмә буларак басылган тугызынчы «Хатлар һәм документлар» томы (төзүчесе Ф.И. Ибраһимова), 2012 елда «Галимджан Ибрагимов: документы и факты. Галимджан Ибрагимов глазами молодых» (төзүчесе М.Х. Ибраһимов) һәм 2020 елда «Галимҗан Ибраһимов – документларда: 2 томда» (төзүчесе Р.Ф. Исламов) китаплары дөнья күргән иде. Әдипнең шәхесенә бәйле документлар шактый күп җыелганлыктан, әлеге китапларны да истә тотып, эчтәлек ягыннан кабатлана торганнарын (мәсәлән, Анкета) 15 нче томга кертү кирәк табылмады. Томда документлар чыганак телендә бирелде.

Төрле стильдә язылган хатлар Г. Ибраһимовның эпистоляр жанр остасы булуын да күрсәтә. Әдипнең 1921, 1929 һәм 1936 елларда язылган автобиографияләре аның үз тормышында булган үзгәрешләрне генә түгел, илдәге сәяси һәм иҗтимагый вазгыятьне дә чагылдыра.

Г. Ибраһимовның тел, әдәбият белеменә караган, XX гасыр башы татар иҗтимагый хәрәкәте тарихын тикшерүгә багышланган хезмәтләре, шул дәвернең әһәмиятле тарихи һәм мәдәни вакыйгаларына күзәтү ясаган публицистик язмалары бүгенге көндә дә актуаль. Алар үз заманының иҗтимагый-сәяси фикер көрәшен гәүдәләндерү белән бергә, бүгенге тормышыбызны да тирәнрәк аңларга, милләтебезнең үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә бәйле уй-фикерләребезне, омтылышларыбызны ачыклауга хезмәт итәрдәй хосусиятләрен дә югалтмаганнар.

Г. Ибраһимов иҗатын кайтару юлында әдәбиятчы-текстологлар – Ә.Х. Алиева, К.Г. Әхсәнов, Г.Г. Батыршина, Э.М. Галимҗанова, Г.Н. Зәйниева, З.Г. Мөхәммәтшин. Ф.Г. Фәйзуллина Г.М. Ханнанова, Г.А. Хөснетдинова тарафыннан зур хезмәт куелды. Алар үз алларына куйган максатка ирешү өчен, гаять зур күләмле бу эшне академик төгәллек белән башкарып чыктылар.

Томнарга филология фәннәре докторы Д.Ф. Заһидуллина («Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлы һәм киңкырлы эшчәнлеге», «Әдәби тәнкыйтьне һәм сәнгать теориясен үстерү – милли мәдәният ихтыяҗы: Галимҗан Ибраһимов», «Галимҗанов Ибраһимов – әдәбият теоретигы», «Галимҗан Ибраһимов – марксистик әдәбият фәне тудыруның үзәгендә»), филология фәннәре кандидаты Б.Э. Хәкимов («Гыйлем һәм гамәл берлеге»), тарих фәннәре кандидаты

К.Г. Әхсәнов («Галимҗан Ибраһимов: тарихтан – инкыйлабка», «Галимҗан Ибраһимов каләмендә – инкыйлаб һәм татар иҗтимагый хәрәкәтләре тарихы»), тарих фәннәре кандидаты Ә.А. Гатин («Галимҗан Ибраһимов – публицист»), публицист һәм төбәкне өйрәнүче М.Х. Ибраһимов («Галимҗан Ибраһимовның тормышы һәм эшчәнлеге документларда») тарафыннан язылган күләмле кереш мәкаләләр Г. Ибраһимовның күпкырлы эшчәнлеген яктыртуда мөһим роль уйныйлар.

Әлеге 15 томлы академик басма милли мәдәниятебезгә һәм әдәбиятыбызга битараф булмаган укучыларыбыз тарафыннан хуплап каршы алыныр, киңкырлы шәхес тә үзенә лаеклы югарылыкта һәм текстологларның хезмәтләре дә тиешле бәяләнер, дип өметләнәбез.

**Әдәбият**

*Алиева Ә.Х., Зәйниева Г.Н.* Г. Ибраһимовның яңа басмасы // Фәнни Татарстан, 2019. № 1. Б. 33–47.

*Заһидуллина Д.Ф.* Г. Ибраһимов – әдәбиятчы: яңа чыганаклар (15 томлык академик басманың 6–7 томнары басылу уңае белән) // Фәнни Татарстан, 2020. № 2. Б. 114–125.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 512 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр. Академик басма: унбиш томда. 6 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1914) / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Г. Мөхәммәтшин; кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 327 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Академик басма: унбиш томда. 7 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1915–1916) / [төз.: Г.М. Ханнанова, З.Г. Мөхәммәтшин; текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Г. Мөхәммәтшин; кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 375 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Академик басма: унбиш томда. 8 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1918–1933) / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Г.А. Хөснетдинова; кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 431 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Академик басма: унбиш томда. 9 т.: татар тел белеменә һәм телне укыту методикасына караган хезмәтләр / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Ә.Х. Алиева; кереш сүз авт. Б.Э. Хәкимов]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 383 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Академик басма: унбиш томда. 10 т.: татар тел белеменә һәм телне укыту методикасына караган хезмәтләр / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Э.М. Галимҗанова, Ф.Г. Фәйзуллина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 351 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Академик басма: унбиш томда. 11 т.: тарихка һәм иҗтимагый фикергә караган хезмәтләр (1909–1920) / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Ә.Х. Алиева]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. 462 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Академик басма: унбиш томда. 12 т.: тарих һәм иҗтимагый фикергә караган мәкаләләр, хезмәтләр (1922–1932) / [төз.: Г.М. Ханнанова, Г.А. Хөснетдинова; текст. әзерл.: Г.А. Хөснетдинова, Г.М. Ханнанова, Э.М. Галимҗанова; иск. һәм аңл. әзерл.: Г.А. Хөснетдинова, Г.М. Ханнанова, К.Г. Әхсәнов; кереш сүз авт. К.Г. Әхсәнов]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. 599 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Академик басма: унбиш томда. 13 т.: публицистика (1907–1918) / [төз., иск. һәм аңл. әзерл. Ф.Г. Фәйзуллина; кереш сүз авт. Ә.А. Гатин]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. 421 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Академик басма: унбиш томда. 14 т.: публицистика (1919–1931) / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Э.М. Галимҗанова]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. 415 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Академик басма: унбиш томда. 15 т.: документлар һәм хатлар / [төз., текст., иск. Һәм аңл. әзерл: Г.Н. Зәйниева, Ф.Г. Фәйзуллина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. 599 б.

*Рәмиев З.З.* Институт эшчәнлегендә әдәбият белеме мәсьәләләре // Фәнни Татарстан, 2019. № 3. Б. 108–119.

***Фәйзуллина Фәния Галимулла кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 82.091

*Шәриф Байчура*

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ БЕЛӘН ОЧРАШУЛАР
## (Истә калганнардан)

В отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан хранится фонд Узбека Байчуры. Основу фонда составляют 527 книг и архивные документы. Хронологические границы коллекции охватывают 1979–1996 годы.

Наряду с книгами и документами языковеда Узбека Байчуры в фонде находятся материалы, касающиеся его отца журналиста Шарифа Байчуры и матери врача Амины Алимбек. В нашем случае интересны воспоминания, связанные именно с личностью Шарифа Байчуры.

Шариф Байчура – татарский журналист XX века, который внес огромный вклад в татарскую журналистику и вел активную деятельность во времена Советской власти. В молодости он был хорошо знаком с видными деятелями татарской интеллигенции того времени – Г. Тукаем, Ф. Амирханом, Г. Такташем, К. Тинчуриным, Г. Ибрагимовым. Через несколько лет Шариф Байчура и сам стал опытным публицистом и переводчиком, опубликовал воспоминания, связанные с этими писателями, поэтами. Все эти документы хранятся среди архивных материалов фонда Узбека Байчуры. Один из таких документов – воспоминания Шарифа Байчуры, связанные с писателем, ученым, публицистом, общественным деятелем Галимджаном Ибрагимовым. Эта статья была опубликована в 1967 году в газете «Социалистик Татарстан». Надеемся, что этот памятник будет интересен и современному читателю.

**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, литература, публицистика, языкознание, революция.

There is the Uzbek Baichura fund in the department of manuscripts and rare books of the National Library of the Republic of Tatarstan. The basis of the fund consists of 527 books and archival documents. The chronological boundaries of the collection cover the period 1979–1996.

In addition to the books and documents of the Uzbek linguist Baichura, the fund contains materials concerning his father, journalist Sharif Baichura and the mother, doctor Amina Alimbek. In our case, the memories that are interesting are those that relate specifically to the personality of Sharif Baichura.

Sharif Baichura is a tatar journalist of the 20th–century who made a great contribution to the field of tatar journalism and became active during the Soviet era. He was well acquainted with prominent figures of the tatar intellectuals of the time – G. Tukai, F. Amirhan, H. Taktash, K. Tinchurin, G. Irbragimov. Several years later Sharif Baichura became an experienced publicist and translator, he published memories related to these writers, poets. All these documents are kept among the archives of the Uzbek Baichura foundation. One such document is the memoirs of Sharif Baichura related to the writer, scientist, publicist, public figure Galimjan Ibrahimov. This article was published in 1967 in the newspaper «Socialist

Tatarstan». We hope that this monument, connected with the personality and activity of the writer, will be of interest to the modern reader as well.

**Keywords:** Galimjan Ibrahimov, literature, journalism, linguistics, revolution.

*1997 елдан алып Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Үзбәк Байчура фонды эшләп килә. Фондның төп өлешен 527 китап һәм архив документлары тәшкил итә. Әлеге материаллар 1979–1996 еллар аралыгын колачлый.*

*Фондта Үзбәк Байчураның шәхси китаплары һәм документлары белән беррәттән, галимнең әтисе журналист Шәриф Байчура һәм табибә Әминә Алимбәккә караган материаллар да саклана. Әмма безнең өчен нәкъ менә Шәриф Байчураның үзе белән бәйле истәлекләр кызыклы.*

*Шәриф Байчура – XX гасыр татар журналистикасына зур өлеш керткән, Совет власте елларында актив җәмәгать эшчәнлеге алып барган шәхес. Хезмәтенең башлангыч чорында ук Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Һ. Такташ, К. Тинчурин, Г. Ибраһимов кебек танылган татар зыялылары, талант ияләре белән якыннан таныш булган. Еллар үтеп, үзе дә шактый тәҗрибә туплаган журналист булып җитлеккәч, Шәриф әлеге шагыйрьләр, язучылар белән булган истәлекләрен мәкалә итеп язып бастыра. Бу материаллар барысы да Үзбәк Байчура фондында саклана. Укучылар игътибарына шундый мәкаләләрнең берсен – язучы, галим, публицист, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов белән бәйле хатирәләрне тәкъдим итәбез. Язма 1967 елда «Социалистик Татарстан» газетасында басылып чыккан. Әлеге истәлек хәзерге заман укучысы өчен дә шактый мавыктыргыч һәм файдалы чыганак булыр дип уйлыйбыз.*

Бу моннан 56 ел элек – 1911 елның җәй башында булды. Мин ул вакытта бер хосусый типографиядә корректор булып эшли һәм шул ук вакытта рус теленнән укытучы булырга хәзерләнә идем.

Рус телен мөмкин кадәр яхшырак үзләштерү һем практик яктан да ныгыту теләге белән, ул замандагы татар яшьләренең рус семьяларыннан бүлмә алып, рус укымышлылары белән аралашып торырга омтылулары бик табигый хәл иде. Классик язучыбыз Фатих Әмирханның «Яшьләр» һәм «Урталыкта» дигән әсәрләрендә бу заман яшьләре тормышыннан шундый күренешләр бик ачык тәсвир ителә. Мин дә бу елны хәзерге Спартак (элекке Әрмәнски) урамының 16 йортында Казан хәрби интендантствосы чиновнигы Спасский квартирында бер гимназист һәм бер художество мәктәбе укучысы белән берлектә аерым бүлмә алып тора идем.

Беркөнне кич белән минем эштән кайткан төшемә хуҗаның өй хезмәткәре:

– Сезгә нииндидер бер төргәк калдырып киттеләр, – дип каршылады. Мин, моңа гаҗәпләнеп, кайдан, нинди төргәк китергәннәр дип, бер кәгазь төргәген ачып карасам, ул кайсыдыр типографиядән

җибәрелгән корректура булып чыкты. Яхшылап тикшерә торгач, аның шул елларда әдәбият мәйданына чыккан һәм тиз арада күренекле язучы булып үсеп барган Галимҗан Ибраһимовның беренче әсәре – «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән хикәясенең корректурасы икәне беленде. Аның бу әсәре 1907–1908 елларда шәкертләр органы – «Әлислах» газетасында Фатих Әмирханның турыдан-туры булышлыгы һәм редакцияләве белән газетаның күп санарына сузылып басылып килгән иде. Хәзер исә аның аерым китап итеп басылуы икән. Сораштыра торгач, ул корректураның миңа килеп эләгүенең сәбәбе дә аңлашылды. Г. Ибраһимов бу вакытта шул ук Әрмәнски (хәзерге Спартак) урамында бишенче йортта тора икән. Типографиядән җибәрелгән кыз аны таба алмыйча урамда аптырап йөргәндә, кемдер берәү «Менә бу йортта типографиядә эшләүче бер татар егете тора» дигәч, төргәкне миңа калдырып киткәнлеге беленде. Мәсьәлә ачыклангач, мин икенче көнне кич белән Г. Ибраһимов иптәшне эзләп таптым.

Өй ишеген шакып, сорап кергәч, мине уртача буйлы, озын кара чәчен артка таба шомартып тараган, кара мыеклы, коңгырт кара күзле, өстенә кара сатин күлмәк киеп, биленә киң каеш бәйләгән, чалбар балакларын итек кунычына кертеп кигән мөлаем кыяфәтле егерме биш яшьләр тирәсендәге егет каршылады. Бу – Галимҗан Ибраһимов иде. Аның бу елларда үзенең тышкы кыяфәтен М. Горькийга охшатырга тырышканлыгы күпләргә мәгълүм нәрсә. Минем башыма кылт итеп шул фикер килеп китте.

Г. Ибраһимовның ул вакытларда ук инде демократ табигатьле кунакчыл кеше икәнлеген аны белгән күп кешеләр хәтерли булса кирәк. Ул тиз генә чәй хәзерләтеп алды һәм без – беренче очрашкан кешеләр шактый вакыт төрле темаларга карата сөйләшеп утырдык. Күбрәк ул сөйләде, мин сораулар гына биргәләп утырдым. Бу вакытларда инде аның башлыча «Йолдыз» газетасында байтак кына мәкаләләре чыгып өлгергән, татар әдәбиятының барышы турында еллык отчетлары басылып килә. Шуңа күрә аның фикер ягыннан шактый үскән, мәгълүматы да байтак киң икәнлеге һәр сүзеннән күренеп тора иде. Минем Тукай һәм Фатих Әмирхан иҗатларына карашы турында биргән сорауларыма да ул кыскачарак кына, ләкин уңай җавап бирде, чөнки бу чакта әле ул бу язучыларга карата уңай позициядә тора иде.

Менә шушы күрешүдән соң миңа Г. Ибраһимов белән тагын да очрашкаларга туры килде. Кайчакларда урамда очрашып-сөйләшеп йөрүләр дә булгалады. Бу елны ул һәрвакытта башына котелок (каты кара эшләпә), өстенә соры калын чикмән киеп йөрде. Моннан соңгы елларда инде материаль ягы яхшыра бару белән кием дә үзгәрә барды: җәен күбесенчә панама (эшләпә) өстендә накидка (җиңсез пальто), кышын гади пальто һәм бүрек кия, аякта һәрвакытта күн итек була, йөргәндә ул вак-вак атлап тиз йөри, гәүдәсен төз тота иде.

Революциядән элекке чорда аның белен тагын бер озаклап сөйләшеп утыруым исемдә калган. Бу – 1914 елда, аның «Аң» журналында

секретарьлык иткән вакытында булда. Бу чакта ул хәзерге Куйбышев мәйданы ягыннан килеп Щапов урамына кергәннән соң, тау уртасына кадәр менгәч, уң кул якта урамнан ук агач баскыч белән менеп керелә торган 3 катлы дүртенче номерлы йортның икенче катында, хәзер өченче номерлы квартирада дүрт тәрәзәле якты бүлмәдә тора иде. Бу юлы без аңа мәрхүм язучы М. Гали белән барып чыктык. Татар әдәбиятының үсеше, яшь көчләрнең туып күтәрелеп килүе, «Аң» журналының бу өлкәдә зур эшчәнлек күрсәтүе турында шактый озакка сузылган сөйләшү алып барылды. Без китәргә җыенгач кына, Г. Ибраһимовның якын дусларыннан берсе булган Шәһит Әхмәдиев килеп калды.

Бу күрешүдән соң Г. Ибраһимов озак та тормыйча Казаннан китте һәм беренче империалистик сугыш елларында ул Уфада «Мәдрәсәи Галия»дә укытучылык итте. Февраль революциясен ул Уфада каршылап, анда элек «Ирек», аннары «Безнең юл» газеталарында эшли, 1918 елның гыйнварендә Петроградка Учредительный собраниегә барып, большевиклар белән берлектә аны ташлап чыга. Казаннан барган Мулланур Вахитов белән бергә Милләтләр халык комиссариаты янындагы Мөселман комиссариатын төзү эшенә катнаша, аның органы булган «Чулпан» газетасының фактик редакторы була һәм 1919 елның җәендә яшерен рәвештә дүрт ай чамасы Колчак тылында йөреп кайтканнан соң, шул елның көзендә яңадан Казанга әйләнеп килә.

Бу вакытта мин «Кызыл Армия» газетасында секретарь булып эшлим. Без тагын очрашабыз. Г. Ибраһимов редакциягә еш кына килеп чыккалый. Бу чорда ул әдәби әсәрләр тудырудан бигрәк публицистика белән шөгыльләнә, революциянең барышына, совет шартларында милли культураның үсешенә карата «Кызыл Армия», «Эшче» һәм «Эш» газеталарында әһәмиятле мәкаләләр бастырып килә. Шуның белән бергә, әдәби әсәрләр язуны да бөтенләй читтә калдырмый. «Яңа кешеләр» (1920) пьесасы, «Кызыл чәчәкләр» (1921) хикәясе шул вакытларда дөньяга чыктылар. «Безнең көннәр» романының беренче варианты шул 20 нче елда чыкса да, ул асылда революциядән элек язылган иде. Язучы революция тарихына караган хезмәтләр чыгаруда да активлык күрсәтте. «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» (1922), «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» (1925) һәм башкалар.

1919 ел ахры һәм 1920 ел башларында мин хәзерге Бауман урамындагы «Бристоль» гостиницасында Галимҗан Ибраһимов белән янәшә бүлмәдә яшәдем. Без еш аралаша идек. Бераздан мин аннан күчеп киттем. Шуннан беркадәр вакыт үткәч, Г. Ибраһимов белән бер очрашкан вакытыбызда ул гостиница тормышыннан туйганлыгын сөйләп, кая булса да квартирага чыгарга теләвен белдерде һәм миннән шул турыда сорашкалап каравымны үтенде. Мин бу вакытта хәзерге Зәйни Солтанов урамы, 12 йортта профессор Газиз Гобәйдуллин әтисе квартирында тора идем, шул ук өйдә хосусый йортлардан учетка алынган торак мәйданнарына ордер бирүче район оешмасы да

урнашкан иде. Мин шуннан сорап карарга булдым. Бер-ике көннән Г. Ибраһимов исеменә ордер алдым һәм ул элекке Шиһап Мәрҗани йортындагы (Насыйри урамы, 10) бер квартирага кереп күчеп утырды. Хәзер без тагын күршеләр булдык. Бер атна-ун көн үткәч, мин авылдан хат алдым. Хәзерге Буа районы Аксу авылында укытучы сеңлем авырый икән, кайтып килергә кирәк. Галимҗан минем авылга кайтасымны белгәч:

– Көннәр салкын тора, юл ерак, өстең юка, әнә минем даханы киеп кайт, диде. Аның Уфадан алып килгән бу дахасы эче-тышы мехтан, киң, иркен һәм гаять җылы иде. Мин аны кигәч, салкынның нәрсә икәнен дә белмичә, авылдан бик әйбәт йөреп кайттым.

Г. Ибраһимов күпкырлы талант иде: ул әдип тә, тәнкыйтьче дә, тарихчы да, педагог та, тел галиме дә. Шулай ук орфография мәсьәләсе белән дә җитди шөгыльләнде. Шундай бер вакыйга хәтеремдә калган: 1920 елның көзендә (сентябрьдә булса кирәк) Татарстан Республикасы Совнаркомының беренче председателе иптәш Сәетгалиев җитәкчелегендә хәзерге Щапов урамы, 41 йортта (Машкин йорты) татар теле орфографиясе буенча киңәшмә үткәрелде.

Бу чорда татар әдәби телендә сузык авазларны алты яки ун итеп санап, бу ике агым вәкилләре арасында көрәш бара иде. Республика күләмендә шул агымнарның кайсын рәсмиләштереп тормышка ашыру мәсьәләсен хәл итү өчен барган бу киңәшмәдә, алты сузык ягындагылар белән ун сузык ягындагыларның докладлары тыңланды. Алты сузыкны яклап, доклад белән Г. Ибраһимов чыкты һәм киңәшмәдән соң алты сузыклы орфографияне кабул итү турында Татарстан хөкүмәтенең декреты чыгарылды.

1925–1927 елларда Г. Ибраһимов иптәш Татарстан мәгариф комиссариаты янындагы Гыйльми Үзәк председателе булып эшләве белән бергә В. Ленин әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү эшенә дә җитәкчелек итте. Мин исә «Кызыл Татарстан» газетасында секретарьлык эшен алып барудан тыш, әнә шул тәрҗемә эшләренә дә катнаша идем. Шул уңай белән тагын еш күрешә башладык. Бу вакытта (1922–1923 еллар) ул хәзерге Ленин урамы 21 номерлы йортта тора иде.

Шул чорда Ленин әсәрләрен тәрҗемә итү комиссиясенең бер утырышында булган эпизод исемдә калган. Сүз, мәкаль һәм әйтемнәрне тәрҗемә итү турында бара иде. Утырышны алып баручы Галимҗан Ибраһимов:

– Мин үзем, егетләр, мәкальләрне тәрҗемә итү ягында тормыйм. Мәкальләр ул, күбесенчә, һәр телнең үзенчәлегенә бәйләнешле була. Шуңа күрә тәрҗемә уңышлы чыкмый. Кайбер сирәк очракта әйбәт кенә килеп чыгуы да мөмкин. Ә менә бу «львиная доля» сүзләрен «арыслан өлеше» дип тәрҗемә итүгә килгәндә инде (сүз шул турыда бара иде) минемчә, бу начар булмас иде кебек. Чөнки татарчада бу мәгънәне бирә торган мәкаль юк, диде.

Менә шул рәвештә, Г. Ибраһимов, тәрҗемә өлкәсендә һәрбер үзенчәлекле мәсьәләгә карата зур игътибар белән эш итә иде.

1926 ел башында мин нәшрият һәм матбугат комбинатының редакция коллегиясе секретаре булып эшли башлагач, Г. Ибраһимов белән тагын да ешрак аралашу башланды, чөнки бу редколлегиянең председателе Сафа Борһан булса да, мәгариф комиссариаты вәкиле буларак бу коллегиядә член булып торган Г. Ибраһимов үзенең бу өлкәдәге зур тәҗрибәсе һәм авторитеты белән нәшрият планнарын төзүдә һәм башка төп мәсьәләләрне хәл итүдә үзәк рольне уйнап килде. Бу вакытларда аның миңа телефоннан шалтыратмаган көне аз булгандыр. Шулай ук ара-тирә аның өенә дә барып чыккан вакытлар булгалады. Мәгълүм булганча, бу елларда (1923–1927 еллар) ул хәзерге Комлев урамы, 33 йортта тулы семья тормышы белән яшәде, һәм исәнлеге начарлана башлагач, Кырымга да шул квартирасыннан күчеп китте. Аны озак вакытка Казаннан аерган бу ерак сәфәргә озатучылар арасында бу юлларны язучы да бар иде.

*Текстны басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать*
*институтының халык иҗаты бүлеге аспиранты*
***Хөсәенова Гөлнирә Рәзиф кызы** әзерләде*

УДК 398.86

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# ҖЫР ЖАНРЫНДА ТАКМАКЛАР: ТӨРЛӘРЕ ҺӘМ ФУНКЦИЯЛӘРЕ

Данная статья посвящена исследованию некоторых вопросов татарского народного песенного жанра. Целью исследования является раскрытие жанровых особенностей такмаков, представляющих собой жанр татарского музыкально-поэтического фольклора, исполняющихся в рифмованном песенно-речитативном стиле во время обрядов с игровыми действиями. Научная новизна статьи заключается в том, что данная разновидность народных песен впервые становится объектом специального научного исследования как образцы национального словесного фольклора. Автор классифицирует татарские такмаки, выявляет отличительные и оригинальные черты каждой из групп, обосновывает свои выводы множеством примеров. Полученные автором результаты показывают, что дошедшие до наших дней в составе обрядовых, танцевально-игровых и эпических акций такмаки играют определенную функцию в истории национального фольклора. В исследовании использован структурно-описательный метод.

**Ключевые слова:** татарское народное песенное творчество, такмаки, музыкально-поэтический жанр.

This article is devoted to the study of some issues of the Tatar folk song genre. The aim of the study is to reveal the genre features of takmaks, which are a genre of Tatar musical and poetic folklore, performed in a rhyming song-recitative style during rituals with game actions. The scientific novelty of the article lies in the fact that this kind of folk songs for the first time becomes the object of a special scientific study as examples of national verbal folklore. The author classifies the Tatar takmaks, reveals the distinctive and original features of each of the groups, substantiates his conclusions with many examples. The results obtained by the author show that takmaks that have survived to this day as part of ritual, dance-game and epic actions play a certain function in the history of national folklore. A structural-descriptive method was used in the study.

**Keywords**: Tatar folk song art, takmaks, musical and poetic genre.

Татар халкының җыр мирасы – төрле бизәклләрдән тукылган моңлы, шигъри бер дөнья. Халык җырының хискә, мәгънәгә бай нәфис сүзләре һәм гамьгә, дәрткә бай тылсымлы музыкасы халыкның рухи бөтенлеген һәм тиңдәшсез талант иясе булуын раслый. Татарларның җыр хәзинәсендә чал тарих авазлары да, бүгенге көннәр аһәңе дә тирән булып уелган.

Жанр үзенчәлеген шигъри хәзинә буларак тикшергәндә татар традицион җыр мирасын дүрт төркемгә бүлеп карау кабул ителгән: йола җырлары; уен-бию җырлары; тарихи җырлар; лирик җырлар.

Шушы төркемнәрнең берсе булган уен-бию җырларының зур өлешен такмаклар алып тора. Такмаклар – татар халык музыкаль-

поэтик фольклорының йолалар вакытында көйләп такмаклау стилендә башкарыла торган, уен элементына ия жанры, халык иҗатының төрле жанрлары составында очрый. Бу – күп кенә халыклар иҗатында урын алган бик борынгы жанр төре. Алар кешелек дөньясының сабыйлык чорында ук, җыр-биюләр, хезмәт эшчәнлегенә һәм йолаларга кушылып, музыка коралларына кадәр үк барлыкка килгәннәр һәм, киң таралып, музыканы алыштырып яшәгәннәр. «Бию такмакларының тамырлары, һичшиксез, шаман камлау текстлары һәм биюләре, шулай ук күмәк культ-танцылар музыка коралыннан бәйсез башкарылган заманнарга ук барып тоташа» – дип яза М. Бакиров, әлеге жанр төре килеп чыгышының борынгылыгын ассызыклап [Бакиров, б. 333].

Билгеле булганча, фольклор әсәренең төп билгеләреннән берсе – синкретиклык, йола комплексында очрый торган җыр-такмак текстлары да – әнә шул җитди билгенең күркәм мисалы. Йола фольклоры поэзиясе һәм уен-бию такмаклары – җыр жанрының йола яки уен барышында реальләшә торган төре. Нәкъ менә шушы аерылгысыз бәйләнештә булу сыйфаты, ягъни күптөрле нәүрүзләрнең, келәүләрнең, сөрәннәрнең, арбауларның һәм сыктауларның, такмак-такмазаларның һәм җырларның теге яки бу йола, уен барышына логик һәм эстетик бәйләнгән булуы, аларның шул бәйләнештән башка җанлы яшәештә бик сирәк очравы бу катлаулы иҗат дөньясының уртак сыйфаты, асыл сыйфаты итеп карала да.

Такмаклар – фәнни тикшеренүләрдән бөтенләй читтә калган жанр төре дип әйтә алмыйбыз, аларның жанрлык сыйфатларына, төп поэтик үзенчәлекләренә галимнәребез хезмәтләрендә күпмедер дәрәҗәдә игътибар бирелгән; татарлар яши торган төрле төбәкләрдә язып алынган, халык арасында аеруча киң таралган үрнәкләр «Татар халык иҗаты» академик томнарында урын алган, текстлар хакында белешмә дә китерелгән [Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары, б. 5–30]. Татар халык җырларын сүз сәнгате буларак өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтендә К.М. Миңнуллин такмакларны уен җырларының композицион бер өлеше, кушымтасы дип билгели [Миңнуллин, б. 57]. И. Надиров та аларны хаклы рәвештә уен жанрының аерылгысыз өлеше дип таный [Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары, б. 23]. Соңгы чор фольклористикасында галимнәр тарафыннан такмакларның борынгылыгына, башка жанрлар белән керешүенә дә әһәмият бирелә килә, әйтик, халыкның сөрән йоласы комплексында йола җыры буларак, шулай ук эпик җыр сыйфатында эпос-дастаннарда чагылыш тапкан такмаклар фәнни тикшеренүдә җитди фольклор материалы буларак карала [Мухаметзянова, Миннуллин, с. 5–14].

Татар халкында популяр такмакларның, асылда, төп ике төрен аерып күрсәтергә мөмкин: уен такмаклары һәм бию такмаклары. Аларның бердәмлеге – икесенең дә халык җырлары жанрына каравында, эстетик функцияләрендә, бию белән бәйләнгән булуларында; төп аермалары исә – биюнең бер очракта, ягъни бию такмакларында

тоташтан баруында, икенче очракта, ягъни әйлән-бәйлән уеннарында – уен хәрәкәтләре һәм сүзләре белән аралашуында.

Бию такмагы белән уен такмагы арасындагы уртаклык һәм аермалар мисалларда ачык күренә. Икесенең дә биетүгә хезмәт итүләрен, тиз һәм еш кабатлана торган хәрәкәт ритмына корылуларын да бию һәм уен такмакларының уртаклыгы дип күрсәтергә мөмкин. Такмак көйләрендә милизмнар, ягъни музыкаль орнамент-бизәк юк дәрәҗәсендә. Янә килеп, аерым бию такмакларының да, уен такмаклары кебек үк, махсус көйләре бар, хәлбуки, байтагы иркен рәвештә теләсә нинди көйгә башкарыла. Менә үз көе булган, яисә ярым көйләп яки төрле көйләргә кушылып әйтелә-көйләнә торган «Әпипә» тамагы:

Бас, кызым Әпипә,
Син басмасаң, мин басам;
Синең баскан эзләреңә
Мин дә китереп басам.

Бас, кызым, эзенә,
Күз тимәсен үзеңә;
Асыл гөлләр үсеп тора
Синең баскан эзеңә.

«Әпипә»дән тыш «Әнисә», «Бие-бие, Хәйбулла», «Бие, бие, бие әле», «Бас, бас, каты бас» һ.б. такмаклар да шактый озын, буйдан буйга бию белән кушылып баралар, ягъни тоташы белән биетү тексты буларак характерланалар:

Бие, бие, Хәйбулла,
Биегән кеше бай була;
Биегән кеше бай булса да,
Кесә ягы сай була.

Бие, бие, Хәйбулла,
Биегән кеше бай була;
Бай булмаса, тук була,
Ашарына юк була.

Бие, бие, Хәйбулла,
Биегән кеше бай була;
Биегән кеше бай булганчы,
Карт алаша тай була.

Ә уен такмагы чагыштырмача кыска була һәм әйлән-бәйлән җырларының биетү өлешен генә тәшкил итә. Менә, мәсәлән, «Кайсыгызны сайлап алыйм» уенында кара-каршы тезелгән яшьләр бер яктан икенче якка йөреп такмаклар әйтешәләр һәм, аларның эчтәлегенә карап, үзләренә иптәш сайлыйлар:

Агыйделнең аръягында
Үсә микән бөрлегән;
Кайсыгызны сайлап алыйм,
Барыгыз да бер дигән.

Уен вакытында икенче якка барырга теләмәгән кеше чакыруны кире кага:

Өстемдәге күлмәгемнең
Җиң очлары тар түгел;
Син бит матур, матурны эзлә,
Мин бит сиңа пар түгел.

Әмма нәкъ менә строфалар (куплетлар) саны шактый булганлыктан, күпчелек бию такмакларының текстларына тотрыклылык хас түгел, аларда сюжеттан сюжетка, образдан образга бәйләнеш-күперсез күчү күзәтелә.

Бию такмакларының да, уен такмакларының да төп функциясе ял итүчеләрне биетүгә, күңелләрен күтәрүгә кайтып кала. Бүгенге көндә такмакларның тормыштагы урыны, нигездә, бәйрәм-мәҗлесләрдә башкарыла торган уен-биюләр белән бәйле. Алардагы төп мотив биюгә өндәү-кыстау, биючегә мөрәҗәгать итү, аның хәрәкәтләрен хуплау, осталыгына соклану яисә шаяртып көлү, тексттагы шаян сүзләр аша бәйрәмдә катнашучыга әйтер сүзеңне җиткерергә омтылудан гыйбарәт («Бас, кызым, катырак», «Әнә шулай тыпырда» һ.б.):

Бас, кызым, катырак,
Сындыр идән тактасын;
Сындырсаң идән тактасын,
Кияү түләр акчасын.

Бас, кызым, катырак,
Идәннәре селкенсен;
Идәннәре селкенсен дә,
Кияү күңеле җилкенсен.

Уен-бию җырларының һәм такмакларының шигырь төзелеше силлабик, ягъни үзара тәңгәл тезмәләрдә иҗекләрнең бер үк санда килүенә нигезләнгән була. Чыннан да, такмакларны көйсез укып та булмый, алар ихтыярсыздан ритмга салынып әйтелә башлый. Бу аларның рифмалары һәм ритмнарының бик тә төгәл булуыннан килә.

Татар халык җыр жанрында такмаклар дип билгеләнә торган төрнең тагын бер үзенчәлеге турыдан-туры аларның вазифасы – йола, бию хәрәкәтләренә ритм, темп биреп торулары белән бәйләнгән: йола җырларындагы кебек, аларда еш кына бернинди эчтәлеге булмаган, әмма матур, шома яңгыраган сүзләр тезмәсе билгеле бер урын ала. Бу аерым җырларның исемнәреннән үк күренеп тора: «Ал итә, итә, итә», «Айдыр-дугая», «Импаира-тиритур», «Әннәгизә-генәем, «Әлләрәйләзәйлирәйлә» һ.б.:

Импаира-тиритур,
Импаира-тиритур;
Киң кырларда сабан сөрә –
Колхозчы егет бит ул.

Агыйделнең аръягында
Җырлап утын кисәләр;
Безгә дигән яшь матурлар
Колхозларда үсәләр.

Такмакның һәр сүзе биюче хәрәкәтенә, аның гамәленә бәйле. Аларда биюгә өндәү-кыстау, биючегә мөрәҗәгать итү, аның хәрәкәтен хуплау яисә шаяртып көлү нюанслары ярылып ята. Бию такмаклары, борынгы жанр буларак, әле биюләр музыка коралларыннан башка үтәлгән заманнарда ук туган һәм музыканы алмаштырып яшәгән. Такмакның үсүе ялгыз строфадан күп строфалылыкка, куплетлар арасындагы бөтенлеккә, сюжетлылыкка омтылу юнәлешендә барган дип уйларга урын бар. Хәзерге көннәргә кадәр телдә сакланган «Әпипә», «Әнисә», «Мич артында сары май», «Бие, бие, Хәйбулла» такмакларында без әнә шул бөтенлек, сюжетлылык билгеләрен күрәбез:

Мич артында сары май,
Юктыр аның сызыгы;
Туйга килеп биемәгәч,
Юктыр аның кызыгы.

Сикереп төштем биергә,
Аяк астым таш кына;
Туйга килеп биемәгәч,
Нигә булдың башкода?

Биек тауның башында
Ябалаклар азыгы;
Туйга килеп биемисең,
Әллә капка казыгы?

Әтәчтә дә бер исем,
Тавыкта да бер исем;
Туйга килеп биемәгәч,
Ник ир булып йөрисең?

Әй, имерә-имерә,
Имерә сөяк кимерә;
Кода кайда йөри икән?
Кодача идән җимерә.

Имән микән сайгагы?
Юкә микән сайгагы?
Имән булса бик чыдар,
Юкә булса шарт сынар.

Бас, кызым Әпипә,
Син басмасаң, мин басам;
Актык кызымның туенда
Басып калыйм ичмасам.

Бас, кызым, бас әйдә,
Шул «Әпипә» көенә;
Баса белмәгән туташлар
Кайтып китсен өенә.

Тора-бара биюләр музыка коралларына, бигрәк тә гармунга ияреп яши башлаган. Фольклорның «тере» үрнәге булган такмаклар – күңел ачу чарасы буларак, чагыштырмача яшәүчән жанр, аларны татарлар яши торган төрле төбәкләрдә бүген дә очратырга мөмкин.

Уен-бию җырлары буларак характерлана торган такмаклар татар халкының сурәтле фикерләү мәйданы иксез-чиксез икәнлеген, ә туган телебезнең сыгылмалы һәм шигъри бай булуын исбатлый. Татар халкының җыр жанрын баета торган такмакларны милли фольклорның бүгенге көндә дә шактый актив яши торган төре дип билгелибез. Гомуми нәтиҗә ясап әйткәндә, татар халкының милли йолалары һәм бәйрәмнәре, күңел ачу һәм ял итү традицияләре белән тыгыз үрелгән поэтик байлыгы – бүген дә үзенең тарихи-танып белү һәм эстетик кыйммәтен югалтмаган кадерле бер мирас, олы бер хәзинә ул.

**Әдәбият**

*Бакиров М.* Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 359.

*Миңнуллин К.М.* Һәр чорның үз җыры. Казан: Мәгариф, 2003. 400 б.

*Мухаметзянова Л.Х., Миннуллин К.М.* Общие традиции в эпосе и семантике обряда Сорэн у татар (на примере татарских обрядовых песенных текстов, записанных на фольклорных экспедициях) // Вестник Северо-Восточного федерального университета имени М.К. Аммосова. Серия «Эпосоведение». 2021. № 4 (24). С. 5–14.

*Надиров И.Н.* Татар халкының йола поэзиясе, уен җырлары, бию такмаклары // Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары / төз. И.Н. Надиров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 329 б.

Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары / томны төз., кереш мәкалә язучы, иск. әзерләүче И.Н. Надиров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 329 б.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел,*
*әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге*
*баш фәнни хезмәткәре*

УДК 392.15

***Р.Ә. Яруллина-Йылдырым***

# ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ХАЛЫКЛАРЫНДА СӨННӘТ ЙОЛАСЫ

В процессе формирования национального характера личности наряду с образом жизни и мышления, культурными ценностями, религиозными воззрениями, языком и географическими особенностями важную роль играют и традиции народа, представителем которого является эта личность. Смена поколений, социальные, политические и экономические изменения в стране, совместное проживание с другими этническими группами приводит к изменению национальных особенностей: к их видоизменению или же наоборот, к их исчезновению. Одна из таких культурных ценностей, вынужденных претерпеть изменения под воздействием общественных факторов, – обряд обрезания, являющийся общим для всех мусульманских народов.

В статье затрагиваются отдельные и общие элементы, касающиеся вышеуказанного обряда у татар в исторической ретроспективе, в силу разных причин проживающих в разных регионах и у турков Восточной части Анатолии, среди которых данный обряд и поныне является неотъемлемой частью их культуры. Обряд обрезания, укоренившийся в среде турков восточной и юго-восточной части Турции, рассматривается в тесном единстве с традицией «кирве». Также дается пояснение о требованиях при выборе кирве, экономические и социальные обязанности данной личности.

**Ключевые слова:** культурные ценности, тюркские народы, обряд обрезания, кирве.

In the process of forming the national character of a person, along with the way of life and thinking, cultural values, religious beliefs, language and geographical features, the traditions of the people, of which this person is a representative, also play an important role. Change of generations, social, political and economic changes in the country, living together with other ethnic groups leads to a change in national characteristics: to their modification or vice versa to their disappearance. One of these cultural values forced to undergo changes under the influence of social factors is the rite of circumcision which is common to all Muslim peoples.

The article touches upon individual and general elements relating to this rite among the Tatars in a historical retrospective for various reasons living in different regions and among the Turks of the Eastern part of Anatolia, among whom this rite is still an integral part of their culture. The rite of circumcision rooted among the Turks of the eastern and southeastern parts of Turkey is considered in close unity with the kirve tradition. An explanation is also given about the requirements for choosing a kirve, the economic and social responsibilities of a given person.

**Keywords:** Cultural values, Turkic peoples, circumcision rite, kirve.

Шәхеснең милли характеры формалашуда шул милләткә хас тормыш һәм фикерләү рәвеше, дин, тел, яшәү урыны кебек факторлар белән бергә, гореф-гадәт һәм йолаларның да әһәмияте зур.

Ил күләмендә барган социаль, сәяси һәм икътисади үзгәрешләр, башка этник төркемнәр белән аралашып яшәү милли сыйфатларның төрләнүенә, баюына, яки киресенчә, юкка чыгуына китерә. Тарихи ватаныннан читтә, бигрәк тә чит регионнарда һәм илләрдә яшәгән халык, үз милләтенең төп үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, башка милләтләргә хас сыйфатларның йогынтысын да кичерә. Җәмгыять, шушы җәмгыятьтә формалашкан шәхес һәм шәхеснең яшәү фәлсәфәсен билгеләүче рухи кыйммәтләрнең тормышта бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән төшенчәләр булуын беләбез. Бу төшенчәләрнең берсе зыян күрсә, башкалары да аның йогынтысы тоя.

Мәгълүм булганча, сөннәт – ир баланың җенес әгъзасы очын каплап торган тирене кисеп алу йоласы ул. Мөселманнар арасында ир баланы сөннәткә утырту йоласының башланып китүе Ибраһим пәйгамбәр исеме белән бәйләп карала. Дини риваятьләрдән күренгәнчә, «Һәм Ибраһим улы Исмәгыйльне һәм өендә дөньяга килгәннәрнең барысын, һәм акчасы белән сатып алганнарның барысын, өендәге кешеләр арасыннан һәр ир кешене алды һәм, Алланың үзенә сөйләгәнчә, бер үк көнне сөннәткә утыртты. Ибраһим сөннәт булган вакытта туксан тугыз яшендә иде һәм улы Исмәгыйль унөч яшендә иде һәм бөтенесе берлектә сөннәт булдылар» (Теквин Бар 17/22–27) [Işık, 2000, s. 32]. Кайбер риваятьләрдә Ибраһим пәйгамбәрнең сиксән яшендә Шам районындагы Каддум авылында үз-үзен сөннәт итүе бәян ителә. 120 яки 70 яшьләрендә сөннәт булуы хакындагы риваятьләр дә мәгълүм [Koksal, 1991, s. 499]. Ибраһим пәйгамбәр вакытыннан килә торган бу йоланы, ислам дине тарала башлаганнан соң, Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның тарафдарлары да дәвам итә. Хәдисләрдән тумыштан сөннәтле булган Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныклары Хәсән һәм Хөсәенне сөннәткә утыртканлыгы мәгълүм. Пәйгамбәр бу турыда болай дип язган: «Биш нәрсә фытрат (яратылыш) кирәгедер: сөннәтле булу, култык асты кылларын чистарту, касыкларны кыру, тырнак кисү һәм бер дә мыек очларын төзәтү» (Нәсәли 1/32–33) [Işık, 2000, s. 32].

Мөхәммәд пәйгамбәр дөньяга килгәнче, сөннәт йоласы яһүдиләр арасында таралган була. Яһүдиләрдә сөннәткә утырту хахамлар тарафыннан башкарыла. Авыртуны сизмәсен өчен, бу йола бала дөньяга килү белән, төгәлрәге, сигезенче көндә аерым бер ритуал рәвешендә үткәрелә.

Мәгълүмат өчен шуны да искәртү зарур: «Сөннәткә утырту гадәте мөселманнар һәм яһүдиләр арасында гына түгел, Австралия, Полинезия утрауларында, Африка, Америкада (Мексика) һ.б. төбәк халыкларында да таралган. Мондый йола борынгы Мисырда да билгеле булган. Эфиопларга бу йола мисырлылардан кергән, яһүдиләр аны мисырлылардан алганнар» [Миллият сүзлеге, 2007, б. 418]).

Мөселманнарда ир баланы сөннәткә утыртуның катгый билгеләнгән көне дә, баланың яшь чиге дә юк. Шулай да Әхмәтһади Максудиның «Шәригать хөкемнәре»ндә «Ир баланы унынчы яшенә

кадәр сөннәткә утырту»ның [Максуди, 2010, б. 73] сөннәт гамәлләре исәбенә кертелгәнлеге искәртелә. Күпчелек халыкларда ир баланың тууыннан алып балигъ булганчыга кадәрге арада сөннәт ясау гадәт булып килгән. Малайларны 4 тән 7 яшькәчә, кайбер төбәкләрдә так яшьләрдә (3, 5, 7 һ.б.) сөннәткә утырту хуп күрелә. Бала үз-үзен аңлый башлаган яшьтә сөннәт ритуалын башкару мантыйкка сыешлы. Чөнки сөннәткә әзерләнгән ир бала психологик яктан бу йоланы кабул итәргә, үзенең ирләр женесеннән икәнлеген, сөннәтле булуын аңларга тиеш. Ир бала булуның үзенә күрә бер горурлык, көч һәм җаваплылык икәнлеген белү дә аңарда кешелек сыйфатлары формалашуга уңай йогынты ясый. Икенче яктан, сөннәткә әзерләгән бала мөселманлыкны аңлый, ислам диненең кануннары белән таныша, дини йола һәм тәрбия аша тәрбияләнә башлый. Гарәпләрдә «хытан» дип аталган бу йола, төрки халыкларда сөннәт исеме белән йөртелә. Бу, үз чиратында, төркиләрнең Мөхәммәд пәйгамбәр сөннәтенә никадәр бәйле икәнен һәм хөрмәт белән каравын күрсәтә [Işık, 2000, s. 32]. Сөннәт йоласының тагын бер функциясе: ир бала шушы ритуалны узу белән балигълык ягына чыга. Бу ритуал, шартлы рәвештә генә булса да, балачак белән балигълык арасындагы чик булып тора.

Совет елларындагы тыюларга карамастан, төрле төбәкләргә сибелеп яшәгән татар халкы (бигрәк тә авылларда) исламдагы ир баланы сөннәткә утырту йоласын үтәргә тырышкан. Элегрәк кайбер татар авыллары үз сөннәтчеләре белән билгеле булган. Мәсәлән, Арча районындагы Масра авылы үзенең сөннәтче бабалары белән телгә алынган [Zaripova Çetin, 2009, s. 83]. Татарстанның Кайбыч районында сөннәт йоласының ничек башкарылуын Фәридә Яруллина[1] бәян итте. Белгәнебезчә, һәр авылда ук булмаса да, һәр төбәктә бу гамәлне оста башкаручы сөннәтче бабай булган. Сөннәткә утырту йоласы гадәттә һавалар суына төшкәч, көз һәм кыш айларында башкарылган. Күрше авылдан сөннәтче бабайны ат белән алып килгәннәр һәм ул берничә гаиләдәге малайларны сөннәткә утырткан. Ир баланы ата кеше кочагына алган, курыкмасын өчен, баланы төрлечә юмалаганнар, матур вәгъдәләр биргәннәр. Мәсәлән, Кайбыч якларында халык арасында *бабачы* дип йөртелгән сөннәтче бабай: «Сиңа матур чалбар тегәбез, әйдә буен үлчик әле», – дип, кулы белән буй үлчәгән кебек хәрәкәтләр ясаган һәм, «Бисмилласын» укып, тиз арада төп эшен дә башкарган. Бабачыга эше өчен рәхмәт белдереп бирелә торган махсус бүләкләр дә булган. Мәсәлән, сөннәткә утыртылган ир баланың буе озынлыгында сөлге һәм түгәрәк икмәк биргәннәр. Күрше-күлән һәм туганнар сөннәт ителгән малайны котлап уенчыклар, бүләкләр китергән. Бүләкләр балага авыртуын онытырга ярдәм иткән. Матди хәле яхшы гаиләләр Коръән мәҗлесе уздырган. Гомумән алганда, бу якларда сөннәт һәм сөннәт мәҗлесе матур бер бәйрәм рухында башкарылган.

---

[1] Яруллина Фәридә, 80 яшендә. Кайбыч районы Кече Кайбыч авылы.

Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез арасында сөннәт йоласының ничек башкарылуы турында мәгълүмат алу өчен, галимә Флера Баязитованың хезмәтләренә мөрәҗәгать иттек. Мәсәлән, Идел-Урал төбәгендә яшәүче татарларда сөннәтче бабайны *баба карт* дип йөрткәннәр. Сөннәткә утыртканда ул балага «куян ат бирәм» дип, аның игътибарын башкага юнәлтә икән. «Баба карт касан китерә куйан ат?» – «Син терелгәс, син йөри башлагас», – тиләр балага [Баязитова, 2002(б), б. 204]. Бу якларда да элек баба картка түгәрәк икмәк һәм, гаиләнең мөмкинлегеннән чыгып, хәер биргәннәр.

Татарлар яшәгән күпчелек төбәкләрдә, яра төзәлсен өчен, аңа агач череге сипкәннәр. Сөннәтче бабайлар алдан ук юкә агачы черeген иләп әзерләп куя торган булганнар. Ата-ана шул черекне яра төзәлгәнче сибеп торган. Юкә агачының он рәвешендәге череге халыкта көчле антисептик саналган, аның башка яраларны төзәтү өчен дә кулланылганлыгы мәгълүм.

Әстерхан татарларларында ир баланың игътибарын башка нәрсәгә юнәлтү өчен, «ау-ау» дип кычкырып, ишек кага торган булганнар. Сөннәт ясалган бала өчен дип, туган-тумача тиредән тегелгән капчыкка акча салган, бала шуңа карап, елавын онытып торган [Баязитова, 2002а: 158]. Электән Әстерхан татарларында, баланың сөннәткә утыртылуы хөрмәтенә, сөннәт туйлары да уздырылган. Сөннәтләгәнче балага матур киемнәр кидереп, халык алдында биеткәннәр, акча чәчкәннәр. Матди хәле яхшы булган гаиләләр үгез һәм ат суеп, сөннәт туе уздырган. Кайбер төбәкләрдә баланы сөннәткә бирү алдыннан, көрәшчеләр чакырылып, ярыш оештырылган. Җиңүчегә куй яки сыер бирелгән. Соңыннан ул бүләкләр көрәштә җиңгән якның мулласына тапшырылган [Баязитова, 2002(а), б. 157]. Сөннәт ителәчәк бала ленталар белән бизәлгән ат арбасына утыртылган, җыр-музыка белән халык урам әйләнгән [Баязитова, 2002(а), б. 157].

Себер татарларында бу йоланы башкаручыларны *аптал*, *абтал,* кайбер җирләрдә *сөннәт салучы бабай* дип атаганнар. Халык апталларга кадер-хөрмәт күрсәткән, йомшак урынга, мендәргә утырткан. Аларның җиңел куллы һәм укымышлы булуына ышанган. Флера Баязитова бу хакта түбәндәгечә яза: «Себер диалектларында апталның – сөннәтче картның борынгы шаманнар кебек, барабан сугып, тавыш чыгарып торуы турында мәгълүматлар сакланган» [Баязитова, 2009: 212]. Төмән өлкәсендәге авылларда апталларның исә имән агачтан ясалган һәм *тип, төмбер күнәк* дип йөртелгән барабан шәкелендәге әйберне үзләре белән йөртүе мәгълүм.

Ф.Баязитова ата-ананың гаиләдәге ир баланы сөннәткә утырту хөрмәтенә *сөннәт катымы*, *сөннәт туе* исемле мәҗлесләр уздыруы турында да киң мәгълүмат бирә. Мәҗлестә Коръән укытылган, теләкләр теләнгән, тәмле ризыклардан аш табыны хәзерләнгән. Мәҗлескә килүчеләр сөннәткә утыртылган баланың муенына асылган янчыкка акча салган. Себернең кайбер төбәкләрендә сөннәт туенда, Әстерхан татарларындагы кебек, төрле уеннар, көрәш һәм ат

чабышлары оештырылган. Атлар төсле тасмалар белән махсус бизәлгән, тәңкәләр тагылган. Ярышта катнашучыларга бүләкләр өләшенгән. Сарык, тәкә суелган. Борынгыдан килгән бу туйга авыл картлары чакырылган. Гомумән, чит регионнарда да сөннәт йоласы һәм сөннәт туйлары, бер яктан, динебез сөннәтен дәвам итү, дини гадәтләргә хөрмәт күрсәтү булса, икенче яктан, халык арасында теләктәшлек, ярдәмләшү, күңел ачу, милли традицияләребезне саклау чарасы булып торган.

Матур традицияләр һәм гореф-гадәтләрне саклап, аларны нәселдән нәселгә күчерә баручы авылларның бетүе, заман сулышы тәэсирендә төрекләрдә дә, татарлардагы кебек, сөннәт йоласы үзгәреш кичерә. Электән сөннәтчеләр тарафыннан өйдә үтәлгән йола хәзер, бигрәк тә шәһәр җирләрендә, хастаналәрдә башкарыла. Сөннәт туен уздыру да гаиләнең теләгенә, матди хәленә һәм туган-тумача белән мөнәсәбәтләренә бәйле. Шулай да Төркиянең элекке традицияләрне саклаган, дини йолалар белән бәйләнешен бөтенләй үк өзеп бетермәгән көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш районнарында сөннәт һәм кирвәлек йолалары бер-берсенә тыгыз бәйләнештә яшәп килә. Бу якларда сөннәт иткән кешедән бигрәк баланың кирвәсе кем булу әһәмиятле. Кем соң ул кирвә? Төрек халкында «Сөннәт ителгән баланың кулын яки аягын тотып торган һәм бала өстендә ата хакы булган кеше»не *кирвә* дип атыйлар (фарсы телендәге «киров» сүзеннән алынган) [Türkçe Sözlük, 1998, s. 877]. Бу йола Төркиянең көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш районнарында аеруча киң таралган. Бигрәк тә аләвит мәзһәбендә булган төрек һәм көрдләрдә кирвәгә җитди әһәмият бирелә. Чөнки бер риваятьтә язылганча, Мөхәммәд с.г.в. оныклары – Али пәйгамбәрнең уллары Хәсән һәм Хөсәеннең кирвәсе булган (www.seyyidali, s. 1). Кирвәлек традициясе сөнниләр арасында да очрый. Көнчыгыш районның төрле җирлекләрендә бу сүзнең башка мәгънәләре дә бар. Кайбер җирләрдә кирвәлек – «туганлык», икенчеләрендә «күршелек», «кешелек бурычы», «якынлык» кебек мәгънәләрне аңлата [Koksal, 1991, s. 500].

Кирвәлекнең үзенә хас җаваплылыклары да бар. Кирвә итеп билгеләнгән кеше сөннәт эшләткән гаиләгә бу эш өчен тотылган чыгымнарны капларга, сөннәт туен уздыруда, матди ярдәм күрсәтеп, үз өлешен кертергә тиеш. Кайбер җирлекләрдә (аеруча аләвитләрдә) сөннәткә утыртылган ир бала үсеп җиткәч, үз кирвәсенең кызына өйләнә алмый. Чөнки сөннәт ясаган вакытта кирвәгә тамган кан бу ике гаиләнең каны кушылу мәгънәсендә кабул ителә.

Сөннәт һәм кирвәлек йоласының һәр җирдә үзенә генә хас үзенчәлекләре билгеле. Мәсәлән, информант Әбүбәкир Айтекин[1] аңлатканча, Адыяман районының кайбер авылларында мәртәбәле кирвә сөннәт булачак йортка килгәндә, үзе белән берничә дустын ала, сыер, бозау кебек йорт хайваннарын бүләккә китерә. Бу, бер яктан, кирвә ке-

---

[1] Айтекин Әбүбәкир, 70 яшендә, пенсиядәге укытучы. Адыяман шәһәре.

шенең матди хәлен, кирәк булса, сөннәтләнүчегә ярдәм итә алырлык мөмкинлеген күрсәтсә, икенче яктан, сөннәт булачак гаиләгә һәм вазифасына булган хөрмәтен раслый. Ләкин гадәттә сөннәт эшләтәчәк йорт кешеләре, рәхмәт әйтеп, бу бүләкләрне кире җибәрә. Ир баланың ата-анасы кирвәгә, нигездә, кием-салым бүләк итә.

Төрекләрдә сөннәт эшләнәчәк һәм бала ятачак бүлмә махсус әзерләнә: ятакка гадәттә ана кешенең кул эше саналган җәймә җәелә, стеналарга бизәкләр, төсле шарлар эленә. Тәмле исле хушбуйлар сибелә. Якын кешеләр чакырыла, табын әзерләнә. Сөннәт вакытында еламасын дип, әлеге гамәл башкарылган вакытта ир балага зур локум каптыралар.

Сөннәт туенда Коръәннән аятьләр, касыйдә укыла. Гадәттә корбан чалалар һәм итле, ногытлы пылау пешерәләр. Төркиянең көньяк-көнчыгыш җирлегендә Корбан итенең чалган өлеше иң хөрмәтле кешегә – кирвәгә бирелә. Давыл, зорна кебек милли музыка уен коралларында уйнала, җирле биюләр башкарыла. Озын гомерле булсын дип, ир баланың кулына кына ягу ритуалы уздырыла (Шуны да өстәп әйтергә кирәк: кулга кына ягу – кияүгә чыгучы кызлар һәм солдатка китүче егетләр өчен дә иң әһәмиятле йолаларның берсе). Сөннәтле балага алтын тәңкә тагу да төрекләр арасында киң таралган.

Сөннәт ритуалы тәмамланганнан соң да, бу гаилә өчен кирвә иң хөрмәтле һәм дәрәҗәле кеше булып кала. Әбүбәкир Айтекин әйтүенчә, бер балага кирвә булган кеше ике гаиләне, берничә нәселне бер-берсенә якынайта, туганлык мөнәсәбәтләре урнаштыра. Гаиләдә булган барлык мөһим вакыйгаларда, мәҗлесләрдә, мәсәлән, ир бала солдат хезмәтенә киткәндә, өйләнгәндә яки бәби чәендә кирвә түргә утыртыла. Гомумән алганда, төрекләрдә сөннәт, сөннәт туе һәм кирвәлек – гаиләләрне бер беренә якынлаштырган, матди хәле авыр булганнарга ярдәмләшү юлын ачкан һәм мондый традицияләрнең сакланып калуын тәэмин иткән йолаларның берсе.

Йомгак ясап әйткәндә, күпмедер дәрәҗәдә үзгәреш кичерсә дә, сөннәткә утырту хәзерге вакытта да үтәлә торган йолалар рәтендә. Татар халкында ул, бер яктан, дини йола буларак уздырылса, икенче яктан, чисталык саклауга юнәлтелгән һәм табиблар тарафыннан да файдалы дип табылган гамәл буларак популярлаша бара. Төрекләрдә исә сөннәт йоласы туганлык мөнәсәбәтләрен ныгыту ягыннан да әһәмияткә ия.

**Әдәбият**

*Işık E.* İslamiyet'te Sünnet Geleneği // Altınoluk dergisi. 2000. Ağustos. Sayı: 174. S. 32.

Kirvelik – Seyyidali www.seyyidali.com/index

*Koksal H. (1991)* Güneydoğu İllerimizde Kirvelik Geleneği, www. turkoloji. cu.edu.tr

Türkçe Sözlük. Ankara: TDK, 1988. Cilt 2. S. 1679.

*Zaripova Çetin, Ç.* Tatar Türklerinin Gelenek Görenekleri. Ankara: Karadeniz dergisi yayınları, 2009. 160 s.

*Баязитова Ф.С.* Әстерхан татарлары: Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. Казан: Фикер, 2002(а). 300 б.

*Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы (Йола һәм мифология текстлары яссылыгында). Казан, 2009. 736 б.

*Баязитова Ф.С.* Урта Урал (Свердловск өлкәсе) татарлары: Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. Казан: Фикер, 2002(б). 416 б.

*Максуди Ә.* Шәригать хөкемнәре. Казан: Раннур, 2010. 111 б.

Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек / төз.-авт. А. Тимергалин. Казан: Мәгариф, 2007. 575 б.

***Яруллина-Йылдырым Рамилә Әсхәдулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, профессор,*
*Иненю университеты Төрек теле һәм әдәбияты бүлеме*
*чордаш төрки халыклар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире (Төркия)*

УДК 392.11

***И.Г. Закирова***

# ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫНДА КЕНДЕК ӘБИЛӘРЕ ОБРАЗЫ
## (Истәлекләр һәм сөйләкләр мисалында)

В фольклоре татарского народа, проживающего в разных регионах России, описываются врачебные навыки, мастерство повивальных бабок. Долгое время эта деликатная тема оставалась вне поля зрения фольклористов. В иследовании использован материал, собранный автором во время фольклорных экспедиций по районам Республики Татарстан, в Омскую, Томскую, Тюменскую, Иркутскую области РФ. Также для раскрытия данной темы были использованы материалы диалектолога Ф.С. Баязитовой. Бабушки-повитухи с осторожностью и трепетом помогали появиться на свет младенцам, с первой минуты их жизни давали понять, как они дороги и долгожданны. И на сегодняшний день эта тема является актуальной, так как сохраняет опыт, мастерство, деятельность бабушек-повитух в воспитании духовности подрастающего поколения.

**Ключевые слова:** семейные обряды, повивальные бабки, детский фольклор, новорожденный, заклинания, запреты.

The folklore of the Tatar people living in different regions of Russia describes medical skills, the skill of midwives. For a long time this delicate topic remained out of the field of view of folklorists. In this study was used material collected by the author during folklore expeditions to the regions of the Republic of Tatarstan, to the Omsk, Tomsk, Tyumen, Irkutsk regions of the Russian Federation. Also materials of the dialectologist F.S. Bayazitova were used to disclose this topic. Midwives with care and trepidation helped babies to be born, from their first minute of life they made it clear how dear and long-awaited they are. And today this topic is relevant, as it preserves the experience, skills, and activities of midwives in educating the spirituality of the younger generation.

**Keywords:** Family rituals, midwives, children's folklore, newborn, spells, prohibitions.

Татар халкының әниләр һәм әбиләр белән бер дәрәҗәдә хөрмәткә лаек, бөтен кеше тарафыннан олылана, хөрмәтләнә торган кендек әбиләре турында белүчеләр хәзерге вакытта азая бара. Шактый четрекле тема булганга, бу мәсьәлә озак вакытлар фольклорчылар игътибарыннан да читтә калып килгән. Без бу мәкаләдә татар халкының кендек әбиләре образын диалектолог Флера Баязитова хезмәтләренә таянып һәм үзебез экспедицияләр вакытында язып алган материаллар ярдәмендә ачарга омтылдык. Ф.С. Баязитова, һәр елны татарлар яшәгән төбәкләргә оештырылган күпсанлы экспедицияләрдә катнашып, татар халкының рухи тормышын төрле яклап чагылдырган бай материал туплый. Галимәнең җыелган материалны тематик һәм локаль үзенчәлекләр белән бәйләнештә системага салган күпсанлы хезмәтләре тел белгечләре өчен генә түгел, фольклорчылар өчен дә кыйммәтле чыганак булып тора.

Гасырлар дәвамында аналарга бала тудыру вакытында ярдәм күрсәтүче, бала кабул итүче кендек әбиләр булган. Алар, кагыйдә буларак, өлкән яшьтә булып, бу һөнәр буыннан-буынга, анадан кызга күчкән.

Татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә кендек әбиләрне төрлечә атыйлар: кендек әби, мамай, кендекче, инәкә мама, инәкә әби, кендек мама, бахсы, кендегәч карчык, корткааяк, кентекләгән мамай, аппай корткаяк, инәкә, инәлек колака, колагинә һ.б.

Хәзерге көнгә кадәр халыкта кендек әбиләр турында истәлекләр саклана, бала тапкан хатыннар аларны яхшы сүз белән искә ала. Тәҗрибәле кендек әбиләр баланы бик җиңел таптырган, катлаулы очракларда, бала дөрес килмәгәндә дә, алар ананың да гомерен саклап, баланы да имгәтмичә тудырырга ярдәм итә белгәннәр. Татар халкында баланы кендек әбиләр ярдәмендә тудыру күренеше XX гасырның урталарына кадәр дәвам итә. 1960 елларда, кендек әбиләрнең эшчәнлеген тыю нәтиҗәсе буларак, бу күренеш юкка чыга.

Татар фольклорында һәм әдәбиятта кендек әбиләр турында мәгълүмат бик күп. Төрле төбәкләрдә яшәгән татарларның риваять-легендаларында кендек әбиләрнең үз эшләрен яхшы белүләре, табиблык осталыгына ия булулары бәян ителә.

Хәзергә кадәр татар халкының иң популяр риваятьләрендә кендек әбиләрнең җен яки пәри хатынына бала табарга ярдәм итүе турында сүз бара. Шундый риваятьләрнең күпсанлы вариантлары Себер татарлары арасында сакланган. Беренче вариант Төмән өлкәсе Вагай районының Казанка авылында яшәүче Шәрәфетдинова Алия Әйтмөхәммәт кызыннан язып алынды. Информант бу вакыйганы чынбарлыкта үзенең әбисе Мәймүнә белән бәйле вакыйга буларак бәян итә. Риваятьнең кыскача эчтәлеге болай: Мәймүнә тумышы белән Уфадан була. Ул заманының укымышлы хатыннарыннан саналып, бөтен тирә-якта инәлек итә. Бервакыт аны пәринең ире килеп ала. Инәлек беркемгә дә ярдәм итүдән баш тарта алмый. Барырга тиеш була. Бала тугач, баланы юындырырга су булмый, инәлеккә сөт бирәләр. Инәлек сөт савытының үзенеке булуын таный, сөткә йөзеген сала. Пәринең ире инәлекне кире өенә илтеп куя. Инәлек өендә сөт эченнән йөзеген ала. Шул баруында инәлек пәри хатынының йонын йолкып кайта. Бу йонны такыясына (баш киеменә) тегеп куя. Шул вакыттан ул инәлек булган бер хатын да, бер бала да үлми. Мәймүнә бөтен авыруларны да дәвалый башлый.

Бу риваятьтән күренгәнчә, инәлекләрнең осталыгы гади тәҗрибә белән генә аңлатылмый, халык инәлекләрнең сихри көчкә ия булуына да ышана. Бу очракта аның көче инәлекнең пәриләр, ягъни башка дөнья вәкилләре белән бәйләнеше аша килә. Пәринең йоны, ягъни икенче дөньяга караган предмет хатынга сихри көч бирә. Кендек әбиләрне икенче дөнья белән бәйләнештә карау очраклы түгел. Кендек әби үзенең функциясе белән дә ике дөнья арасында арадашчы ролен үти, балага алар арасындагы чикне үтәргә ярдәм итә.

Бу риваятьнең функциясе, бер яктан, кендек әбинең осталыгын мактау, аның гадәти булмаган көчен бәян итү булса, икенче яктан, ул татар халкының тагын бер инануы белән бәйле. Татар халкында, бер генә ризыкны да, суны да, сөтне дә өстен япмыйча калдырырга ярамый, дигән ышану бар. Өсте ачык калган ризыкны пәри ялый, мунчада суның өсте ябылмыйча калса, җеннәр юына, сөт өсте ачык калса, пәри баласын юа дигән ышанулар, бердән, чисталыкка-пөхтәлеккә өнди, икенчедән, төрле стихияләр арасындагы чикләрне билгели. Ят дөньяларны һәм аларның вәкилләрен хөрмәт итәргә, үз дөньяңны сакларга өйрәтә. Шул рәвешле авырулардан саклану чараларына күрсәтә.

Әсәрнең икенче варианты да шушы ук авылда язып алынды. Бу очракта кендек әбинең, баланы юындырганда, күрше хатынының сөт савытын тануы һәм үзенең йөзеген салуы тасвирлана.

Шушы ук риваятьнең тагын ике варианты Татарстанның Балтач һәм Кама Тамагы районнарында язып алынды. Балтач районы информанты Фәсыйхов Наил Шамил улы да вакыйганы үзенең әбисенең әбисе Сәйфетдин Фатыймасы белән булган хәл буларак бәян итә. Мәгълүм эчтәлек бу юлы да кабатлана. Ул иртә белән төнлә үзен җен хатынына кендек әбисе булырга алып китүләрен, баланы сөт белән юуын сөйли. Чынлап та, бер хатынның өсте ябылмаган чиләгендә сөт канлы була. Кама Тамагы районында язып алынган вариантны да информант Хәбибуллина Нәсимә үзе белгән кешеләр белән булган вакыйга буларак бәян итә.

2015 елда Томск өлкәсендә узган экспедиция вакытында бу риваятьләрнең тагын берничә варианты белән очраштык. Аларда кендек әбине чәй өстәленә чакырулары, чанага утыртып алып китүләре кебек детальләр өстәлә.

Әсәрнең төрле регионнарда популяр булуы аның барлык кендек әбиләргә карата да сөйләнүенә ишарәли булса кирәк. Алар кендек әбиләрнең профессиональ осталыкларын күрсәткән, бала табучы хатыннарның аларга ышануы бала табучыны да, кендек әбиләрне дә психологик яктан әзерләгән, бу үз чиратында ананың да, баланың да исәнлеген-иминлеген тәэмин иткән.

Кендек әбиләр бәби туачак өйгә кергәндә, бала туган вакытта, баланы биләгәндә әйтә торган тотрыклы шигъри текстлар, сүзләр булган, күптөрле йолалар башкарылган. Бу йола һәм текстларны башкаруның максаты – ананың баладан исән-сау, җиңел котылуын теләү, баланың таза-сау, бәхетле булып тууын тәэмин итәргә омтылу, ана белән баланы кара көчләрдән, сихердән саклау.

Кендек әбиләрнең бала туасы йортка кергән вакыттан бөтен гамәлләре аерым ышанулар, йолалар, тыюлар кысаларында бара. Кендек әби ишектән кергәндә үк төрле такмаклар, сүзләр әйтеп, аерым бер ырымнар башкарып, күлмәк итәкләрен җилпеп кергән:

Бисмилли, бисмилла,
Җен булмасын,

Җиңеллек булсын,
Озын гомерле булсын [Баязитова, б. 183].

Инәлекләр итәкләрен җилпеп, җен-пәриләрне куып, бусагадан кергәндә:

Шайтаннар ияреп кермәсен,
Шайтаннар-майтаннар кермәсен,
Җен-мазар кермәсен, –

дип бисмилла әйтеп атлап кергәннәр [Баязитова, б. 184].

Кайбер кендек әбиләр бусагадан шырпы сызып, ут яндырып атлаганнар, утны, «җен үтмәсен» дип, үзләренең аяк арасыннан да уздырганнар. Бала табучы хатын янына шул рәвешле ут белән чистарынып кергәннәр.

Бу – татар халкының яңа туган баланы җен алыштыра дигән ышануы белән бәйле. Татарлар баланы кырык көнгә кадәр ялгыз калдырмыйлар. Татар халык иҗатында җен алыштырган балалар турында әкиятләр, легендалар да бар.

Бала озак тумый торса, кендек әбиләр төрле ырымнар башкарган. Мәсәлән, ишекне ачып:

Кысылдым, кысылдым,
Алла, бушат, кысылдым, –

дип кычкыра булган [Баязитова, б. 181]. Фольклорда кендек әбиләрнең ана карынындагы туачак бала белән сөйләшүе тасвирлана. «Ак Күбек» дастанында кендек әбиләр – инәлекләр туарга теләмәгән баланы дөрес туарга үгетлиләр. Алар тиешенчә дөньяга килергә теләмәгән Ак Күбеккә, дөрес туган очракта, алтын-көмеш бишекләр вәгъдә итәләр:

Алтын бишеккә бер салып
Биләр идек Көбәйне,
Көмеш бишеккә бер салып
Биләр идек Көбәйне [Радлов, с. 45].

Дастанның икенче вариантында Ак Күбек үзе инәлекләргә мөрәҗәгать итә:

Ары ултырың, инәлекләр,
Бире ултырың, инәлекләр! [Радлов, с. 143].

Бу мотив та күпмедер дәрәҗәдә чынбарлыкны чагылдыра. Кендек әбиләр туачак бала белән сөйләшкәннәр, тәмле тел белән аны туарга үгетләгәннәр.

Кендек әбиләр яңа туган балага беренче булып бәхет-тәүфыйк теләгәннәр. Тәмле телле булсын, ризыклы-бәхетле булсын өчен аңа бал белән май каптырганнар. Һәрбер йола шигъри текстлар ярдәмендә ныгытылган. Бу йола һәм текстларны башкаруның максаты ананың исән-сау, баладан җиңел котылуын теләү, сабыйның таза, бәхетле булып тууын тәэмин итәргә омтылу, ана белән баланы кара көчләрдән,

сихердән саклау була. Ир бала туса, аны – атасының, кыз бала туса, анасының күлмәгенә төргәннәр. Бу да ата-ана белән бала арасын якынайту өчен эшләнгән.

Баланы юындыру өчен 40 көн дәвамында мунча ягылган һәм кендек әби көн дә баланы юындырырга килгән. Шул ук вакытта баланың баш формасында, кул-аякларында, аркасында җитешсезлекләр булганда, кендек әби массаж һәм мунча ярдәмендә аларны да дәвалаган.

Татар халкында һәркем үзенең кендек әбисен белгән. Хәрби хезмәткә китүче егетләр кендек әбиләре белән саубуллашырга кергән. Кайткач, хәл белү дә мәҗбүри булган. Кендек әбигә бәйрәмнәрдә күчтәнәчләр китергәннәр. Ул һәрбер өйдә кадерле кунак саналган.

Йомгак ясап әйткәндә, кендек әбиләр образы хәзерге вакытта онытылып бара, аларның эшчәнлеген өйрәнү бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмый.

**Әдәбият**

*Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы. Казан, 2010.

*Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной сибири и Дзунгарской степи. Ч. IV. СПб., 1872.

Риваять һәм легендалар авторның Россиянең татарлар компактлы яшәгән төбәкләренә экспедицияләр вакытында язып алынган материалларыннан алынды.

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 37.01

*Л.Ш. Дәүләтшина*

# ХХ ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ҖӘМГЫЯТЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗ МӘГАРИФЕ МӘСЬӘЛӘСЕ

Статья посвящена истории татарского женского образования. Татарское либеральное общество начала ХХ в., достаточно разнородное, но удивительно солидарное в вопросах женского образования, называло разные цели обучения девочек. Цели зависели от времени их формулировки, то есть от развития общества в целом и состояния женских школ в частности. Мы проследили материалы татарской периодики с 1906 до 1917 гг., рассмотрели дидактические материалы, отражающие точку зрения религиозного деятеля Р. Фахреддина, и смогли выделить три основные цели обучения девочек, активно обсуждавшиеся в татарском обществе в начале ХХ в.
**Ключевые слова:** женское образование, цели обучения девочек, татарское общество начала ХХ в., татарские женские школы.

The article is devoted to the history of Tatar women's education. The Tatar liberal society of the beginning of the 20th century, quite heterogeneous, but surprisingly solidary in matters of women's education, declared different goals for girls' education. The goals depended on the time of their formulation, that is on the development of society in general and the state of women's schools in particular. We traced the materials of Tatar periodicals from 1906 to 1917, examined didactic materials reflecting the point of view of the religious figure R. Fakhretdin and were able to identify three main goals of girls' education that were actively discussed in Tatar society at the beginning of the 20th century.
**Keywords:** women's education, girls' education goals, Tatar society in the early 20th century, Tatar women's schools.

XIX гасыр ахыры – ХХ гасыр башында, бүгенге татар милләте формалашкан дәвердә, «хатын-кыз мәсьәләсе» милли мәсьәлә белән тыгыз үрелеп бара. Зыялылар, алдынгы карашлы буржуазия вәкилләре арасында татар хатын-кызларының җәмгыятьтәге роле турында яңача күзаллау барлыкка килә. Аның тарафдарлары татар милләте «милләтнең лаеклы аналары»н тәрбияләмичә алга бара алмый дип саныйлар. Әмма «милләт анасы» булу өчен татар хатын-кызлары коллык хәленнән чыгарга, нинди дә булса гражданлык хокуклары алырга тиеш.

1905–1907 еллар революциясе хатын-кыз хокуклары мәсьәләсен тагын да кискенләштерә. Бер яктан, татар милләте алдына алгарыш зарурияте куйган таләпләр артса, икенче яктан, татар вакытлы матбугаты барлыкка килү кичектергесез мәсьәләләр турында сөйләшү мәйданын киңәйтә. Хәтта хатын-кызлар үзләре дә бәхәскә кушылалар.

Бу мәкаләдә без ХХ гасыр башы татар җәмгыятендә «хатын-кыз мәсьәләсе»нең бер өлеше булган хатын-кыз мәгарифе турындагы

фикерләргә тукталырбыз. «Хатын-кызга уку нигә кирәк?» Бу сорауга XX гасыр башы татар җәмгыяте вәкилләре нинди җаваплар биргәннәр?

Татар җәмгыяте дигәндә, без иң элек алдынгы карашлы дин әһелләрен, зыялыларны һәм либераль буржуазия вәкилләрен күз алдында тотабыз. Чыганакларыбыз – дидактик әдәбият һәм вакытлы матбугат материаллары.

Дидактик, тәрбияви әдәбият дин эшлеклеләренең карашын ачык чагылдыра. Шәригатьнең хатын-кыз хокукларын шактый чикләгәнен белеп, алдынгы карашлы дин әһелләре исламның хатын-кызлар һәм ирләрнең бердәй хокукларга ия булуына комачауламавын расларга тырышалар. Бу юнәлеш вәкилләренең чыгышларында, гадәттә, гомумән татар хатын-кызлары яки тагын да киңрәк – мөселман хатын-кызлары турында сүз бара. Хатын-кыз мәсьәләсенең мондый куелышын Р. Фәхреддин хезмәтләрендә очратабыз. Белгәнебезчә, дин белгече һәм мәгърифәтче галим революциягә кадәрге чорда 60 тан артык китап, шулай ук газета һәм журнал битләрендә 700 дән артык мәкалә язып бастыра. Аның 11 хезмәте шәхесне әхлакый һәм эстетик тәрбияләү мәсьәләләренә багышланган; алар арасында «Тәрбияле хатын» (1899), «Гаилә» (Оренбург, 1902) хезмәтләре мәдрәсәләрдә дәреслек буларак файдаланыла [Риза Фәхретдинов]. Бу мәкаләне язганда без Р. Фәхреддиннең «хатын-кыз мәсьәләсенә» багышланган «Нәсыйхәт» (1903), «Тәрбияле хатын» (1899), «Тәрбияле ана» (1898), «Гаилә» (1902) китапларын нигез итеп алдык.

Зыялылар һәм либераль буржуазия вәкилләренең карашы вакытлы матбугат мәкаләләрендә ачык күренә. Без «Вакыт», «Тормыш», «Әлислах» һ.б. газеталарда басылып чыккан материалларга таяндык. XX гасыр башында хатын-кыз мәгарифе мәсьәләләренә багышланып, татар вакытлы матбугатында дөнья күргән мәкаләләр 2020 елда Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты хезмәткәрләре тарафыннан әзерләп бастырылган җыентыкта туплап бирелде [XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында...]. Без, нигездә, шул җыентыктан файдаландык.

XX гасыр башында татар хатын-кызлары мәгарифе мәсьәләләренә багышланган материаллар бик күп, тоташ уфтанудан торганнары да («ник безгә махсус мәктәпләр юк?..», «караңгылыкта яшибез» һ.б), мәсьәләне хәл итүнең конкрет юлларын күрсәткәннәре дә байтак. Гомумән, мәкаләләрдә әйтелгән фикерләр язма авторының кем булуына түгел, ә кайчан язылуына карап аерыла. Материалларны карап чыккач, «Хатын-кызга уку нигә кирәк?» соравына 3 төрле җавап күрәбез.

1. Бәрәкәт эстәү өчен. Ягъни һәр мөселман кешесе, ир-ат яки хатын-кыз булуына карамастан, шәригатьчә яшим ди икән, кимендә укый-яза белергә тиеш. Бу – Алла кушкан гамәл. Димәк, наданлык – гөнаһ. Гөнаһтан качу өчен уку кирәк. Кыз балаларны укытуның бу максаты турында беренчеләрдән булып Р. Фәхреддин әйтә: *«Һәрбер кеше вә һәрбер кавем вә милләтнең бәхетле булуларына баш сәбәп –*

*гыйлемдер... Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт итәр өчен гыйлем кәсеп итегез»* [Фәхретдинов, 2004, б. 89]. Вакытлы матбугат битләрендә дөнья күргән мәкаләләрдә дә бу максат турында әйтелә: *«Адәм баласына гыйлем вә мәгърифәтсез адәмлек юк икәне һәркемгә мәгълүм. Мөслимә улдыгымыз сәбәпле, уку безгә дә фарыз»* (Тоз-Түбәдә кызлар // Вакыт. 1907. 21 июль [XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында..., б. 35]). Гомумән алганда, бу максат турында сүз күбрәк XIX гасыр ахырында дөнья күргән китапларда бара. XX гасырга кергәч, матбугат битләрендә әлеге мәсьәлә сирәк күтәрелә.

2. Хатын-кызның ана буларак «сыйфатын күтәрү» өчен. Р. Фәхреддин китапларында да бу фикергә киң урын бирелгән: *«Хатыннар өчен өйрәнүе кирәк булган гыйлемнәр – нинди гыйлемнәр соң алар?... Бу сорауның җавабында: «хатыннар өчен өйрәнүе кирәк булган гыйлем – ана вә хатын була белү өчен кирәк булган гыйлемдер», дисәк, безне бәлки ялгышлыкта гаепләмәсләр* [Фәхретдинов, 2006, б. 42]; *«Ана булу – бөек бер нигъмәт-муллык вә тиңдәше булмаган бер хөрмәт икәнлегендә шик юктыр. Мондый хөрмәткә аналык вазифасын вә хатынлык хезмәтләрен җиренә җиткергән затлар гына лаеклы булалар. Үзенең дин кирәкләрен белү, бала тәрбияләү ысулы белән таныш булу, беркадәр булса да уку-язу өйрәнү, хатыннар өчен белергә кирәк булган һөнәрләрне, өй һәм йорт белән идарә итү ысулын, күркәм вә бозык холыкларның ни икәнлеген аңлау – хатыннарның вазифаларыдыр. ...Аларга үзләренә Аллаһы Тәгалә тарафыннан әманәт – бүләк ителгән балаларны тиешенчә тәрбияләү вә үзләренә хас булган хезмәтләрне кимчелексез үтәү йөкләтелгәндер»* [Фәхретдинов, 2006, б. 27); *«Яхшы вә яман гадәтләрдә ата вә аналарына иярә торган балаларның аналары надан булса, балаларына гыйлем мәхәббәтен, әхлак дәресләрен һәр мөэмингә белергә кирәк булган нәрсәләрне кем өйрәтер?..»* [Фәхретдинов, 2006, б. 41].

Хатын-кыз белергә тиешле нәрсәләр рәтендә Р. Фәхреддин «өй һәм йорт белән идарә итү ысулын» гына түгел, шулай ук сәламәтлек саклау кагыйдәләрен дә күрсәтә: *«Форсат булганда, сәламәтлек саклау кагыйдәләреннән вә авыру кеше тәрбияләү тәртипләреннән иң мөһим булганнарын беркадәр булса да белү аналар вә хатыннар өчен файдасыз булмас. Чөнки хасталарны тәрбияләүдә хатыннарның осталыклары ирләрдән артык булып, аерым алганда, балалары хаста булганда бөтен кайгыларын шуңа сарыф итәрләр, хәтта ки үз хасталыкларын онытырлар вә боларның сәламәтлекләрен җиренә җиткерү хакында йөз төрле мәшәкатьләргә төшәрләр. Сәламәтлек саклау кагыйдәләреннән хәбәре булган хатын бу вакытта балаларына вә башкаларга олуг ярдәмнәр күрсәтә белер. Хаста тәрбияләү кагыйдәләрен белгән бер хатын хастага булыр-булмас табиблардан артык хезмәт күрсәтер. Аның йомшак сүзе вә мөлаем хәрәкәте хастаның күңеленә аерым рәхәт китерер»* [Фәхретдинов, 2006, б. 45].

Укытып, хатын-кызның ана буларак, хатын буларак «сыйфатын күтәрү» максаты турында вакытлы матбугат битләрендә дә бик

күп язалар. Иң элек хатын-кыз авторларның язмаларына күз салыйк: *«...без балаларымызны тәрбия кылуымыз илән бәрабәр, бөтен милләтне тәрбия кылуымыз табыладыр»* (Мәхдүмә. Вакыт. 1906. 11 апрель [XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында..., б. 18]); *«Тәрбияле вә гүзәл татар үрчетәсеңез килсә, әүвәл кыз балаларга мәктәпләр, мөгаллимәләр тәртип кылып, ысуле тәгълимне [методика] ислах кылырга иҗтиһадыңызны [тырышлыгыгызны] сарыф кылыңыз. Һәм дә бала тәрбиясе, йорт идарәсе, ысуле мәгыйшәт [көнкүреш], хифзыссыйхәт [гигена] кеби гыйлемнәрне укытыңыз. Аннан соң тәрбияле, мәгълүматлы татарлар көтәрсез»* (Фәхрелбәнат Сөләйманова. Вакыт. 1906. 9 май [XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында..., б. 21]); *«Безне тәрбия итер исәңез, без дә тәрбияле, әхлаклы, голүм фөнүннән хәбәрдар балалар үстерәчәкмез...»* (Ләйлә бинте Сабир. Вакыт. 1906. 4 май [XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында..., б. 20]).

Ир-атлар, мәсәлән Ф. Кәрими тарафыннан әйтелгән фикернең интонациясе башкачарак: *«Ирләр һәртөрле мәктәпләргә кереп укыйлар, белектән тәм вә зәвык табалар, вә һәртөрле гәзитә, җәридә, китап укып ләззәтләнәләр, вә белек нуры берлә күңелләрен нурландыралар, вә бер-берсе берлә татлы утырышлар кылалар. Без мөслимәләр исә, мәктәп күрмәй, белектән өлеш алмай, белексез, тәмизсез [пычрак], надан, тәрбиясез калып, гомеремезне аһ-ваһ илә кайгы вә хөсран илә, үзенә һичбер яктан юаныч тапмай, гомерене сагышта вә хәсрәттә кичерәдер. Хөрмәтле ирләр! Үз хәлеңезне төзегәндә вә төзәткәндә, без зәгыйфәләрне дә искә төшереңез, без мескеннәрне дә онытмаңыз, безне дә бераз тәрбия итү ниятендә булсаңыз ла; үзеңез безне тәрбия итмәгәч, без гүзәллекнең ничек икәнен белмәймез вә сезгә каршы нәзакәт күрсәтә алмыймыз. Шулай итеп, хөрмәтле ирләремезнең тәрбиясендә без дә, косурлык кылып, аларның күзенә иләмсез, сөемсез, мәхәббәтсез күренәмез! Укыган марҗалар безнең ирләремезне кулымыздан алып баралар!»* (Вәкилә (Ф. Кәрими). Вакыт. 1906. 11 март [XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында..., б. 13]). Бер яктан, автор уйлаганча, хатын-кызны укыту мәсьәләсенең фәкать ирләр кулында булуы аңлашылса, икенче яктан, мәзәк итеп булса да, татар хатыннары «марҗалардан» кайтыш, дигән фикер әйтелә.

Мәктәпләр ачып, уку оештыруны ир-атлардан көтәргәме, юкмы соравына Әхмәтҗан Биктимиров бик төгәл җавап бирә: *«Хәлеңезне төзәтүне ирләрдән көтмәңез. Алар үз хәлләрене үзләре дә аңлый алмыйлар»* (Әхмәтҗан Биктимиров. Вакыт. 1906. 15 июнь [XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында..., б. 29]).

Гомумән алганда, укытып, хатын-кызның ана буларак «сыйфатын күтәрү» максаты турында 1910 елларга кадәр бик күп сөйләнә, матбугатта басылган мәкаләләрнең дә шактый өлеше нәкъ шул фикергә багышланган. Нәтиҗә ясап, 1913 елда Сания Гыйффәт Кадыйрия болай ди: *«...безнең кыз, хатын өчен төзелгән мәктәпләремез нинди идеягә хезмәт итәләр? Кыз, хатын мәктәпләреннән күзәтелгән максат –*

*иҗтимагый-әхлакый тәрбия күргән милләт аналары йитештерү булса кирәк»* (Сания Гыйффәт Кадыйрия. Тормыш. 1913. 27 октябрь [XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында..., б. 62]).

3. Һөнәр өйрәнү өчен. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, уку-укытуның төп максаты булырга тиешле һөнәр өйрәнү мәсьәләсе 1910 елларда татар вакытлы матбугатында бик еш күтәрелә. Димәк, бу вакытка инде һәр җирдә диярлек башлангыч мәктәпләр ачыла. Инде икенче баскыч турында уйларга кирәк була.

Бу очракта, әлбәттә, татар җәмгыятендә традицион хатын-кыз эше дип кабул ителгән һөнәрләр турында сүз бара. Беренче чиратта, бу – кул эшләре. Кызлар мәктәпләренең һәрберсендә кул эшләренә өйрәтәләр: программа буенча да, өстәмә курслар оештырып та. Мәсәлән: *«Казанда Фатыйха бикә Аитова тарафыннан ачылган кыз балалар мәктәбендә җәй буенча, өч ай, кырыклап кызга тегү һөнәре өйрәтелгән. 15 ләбе калмый йөреп тәкмил иткәннәр [тәмамлаганнар]. Көн дә килә алмаганнары хәзер тәкмил итәчәкләр. Бу мәктәптә кыш көне дә дәресләрдән соң кул һөнәрләре өйрәтеләчәктер»* (Вакыт. 1910. 14 сентябрь [XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында..., б. 194]).

Татар кызларына кайсы һөнәр кулайрак булуын күрсәткән фикерләр дә очрый: *«...кызларын чолгау-чалма яулыгы, сөлге башы чигәргә өйрәтәләр, кружево ясаталар. Бу нәрсәләр, бердән, «фәкыйрь ата» кесәсенә сизелерлек кыйммәт төшә. Икенчедән, ни кызларның үз киләчәкләрендә, ни хәзер, бөтен гаилә өчен һич матди файдалары юкдыр. Чөнки сандыкларга тутырып, кияүгә киткәнче, дуамал асрарга калалар. Хәлбуки, бонлар урынына күбрәк оек бәйләү, тегү кебек һөнәрләр өйрәтсәләр, фәкыйрь кызлар боның илә кәсеп кыла, гаиләләренең тормышын җиңеләйтә, яки үзенә придан хәзерли алырлар иде. Бонлар – һәр көн акча китерә торган эшләрдер»* (Бер «фәкыйрь ата» исеменнән редакция. Вакыт. 1911. 29 март [XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында..., б. 195]); *«...кызлар мәктәбендәге бәйләү-чигү кеби һөнәрләрне түбән сыйныфларда кул күндерер өчен генә өйрәтелеп, зуррак сыйныф талибәләренә кисү-тегү һөнәре өйрәтелсә, гаилә арасына керәчәк ханымнарымызга матди зур файдасы булыр иде. Хәзерге көндә күп ханымнарымызның өйләрендә тегү машиналары була торып, мөкәммәл тегү тәртипләрен белмәдекләреннән, рус модисткаларына акча әрәм итүләре ханымнарымызның иң файдалы һөнәрдән мәхрүм идекләрен ап-ачык күрсәтә. Шуңа күрә, мәктәпләремездә бу көннән үк тегү эшләре мөкәммәл сурәттә өйрәтелә башласа, әллә безнең мөселман ханымнары да модисткаларга әрәм була торган акчаларын кесәләрендә калдырып, гаилә өчен файдалы кешеләр булып йитешерләр иде. Караңгы көнгә төшкән вакытларында да йиңеллек берлә котылырга иде»* (Мәрьям Ягъкубова. Сибирия. 1913. 16 гыйнвар [XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында..., б. 199]).

Хатын-кызларның консерватив өлеше, әлбәттә, яңалыкларга каршы килә. Аларның фикере Мәхмүдә Мозаффарова мәкаләсендә

яңгырый: *«Без гыйлем, һөнәр, мәгърифәт һәм уку юлына аяк басып, үземезнең, ирләремезнең аяк астында изелгән башларымызны күтәрик, без дә азрак хәрәкәтләник дип, укырга, язарга, белергә тырышсак та, Печән базары кибетенә төшүче, баш өстенә төен куйган, авызына сагыз кабып, өйләренә акбур яккан бозык хатыннар безләрне сабакка барганда-кайтканда төрле кабахәт сүзләр илә хурлыйлар, русча укып, ыштансыз йөрергә өйрәнәсез, татарча укып, егетләргә хат язасыз, диярәк. Хәтта мөгаллимәләремезнең диниләренә кадәр үзләре ни русчадан, вә ни дә татарчадан язарга, укырга белмиләр. Дин, иман вә игътикадтан тузан кадәр хәбәрләре улмаса да, «Тегү, чигү, бәйләү нигә кирәк? Менә без сезнең кебек мөгаллимәләрдән, әллә ниндәй марҗалардан укымадык та, үземез кәләпүш эшләп, Печән базарының матур-матур, япь-яшь егетләренә төшереп кыйммәт бәһагә сатамыз. Хисап нигә кирәк? Без менә бармагыбыз белән дә санап, кибетчеләрнең исләрен җибәрәбез. Сезгә бер дә укырга кирәк түгел, хатын-кызларга укырга хәрам», – дип, безне шулай дөньядагы кабахәт сүзләр илә сүгәләр»* (Мәхмүдә Мозаффарова һ.б. Әлислах. 1907. 19 ноябрь [XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында..., б. 40]).

Хатын-кызлар өчен кулай һөнәрләр арасында шулай ук мөгаллимәлек зур урын алып тора. Мөгаллимәләр әзерли торган мәктәпләр ачу зарурлыгын яктырткан мәкаләләр бик күп. Мөгаллимәләр өчен эш урыннары да җитәрлек, мәсәлән: *«Төрле тарафтан идарәмезгә хатлар яки җаваплары түләнгән телеграмнар килә; ышанычлы вә икътидарлы [булдыклы] мөгаллим вә мөгаллимә сорыйлар яки гәзитәмездә үзләрен игълан иткән мөгаллим вә мөгаллимәләрне, "ышанычлы вә икътидарлы булсалар, безгә йибәреңез, хакында тормамыз", диләр»* (Вакыт. 1909. 20 август [XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында..., б. 210]). Хатын-кызларның үзләренең дә мөгаллимәлеккә укыйсылары яки белемнәрен арттырасылары килә: *«Мөгаллимәләребез кыш укыта. Ләкин җәйдә тәгътыйль вакытында мәгълүматларын, белемнәрен арттыру өчен янә укыйсылары килгәнлеге сизелә. Шуның өчен мөселманның күбе мөгаллим вә мөгаллимәләрнең иң җыела торган урыны булган шәһәребез Казанда берничә мөгаллим вә мөгаллимәләр җыелышып, җәйге курс ачсак, ничек булыр иде икән? Үткән ел Уфада ачтылар, укыттылар. Бәлки бу ел да ачарлар, укытырлар. Ләкин мин Казан мөгаллим вә мөгаллимәләренең ул эшкә тәшәббес итмәүләренә [керешмәүләренә] тәәссеф итәм, кайгырам. Үткән җәйдә Казанда шундый мөгаллимәләр укырдай курсның булмавыннан аптырап йөргән берничә мөгаллимәне мин үз күзем белән күрдем»* (Маһруй Мозаффария. Сөембикә. 1914. № 11 [XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында..., б. 229]).

Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, татар хатын-кызлары өчен (кулай булмаса да) мөмкин дип саналган һөнәрләр рәтенә шәфкать туташы һәм сәүдәгәрлек тә килеп керә. Фәхрелбәнат Сөләймания әйткәнчә, *«...бу фәукылгадә [гадәттән тыш] вакыйгалар сәбәпле иң*

*артык бәхетсезлеккә очраган, иң артык ихтыяҗга төшкән милләт – безнең татар милләтедер. Моның сәбәбе дә – безнең милләтебезнең яртысын тәшкил иткән хатын-кызларыбызның башка милләт хатыннары шикелле тормышка муафыйк [яраклы] рәвештә хәзерләнмәгәнлекләре, ирләр табып китергәнне пешереп ашаудан башка нәрсә кулларыннан килмәгәнлегедер. Татарлар күк үк руслар да сугыш мәйданына китеп, өй тулы хатын-кыз, бала-чага калдырдылар. Ләкин анларның хатын-кызлары тормыш мәйданында ирләре берлә бергә эшләп, бергә мал табып өйрәнгәнгә күрә, аларда бездәге күк үк үзгәреш беленмәде. Һәм беленмәс тә. Чөнки аларның сатучы хатыннары сатуларын туктатмый. Ирләре кайтуга һич үзгәреш ясамый. Суммаларын киметми, бәлки арттырып тора алырлар, ирләре нинди генә сәнгатьтә булган булса да, ирләреннән соң да шул эшне алып бара алырлар»* [Сөләймания, б. 12]. Ягъни татар хатын-кызлары, ирләр нинди кәсеп белән көн күрсә, шуны үзләштерергә хокуклы. Хәтта тиеш тә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтик: хатын-кызлар мәгарифе системасы, хатын-кызны шәхси (бәрәкәт эстәү) һәм гаилә (ана роле) кысаларыннан алып чыгып, гаиләдән читтә дә эшләргә әзерли башлый, иҗтимагый тормышка җәлеп итә, үз көнен үзе күрерлек кәсеп белән тәэмин итә. Татар җәмгыяте аңында революциягә тиң бу үзгәреш барлы-юклы 10–15 ел эчендә булып, хатын-кызны татар җәмгыятенең мөстәкыйль берәмлеге итеп таныта.

**Әдәбият**

XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында хатын-кыз мәгарифе мәсьәләләре (документлар җыентыгы) / төзүче-авторлар: Мортазина Л.Р., Зиннәтуллина А.Ә. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2020. 380 б.

Риза Фәхретдинов // Татарика: онлайн энциклопедия. URL: https://tatarica.org/tat/razdely/religiya/islam/shheslr/fhretdin-riza

*Сөләймания Фәхрелбәнат*. Булдыксызлыгыбыз // Сөембикә. 1915. № 12. Б. 11–16.

*Фәхретдинов Р.Р.* Нәсыйхәт. Беренче, икенче, өченче китаплар: Әхлак гыйлеменнән дәреслек-кулланма. Казан: Мәгариф, 2004. 104 б.

*Фәхретдинов Р.Р.* Гаилә. Тәрбияле ана. Тәрбияле хатын. Казан: Рухи Мәгърифәт Академиясе, 2006. 123 б.

***Дәүләтшина Лилия Шамил кызы,***
*ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 7.043

*Л.М. Шкляева*

# ИДЕЛ БУЕНДАГЫ ҖИРЛЕ ХАЛЫКЛАР ЭСТЕТИКАСЫНДА ИЗГЕ ИМӘН ОБРАЗЫ

В данной статье рассматривается образ дуба в произведениях декоративного искусства, как воплощение священного (мирового) дерева архаичных верований у предков современных народов Среднего Поволжья. Опираясь на труды предшествующих исследователей, отмечаются параллели в миропонимании, связанные с охранительной функцией дуба, у финно-угорских и тюркских этнографических групп Поволжья, а также выявляются общие основания для формирования указанных представлений в мифологической картине мира, отраженной в эпосе, фольклоре и декоративно-прикладном искусстве.

**Ключевые слова:** народы Среднего Поволжья, мировое древо, священный дуб, художественные образы.

This article examines the origins of the cult of the sacred (world) tree in archaic traditional beliefs of the ancestors of modern peoples of the Middle Volga region. The author draws analogies of worshiping the world tree in the cultures of other peoples of the world. Based on the works of previous researchers we note parallels in the world-view associated with the protective function of the oak tree in the Finno-Ugric and Turkic ethnographic groups of the Volga region and also identify common grounds for the formation of these ideas in the mythological picture of the world, reflected in the epic, folklore and decorative arts.

**Keywords:** peoples of the Middle Volga region, world tree, mythological picture of the world, sacred oak, artistic images.

Идел буе халыкларының декоратив сәнгатендә дөнья агачына табыну белән бәйле образлар бар. Шуның ачык мисалы – имән агачы. Урта Иделдә үсеп утырган кодрәтле имәннәр илаһи көчләрне гәүдәләндергән һәм биредә күптәннән яшәгән халыклар аларда сыену эзләгән. Дөнья турындагы күзаллаулар системасында аларның мәҗүси культлары XVI–XVII гасырлар сәяхәтчеләренең дә игътибарын җәлеп иткән (С. Герберштейн (1557), Д. Флетчер (1591), А Олеарий (1656)). Тикшеренүләрне XVIII–XIX гасырларда яшәгән галимнәр дәвам иткән (Г.Ф. Миллер (1732–1765), Н.П. Рычков (1770–1772), П.С. Паллас (1773), А. Фукс (1834), К.Ф. Фукс (1839), П.И. Мельников (1851), К.К. Кузнецов (1885), А. Риттих (1870), П.С. Смирнов (1896)). XX гасырда А.И. Емельянов (1913, 1921), В.П. Налимов (1928), Б.А. Латынин (1930), Д.К. Зеленин (1937), Н.И. Воробьев (1953, 1956) кебек этнографларның бу өлкәдәге фәнни тикшеренүләре билгеле. Соңрак А.Ф. Ярыгин (1976), О.В. Данилов (1992), В.Е. Владыкин (1993), Н.Ф. Мокшин (1998) хезмәтләре. XXI гасырда бу галимнәрнең исемнәренә В.П. Иванов (2009), Р.Р. Исхаков (2014) һ.б. өстәлә.

Белгечләр Урта Иделдәге төрле халыкларның бердәй климат шартларында яшәгән һәм хуҗалык эшчәнлегенең бертөрле үсеш стадияләрен үткән ата-бабаларының дөнья төзелеше турындагы күзаллауларында охшашлыклар шактый булуын расладылар [Золотова, с. 5; Напольских, с. 19). Алар буыннан-буынга күчеп киләләр, кешеләрнең әйләнә-тирә табигать белән үзара хезмәттәшлегенә нигез булалар һәм эстетик кануннарда чагылыш табалар [Владыкин, с. 146].

Галимнәр билгеләп үткәнчә, урман кешеләр тарафыннан ике төрле кабул ителгән: аулак чокырлар яшерен куркыныч чыганагы гына түгел, ә азык табу, шулай ук кирәк чагында ышанычлы качу урыны да булган. Моннан тыш Идел буендагы имән урманнары кеше өчен чит-ят күзләрдән яшерелгән үзенчәлекле гыйбадәтханәләр дә булып хезмәт иткән [Ярыгин, с. 9]. Аларда үсә торган агачлар илаһи сыйфатларга ия дип саналганнар, һәм кырыс тыюлар системасы аларны сакларга кушкан. Акрынлап ышануларда иң зур агач күренә башлый. Дөнья агачы турындагы мифлар барлыкка килә [Ярыгин, с. 76]. Тикшеренүчеләрнең күбесе Идел буе халыкларының мәҗүси ышанулары тарихында «дөнья агачына» яки «тормыш агачына» табыну чорын аерып чыгарган [Полухина, с. 86]. Шул ук вакытта кайбер белгечләр «изге имәннәр»не мифик «дөнья агачы» белән тәңгәлләштерүне кире кагалар [Березкин, с. 15; Напольских, с. 27]. Әмма күпләр фикеренчә, хәзерге Урта Идел буе халыкларының борынгы бабалары өчен ул имән агачы булган, бу – яшәү тирәлегенең бердәйлеге белән дә аңлатыла.

Төрле культураларда «дөнья агачы» ролен төрле агачлар уйный. Мәсәлән, далада яшәүче төркиләрдә – мифик Байтирәк агачы [Золотова, с. 5], карел-финнарда – «Калевала» эпик поэмасы буенча билгеле «зур имән» [Кундозерова, с. 179], Скандинавия мифларында – Иггдрасиль корычагачы [Смирницкая, с. 24]. Ирландиядә биш изге агач исәпләнә, алар арасында Эо Мугна имәне [Шкунаев, с. 17] һ.б. бар. Барлык санап үтелгән очракларда кешеләр «дөнья агачы»ның төзелешен дөньяның өч өлештән торган структурасы белән тәңгәлләштереп күз алдына китергәннәр: ябалдашлары – күк (һәм анда яшәүчеләр), кәүсәсе – җир (һәм аның халкы), тамырлары – җир астындагы өлеше (мәетләр кую урыны).

Идел буе халыкларының ышануларында изге имән «җирдә тереклекне яңадан торгызу сәләтенә» ия, кагылгысыз һәм саклаучы агач саналган [Исхаков, с. 15]. Шул ук вакытта ул бердәнбер дип түгел, ә күплек санда тәкъдим ителергә мөмкин. Мәсәлән, фин-угорларның аерым территорияләрендә калган урман массивыннан бүлеп алынган изге «кирәмәт» имәнлекләре булган [Владыкин, с. 76]. «Тормыш агачы» хәзерге татарларның һәм чувашларның катлаулы этногенезына үз өлешен керткән төркиләрнең дә, фин-угор халыкларының да ышануларында әһәмиятле урын алып торган. Христианлыкка кадәрге чорда Урта Идел буе чувашлары катгый рәвештә саклананган изге имәнлекләрдәге («кирәмәт» дип тә йөрткәннәр) «зур имәннәр»гә ярдәм сорап мөрәҗәгать иткәннәр. Вакытлар узу белән, «кирәмәт»-имәнлек-

тәге табыну урыннары чокырларга күчкән. Һәм аның табигый көчкә ия вазифасы да үзгәргән: ул изге саклаучы булудан туктаган һәм төрле авырулар һәм бәла-казалар чыганагына әверелгән [Ашмарин, с. 48]. Шул ук исемдәге агач пот пәйда булган. Әмма элеккеге традицион ышануларның эзләре фольклорда сакланган: «Чуваш халкының җыр поэзиясендә җәенке ябалдашлы имән агачы – атакай, ир-ат матурлыгы символы» [Миннуллин, с. 38].

Чувашлар арасында таралган һәм Урта гасырлар катламына караган «Көмеш диңгездә имәннең тамырлары өскә таба, ә имәннең ботаклары түбәнгә үсә. Ийе (явыз рух) аларның яфракларына килеп җиткәч кенә, баланың авырып китүенә ирешәчәк» [Кагаров, с. 334] әфсен-төфсене шул турыда сөйли. Бу очракта шунысы күз алдында тотыла: көмеш диңгездәге имән яфракларына беркайчан да бернинди явыз көч тә кагыла алмаячак, димәк, бала сәламәт булачак. Элек-электән урмандагы иң биек һәм нык агач төп төрки алла – Тәңре белән элемтә каналы буларак кабул ителгән, ул үзе күктәге яклаучы булып саналган һәм халыкның иминлеген чагылдырган. XX гасыр урталарына кадәр чувашларда, урыны-урыны белән, туган йорттан еракларга чыгып киткәнче, изге имән тирәли әйләнеп йөрү гадәте сакланган. Туган илен ташлап киткән кеше имәннең саклау куәсе үзен саклар һәм кире кайтырга мөмкинлек бирер, дип өметләнгән [Исхаков, с. 16].

Идел буе халыкларының (фин-угор һәм төрки) күмәк хәтерендә хәзерге көнгә кадәр табигать күренешләренә үтә нык бәйлелек шартларында формалашкан архаик ышануларның калдыклары сакланган. Керәшен татарлары (Татарстанның Кайбыч районы) һәм чуваш (Татарстанның Аксубай районы) авылларында хәзер яшәгән халыкларның бер өлеше имәнлекләрне табыну урыны буларак кабул итә. Керәшеннәр ялгыз зур имәнне «Тәңре агачы» дип атаганнар һәм аны шифаны, уңышны, үрчемлелекне арттыручы сыйфатларга ия дип саганнар [Исхаков, с. 14].

Халыкның этник культура яшәеше дәвамында формалашкан дөньяга карашы, аны ничек аңлавы декоратив-гамәли сәнгать образларында чагылыш тапты. Кешеләр өчен аеруча әһәмиятле булган, аларның тормышына йогынты ясаган табигать көчләре борынгыдан ук визуаль символларда гәүдәләнеш таба [Галушка, с. 5]. Әйтик, имән яфраклары һәм имән чикләвекләре образлары декоратив-гамәли сәнгать эшләнмәләрен бизәүдә тотрыклы элементларга әйләнә [Латынин, с. 33]. Аларны нәселдән килгән җирле халык һөнәрчелеге осталары тарафыннан эшләнгән предметларның үзенчәлекле бизәлешендә очратырга мөмкин. Чигүдә һәм агачны кисеп-уеп бизәк төшерүдә чәчәк-үсемлек бизәкләре композициясендә таныш яфракларның формалары очрый, зәркәнчелек үрнәкләрендә (шөлдерле асма бизәк һәм чигә асылмалары) имән чикләвекләре рәвешендәге бизәнү әйберләре табыла.

XIX–XX гасыр урталарында татар авылларында яшәүче чигүчеосталар алъяпкыч, эскәтер һәм хәтта намазлыклар чиккәндә имән

яфраклары сурәтенә аеруча еш мөрәҗәгать итәләр. Әлеге факт автор тарафыннан җыелган экспедиция материаллары белән дә раслана. Мәсәлән, Акъяр (Азеево) авылы (Татарстанның Яңа Чишмә районы) китапханә музее экспозициясендә үсемлек орнаменты төшерелгән кара намазлык күрсәтелә, аны 1923 елда тамбур техникасында С.М. Шәйхетдинова чиккән. Эшләнмәнең караңгы фонында кызгылт-сары һәм ал төстәге стильләштерелгән имән яфраклары бигрәк тә нык күзгә ташлана. Зирекле авылы (Яңа Чишмә районы) музеенда төрле төстәге бизәкләр төшереп чигелгән кызыл ашъяулык саклана (XX гасыр урталары), аның да компонентларының берсе – сары имән яфраклары. Мондый чигү үрнәкләре Актаныш районы осталары намазлыкларында да бик күп [Солтанова, с. 369]. Күрсәтелгән элементлар Татарстан декоратив сәнгатенең профессиональ осталары иҗатында да очрый. Мәсәлән, чигүче З. Бикташеваның «Болгар чәчәге» әсәрендә (2004) көзге имәннәрнең алтын яфраклары Болгар мәдәнияте символы булып хезмәт итә [Шкляева, с. 226]. Агачны кисеп-уеп бизәк төшерүче оста Р. Әхмәтовның «Минем йортым – минем мирасым» (2020) әсәрендә тормыш агачы композициядә үзәк урынны алып тора. Рәссам кодрәтле имәннең тылсымлы образын бирүгә ирешкән. Авторның идеясе буенча, агачның куе ябалдашлары Татарстан картасы абрисы белән туры килә. Көчле ботакларда гадәти булмаган җимешләр аермачык күренә, аларның һәркайсы республика гербларының берсе булып тора. Изге имән кисеп-уеп традицион бизәк төшереп эшләнгән үзенчәлекле агач йорт фонында җәелеп үскән.

Тарихи үткәнгә мөрәҗәгать итү композициядәге стиль элементларының семантик әһәмиятен ачарга ярдәм итә. Имән яфрагы һәм имән чикләвеге элек саклау функциясен үтәгән, яшәүгә сәләтне чагылдырган. Хәзерге вакытта Татарстанның профессиональ рәссамнары иҗатында үзенең тамырлары белән Болгар мәдәниятенә барып тоташучы әлеге образларның семантик әһәмияте яңадан карала. Бүген алар декоратив функцияләр үти һәм көчмлелекне чагылдыра.

## Әдәбият

*Ашмарин Н.И.* Введение в курс чувашской народной словесности / Чувашский фольклор. Специфика жанров. Чебоксары: Типография № 1, 1982. С. 3–53.

*Березкин Ю.Е.* Мифологические деревья в лесу культуры // Этнографическое обозрение. М.: Изд-во «Российская академия наук» № 6, 2012. С. 3–18.

*Владыкин В. Е.* Культ Кереметя у удмуртов / В.Е. Владыкин // Вопросы советского финно-угроведения: Тез. докл. Саранск, 1972. С. 75–77.

*Галушка Н.В.* Символика элементов крымскотатарского орнамента в структуре древа жизни // Таврический научный обозреватель. 2017. № 4–2 (21). С. 3–6.

*Золотова Т.А.* Очерки традиционной культуры народов Поволжья. Йошкар-Ола: МарГУ. 1996. 100 с.

*Исхаков Р. Р.* Параллели в религиозно-мифологических картинах мира и обрядовости татар и чувашей: опыт историко-этнографической реконструкции. Чебоксары, 2013. 60 с. (Научные доклады / ЧГИГН; вып. 11).

*Кагаров Е. Г.* Мифологический образ дерева, растущего корнями вверх // Доклады АН СССР. Л.: 1928, серия В, № 15. С. 331–335.

*Кундозерова М.В.* Мировое древо и ландшафные знаки-символы его локализации (по материалам карельских эпических песен и заклинаний) // Труды Карельского научного центра Российской академии наук. 2012. № 4: Гуманитарные исследования, вып. 3. С. 178–184.

*Латынин Б.А.* Мировое дерево – древо жизни в орнаменте и фольклоре Восточной Европы / Известия ГАИМК. В. 69. Л.: Печатный двор, 1933. 33 с.

*Миннуллин К.М.* Общая символика в песенной поэзии народов Поволжья и Приуралья // Типология татарского фольклора. Казань: Мастер Лайн, 1999. – 156 с.

*Напольских В. В.* Мифологема мирового древа и мифологии народов уральской языковой семьи // Этнографическое обозрение. М.: изд-во РАН. 2012. С. 19–28.

*Полухина А.Н.* Проблемы взаимовлияния традиционных культур славян и финно-угров Волго-Камья в процессе развития этносов // Вестник Удмуртского университета. № 5. 1996. С. 85–87.

*Смирницкая О.А.* Корни Иггдрасиля. Эдда. Саги. Скальды. М.: Терра, 1997. 638 с.

*Солтанова Р.Р.* Осталар ягы // Милли-мәдәни мирасыбыз: Актаныш. 2 нче басма. Казан, 2021. 572 б.

*Шкляева Л.М.* Искусство вышивки Земфиры Бикташевой как часть национальной культуры татарского народа // Проблемы просвещения, истории и культуры сквозь призму этнического многообразия России (к 170-летию чувашского просветителя И.Я. Яковлева): Сборник трудов Всероссийской научной конференции с международным участием. 2018. С. 225–229.

*Шкунаев С.В.* Предания и мифы средневековой Ирландии. М.: Изд-во Москов. ун-та, 1991. 284 с.

*Ярыгин А.Ф.* Современные проявления дохристианских верований марийцев. Йошкар-Ола: Марийское кн. изд-во, 1976. 76 с.

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 391

***О.Ю. Бердникова***

# ТАТАРСТАНДА ЗАМАНЧА МОДА ЮНӘЛЕШЕ БУЛГАН КИЕЗ ҺӘМ ЕФӘК КОСТЮМНАР

В данной статье анализируются костюмные комплексы из войлока и шелка, созданные в рамках дизайнерского проекта, реализованного в Казани 2021 г. силами мастеров «Киез НУР», региональной общественной организации развития ремесла войлоковаляния в Татарстане. Основой для художественного решения послужили образы, характерные для национальной культуры татар.

**Ключевые слова:** искусство костюма, войлоковаляние, этнический стиль, декоративная система, татары.

This article analyzes costume complexes made of felt and silk created within the framework of a specific design project implemented in Kazan in 2021 by the masters of «Kiez NUR», a regional public organization for the development of the craft of felting in Tatarstan. The basis for the artistic solution was the images characteristic of the national culture of the Tatars.

**Keywords:** costume art, felting, ethnic style, decorative system, tatars.

Хәзерге заман костюм сәнгатен кешенең тышкы кыяфәтенең образлы чагылышы дип тә, кешенең нинди этноска каравын XXI гасырның модалы тенденцияләренә туры килгән чаралар ярдәмендә визуальләштерү дип тә билгеләргә мөмкин.

Костюм үсеше проблемалары белән П.Г. Богатырев (1971), Ф.Х. Вәлиев (1984), А.Б. Гофман (1994), В.В. Ермилова (2001), Н.М. Калашникова (2002), О.Б. Ванштейн (2005), А.А. Васильев (2011), М.А. Коськов (2011), О.В. Пудакова (2016) Н.В. Герасимова (2019), Н.Ю. Митрофанова (2020) һ.б. кебек сәнгать белгечләре һәм культурологлар шөгыльләнгән. Хәзерге заман костюм сәнгате өлкәсендәге тикшеренүләрнең актуальлеге җәмгыятьтә рухи ориентирларның үзгәрүе белән бәйле. Алар маркетинг хезмәтендәге икътисади үзгәртеп корулар һәм гамәлләр белән бәйле, максатчан төстә ниндидер этнографик төркем вәкиле буларак түгел, ә «арт-проект» буларак, шәхес формалаштыруга юнәлдерелгән [Демшина, с. 59]. Әлеге процесслар милли үзидентификацияне юкка чыгара. Бу тамгаларның тулысынча югалуына юл куймас өчен, төрле этник элементларга ия костюм комплекслары булдырырга кирәк [Султанова, с. 542]. Хәзерге галимнәр билгеләп үткәнчә, костюм предметларының төп нигезен эшләнү материалы тәшкил итә [Романовская, с. 38]. Бүген югары мода дөньясында киезнең көннән-көн популярлаша баруын билгеләп үтәргә кирәк.

Төрки дөньяда йөзләрчә еллар буена киезнең традицион кием җитештерүдә кулланылуын исәпкә алып, «Киез НУР» киез басу һөнәрен үстерү буенча төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзалары 2021 елда

костюмнар коллекциясен булдыруда катнашырга карар кылдылар. Проектның инициаторы – «Э-моция» үзешчән театр студиясе (сәнгать җитәкчесе Н.Н. Суркина, костюмнар буенча рәссам М.В. Родионова) чыгыш ясады. Ел дәвамында оста О.В. Смирнова, М.В. Родионова эскизлары буенча, «Иске Казан әкиятләре» дип исемләнгән коллекциягә кергән 15 костюм комплексын эшләде.

Киездән, ефәк, вискоза һәм фатиннан юеш басу техникасын кулланып җитештерелгән эшләнмәләр экологик яктан югары сыйфатлы, чөнки аларның нигезен табигый тукымалар һәм сарык йоны тәшкил итә. Костюм комплекслары төрледән-төрле формадагы бизәкләп эшләнгән дизайн әсәрләре булып тора, чөнки татар халкы традицион киемнәргә чигеп бизәк төшерергә яраткан [Шкляева, с. 128]. Ир-ат костюмнары джемпер тибындагы өске кием һәм ыштан компонентларыннан тора. Хатын-кызлар киеменең нигезен күлмәкләр яки топ һәм чалбарлар тәшкил итә. Барлык баш киемнәренең формалары ир-ат кәләпүшен яки асылмалы чуклар белән бизәлгән кызлар такыясын (тайканы) хәтерләтә. Күрсәтелгән үзенчәлекләр аларга, күлмәк итәге буйлап баручы бөрмәләр белән беррәттән, татар стилен тудырырга мөмкинлек бирә. Күпчелек эшләнмәләрнең кайма читләрендә лалә чәчәкләре рәвешендәге декоратив бизәк (вставка) бар. Алар бизәкне тәгәрәтеп кертү (приваливание) техникасында әзерләнә: бизәү өчен keләмнең төп фонына буялган йон кушыла. Җиде костюм җылы терракота гаммасында, сигезе – салкын ультрамарин төсендә. Аларның беренчесе тормыш, җылылык һәм яктылык энергиясен символлаштыра, икенчесе тереклек бирүче дымны да, хәтерсез калдыручы суны да гәүдәләндерә. Якты-ачык төсләрдән караңгыга күчә барган сузылмалар җемелдәү эффекты тудыра. Костюмнар комплексының мондый капма-каршы колористик чишелеше дуалистик фикерләүне, тормышның каршылыклы күренешләре чагылыш тапкан дөньяга карашларны чагылдыра.

Аяк киеме колористикасы буенча костюмның гомуми ансамбле белән чиратлаша һәм аңа аерым бер театральлек һәм әкияти төс бирә. Иң элек йонны чылатып тәгәрәтәләр, махсус агач калыпларда борынын өскә каратып бөгеп тиешле формага китерәләр. Мондый башмакларны «пуленалар» дип атыйлар. Алар XII–XIII гасырлардагы тәре походлары вакытында Көнчыгыштан китерелгәннән соң, Урта гасырлар Европасында популярлашып китәләр. Киләсе гасырда бу аяк киеме бик тар һәм сузылган рәвешкә китерелә.

Ир-ат костюмнары арасында берсенең прообразы булып Казанның танылган символы – Көнчыгыш әкиятләрендәге утлы аждаһаларның «туганы» – канатлы елан Зилант хезмәт иткән. Озын һәм иркен җиңле киемнең кызгылт-сары төстәге өске өлешендәге молния аркада урнашкан. Баш киеме аждаһаның борынын имитацияли, киң алынма яка елан кабыгын хәтерләтә. Җыерчыкланып беткән канатлар һәм койрык рәвешендәге бөркәнчек киемне бербөтен итә.

Икенче комплекс батыр образын тудыра. Аның җилкәләре җиңнәрнең төрледән-төрле (өске өлешендәге бантны хәтерләткән,

шулай ук буеннан буена сузылган аркылы) бөрмәләр исәбенә тагын да киңрәк булып күренә. Киемдәге төрки декоратив сәнгать өчен хас чәчәк-үсемлек бизәкләре геройның милли үзенчәлеген ассызыклый. Костюм комплексының этник стиле үзенчәлекләре киң ыштан белән дә тулыландырыла.

Ирекле формаларга бай чираттагы костюм юлбасар образын тудыра. Җиңнәр киңрәк итеп эшләнгән, бу аларны декоратив тыгыз бөрмәләр белән бизәргә мөмкинлек бирә. Туры силуэтлы чалбарның балаклары җыелып, йомшак итек эченә тыгып куелган.

Хатын-кыз киемнәренең берсе хан кызы образын күз алдына китереп бастыра, ул зур аскы кисемле күлмәктән һәм Урта гасырлар стилендәге ачык фатин шлейфтан тора. Материалның фактуралылыгы нәфис зәбәрҗәт төсеннән тирән ультрамарин тоннарга күчә бару белән баетыла. Озын җиңнең өске өлеше фонарик формасында.

«Чулпан» – зәбәрҗәт-зәңгәр төстәге күлмәк – костюмның милли элементларын стильләштерү белән игътибарны җәлеп итә. Ул гадәттәгедән озынрак итеп эшләнгән изү, шулай ук тездән башланган бала итәкнең киң каймасында урнашкан ефәктән эшләнгән чәчәкле бизәкләрдән тора. Аның аскы каймасындагы йомшак бөрмәләре караңгы зәңгәр-шәмәхә төстәге дулкынсыман сызык барлыкка китерә. Күлмәкнең җиңел фатин җиңнәре тыгыз киез янәшәсендә аеруча нәфис булып күренә.

Тагын бер костюм һәр халыкның мәдәниятендә беренчел дәрәҗә әһәмияткә ия булган кояшны гәүдәләндерә. Әлеге образ кызгылт сарыдан башлап чия кызылга кадәр төсләр гаммасы һәм диск рәвешендәге күкрәк бизәге кебек тәэсирле чаралар ярдәмендә барлыкка килә. Бу дисктан киез һәм фатиннан эшләнгән нурлар тарала. Һәр нур лалә чәчәге рәвешендәге күләмле декор белән тәмамлана. Бармак очларыннан түбәнрәк төшеп торган воланлы җиңнәр аеруча күзгә ташлана, ә аларның астыннан үтә күренмәле фатин бөрмәләр күренеп тора.

Коллекциядәге әкияти пәри кызы костюмы да үзенчәлекле. Эшләнмәнең чит-читләре ефәктән ясалган чәчәкләр белән бизәлгән, аларның күбесе арка ягында урнашкан. Кыек итәк очының кабарынкы булуын ассызыклагандай, җиңел бөрмәләре белән озын шлейф сузыла, ул җиде кат фатин белән ныгытылган. Киездән эшләнгән костюмның үтә күренмәле җиңле туника формасындагы өске өлеше диагональ каймалар белән төгәлләнә.

«Яугир хатын» костюмы ике өлештән тора. Өсте – ике катлы җилкә канатлары (кыска – киез һәм үтә күренмәле озын) белән бизәлгән җиңле топ. Икенчесе итәк-чалбар рәвешендә стильләштерелгән, аның иң аскы өлеше генә җыелган, бу исә аңа грушасыман форма бирергә ярдәм итә. Эшләнмәгә чәчәк-үсемлек бизәкләре төшерелгән.

Ә менә фатин җиңле һәм А хәрефе рәвешендәге «Миләүшә» күлмәге ефәктән «коелган» оча торган ат образы белән бизәлгән. Ат төрки халыкларның тормышы белән нык бәйләнгән һәм әкиятләрдә

тугры һәм игелекле дус итеп тасвирланган. Төрки мәдәнияттә ул хәрәкәтнең үзен символлаштырган, кайчакта хәтта Тәңренең гәүдәләнеше булган.

«Илнур» һәм «Алинә» костюмнары бердәмлекне һәм үзара бәйләнешләрне символлаштыра. Төсләрнең кулланылышы да шул максатка буйсындырылган. Әйтик, җылы тоннардагы хатын-кызлар киеме зәңгәр муенса белән белән тулыландырыла, ә ирләрнеке – киемнең кызгылт сары төстәге өске өлеше белән. Туры фасонлы чия кызыл төстәге «Алинә» күлмәгенең өске өлеше күләмле, терсәктән алып беләзеккә кадәресе – тар. Биек яка муен сызыгын ассызыклый. Эшләнмәнең түбәнге өлешен катлы-катлы йон һәм фатин воланнар бизи. «Илнур» костюмы вискоза белән бизәлгән сыланып торган пуловердан гыйбарәт, ул ачык төсләрдән башланып, зәп-зәңгәр-шәмәхә төсләргә керүче киң ыштан белән контраст тудыра.

Шулай итеп, «Киез НУР» осталары үзенең «Иске Казан әкиятләре» дигән исеменә бик тә туры килә торган үзенчәлекле һәм игътибарга лаек коллекция булдыруга ирештеләр, костюм сәнгатен үстерүгә үзләреннән лаеклы өлеш керттеләр. Ул, башка тарихи чорлардан аермалы буларак, хәзерге заман кешесенең дөньяга карашын ачучы субъектив-шәхси юнәлешкә нигезләнә. Костюм, бүгенге көннең мөһим символик системасы элементы буларак, яшьләрнең дөньяны кабул итүенә йогынты ясый.

«Иске Казан әкиятләре» костюмнар коллекциясе тышкы кыяфәтне хәзерге этник стильдә бизәүнең үзенчәлекле чишелешенә кызыксыну уятырга тиеш. Костюм сәнгате хәзерге вакытта XXI гасыр кешесе өчен иң тәэсирле сәнгати иҗат төренең берсенә әверелә бара. Ул аның үз-үзен нинди итеп күрүен һәм эстетик өстенлекләрен чагылдырырга мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

*Богатырев П.Г.* Вопросы теории народного искусства. М.: Искусство, 1971. 511 с.

*Валеев Ф.Х.* Народное декоративное искусство Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 171 с.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Декоративное искусства Татарстана, 1920-е – нач. 1990-х гг. Казань: Фэн, 1995 г. 188 с.: ил.

*Ванштейн О.Б.* Денди: мода, литература, стиль жизни. М.: НЛО, 2005. 640 с.

*Васильев А.А.* Судьбы моды. М.: Альпина, 2011. 464 с.

*Герасимова Н.В.* Национальные традиции в современном костюме татар Иркутской области // Мода и дизайн: исторический опыт – новые технологии: Матер. XXII Междунар. науч. конф. СПб., 2019. С. 75–78.

*Гофман А.Б.* Мода и люди: новая теория моды и модного поведения. М.: Наука, 1994. 233 с.

*Демшина А.Ю.* Мода в контексте визуальной культуры: вторая половина XX – начала XXI в. СПб.: Астерион, 2009. 106 с.

*Ермилова В.В., Ермилова Д.Ю.* Моделирование и художественное оформление одежды. М.: Академия, 2001. 184 с.

*Калашникова Н.М.* Народный костюм (семиотические функции). М.: Сварог и Ко, 2002. 376 с.

*Килошенко М.И.* Психология Моды. М.: Оникс, 2006. 320 с.

*Коськов М.А., Мазулевская Ю.Е.* Костюм. Основы теории. СПб.: ЛГУ им. Пушкина, 2011. 224 с.

*Липская В.М.* Функциональность костюма как транслятора социальных ценностей // Обсерватория культуры. Научно-теоретический журнал, № 1. М., 2012. С. 92–97.

*Митрофанова Н.Ю.* Основные аспекты Эко реабелитации текстиля в современном мире // Мода и дизайн: исторический опыт – новые технологии. Материалы XXIII Междунар. науч. конф / под ред. Н.М. Калашниковой. СПб.: ФГБОУВО «СПбГУПТД», 2020. С. 204–208.

*Пудакова О.В.* Костюм – хранитель ценностей этноса // Искусство в школе. М., 2016. № 2. С. 30–32.

*Романовская Ж.Б.* История костюма и тендерные сюжеты моды. СПб.: Алетейя, 2010. 442 с.

*Султанова Р.Р.* Интерпретация народного татарского костюма в современном проектировании (в соавторстве с О. Пудаковой) // Искусство и художественное образование в контексте межкультурного взаимодействия: Материалы Международной научно-практической конференции «Искусство и художественное образование в контексте межкультурного взаимодействия» (Казань, 6–7 декабря 2012 г.). Казань: Отечество, 2013. С. 541–544.

*Шкляева Л.М.* Стилевые особенности вышивки в декоре татарского народного костюма (по материалам экспедиций ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ в 2012–2018 гг.) // Материалы XXIII Международной конференции »Мода и дизайн: исторический опыт – новые технологии» (РЭМ. Санкт-Петербург, 27–29 мая 2021). СПБ: СПбГУПТД, 2021. С. 127–130

***Бердникова Ольга Юрьевна,***

*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге аспиранты*

УДК 784.4

## СОЛТАН ГАБӘШИ
## ТАТАР МУЗЫКАСЫ ТУРЫНДА

В статье рассматриваются ответы композитора, фольклориста и педагога С.Х. Габаши на вопросы журнала «Яңалиф». В анкете делается акцент на развитие пролетарской культуры, соотношение старого и нового в татарской музыке. Особое внимание уделяется вопросам изучения фольклора, этнографии, дается оценка оперному жанру, зарождающемуся в татарском искусстве.

**Ключевые слова:** Султан Габаши, татарская музыкальная культура, композитор, фольклор, этнография, театральное искусство, опера, спектакль.

The article examines the answers of the composer, folklorist, teacher S.H. Gabashi to the questions of the magazine «Yanalif». The questionnaire focuses on the development of proletarian culture, the relationship between old and new in Tatar music. Special attention is paid to the study of folklore, ethnography, and the opera genre emerging in Tatar art is evaluated.

**Keywords:** Sultan Gabashi, tatar musical culture, composer, folklore, ethnography, theatrical art, opera, performance.

«Яңалиф» журналы 1927–1932 елларда Казанда татар телендә латин шрифты белән Татарстан Мәгариф халык комиссариаты (Наркомпрос), Татарстанның пролетар һәм совет язучылары оешмасы тарафыннан басыла. Журналда әдәби театраль һәм музыкаль күзәтүләр белән Х. Вәли, Г. Нигъмәти, М. Парсин һәм башкалар чыгыш ясый.

1931 елда журнал редакциясе татар музыкасын үстерү проблемалары буенча читтән торып түгәрәк өстәл үткәрә һәм фикер алышу оештыра. Журналның шул елгы 3–11 нче саннарында әлеге түгәрәк өстәл белән бәйле материаллар урын ала. Татар зыялыларының күренекле вәкилләренә татар музыка мәдәниятенең бүгенге торышына кагылышлы 12 сораудан торган анкета тәкъдим ителә. Хөкем сөрүче совет чоры идеологиясе нигезендә бу сорауларда пролетариат мәдәнияте үсешенә, музыкага кагылышлы яңа проблемаларны чагылдыру, халык иҗатын фәнни өйрәнүгә, этнография байлыкларын туплауга, иҗади кадрлар тәрбияләүгә басым ясала.

Сорауларга композиторлардан С.Х. Габәши һәм А.С. Ключарев, дирижерлардан А.А. Литвинов, җырчылардан Н. Сафин җавап бирә. Дүртенче номерда шагыйрь Хәсән Туфанның шул ук темага кагылышлы «Пролетариат композиторлары кирәк» дигән мәкаләсе дә басылып чыга.

Татар профессиональ музыка мәдәниятенең үсеш юлларын билгеләгән музыкант – композитор, музыка белгече, фольклорчы, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Солтан-Әхмәт Хәсәнгата улы Габәши барлык сорауларга да төгәл һәм ачык җаваплар бирә. Алар журналның

3–6 нчы саннарында басылган. Монда композитор үзенең теоретик карашларын, татар халкының музыкаль иҗатына мөнәсәбәтен, гореф-гадәт һәм новаторлык проблемаларын турыдан-туры яктырта. Журнал сорауларына җавап биреп, С. Габәши, асылда, иҗатының алдагы уңышлы чорына йомгак ясый сыман.

Солтан Габәшинең теоретик карашлары шактый алдынгы булып күренә. Мәсәлән, лад төшенчәсен ул интонацион тәртип күренеше буларак күз алдына китерә. Шулай ук композитор көй һәм гармониянең аваз биеклеге бердәмлеге принцибын раслый. Шуның белән бергә Габәши киләчәктә аккорд материалы, көйнең үзенчәлеген бозмыйча, чит тавышлар белән баетылачак дип фаразлый. Композиторның пентатоникага нигезләнгән модаль оештырылган фактурасы хәзерге музыка теленең иң мөһим компонентларыннан берсе булып тора һәм аны милли чыганаклар белән табигый рәвештә бәйли.

***Софийская Айгөл Борис кызы,***
*композитор, музыка белгече,*
*сәнгать фәннәре кандидаты*

## МУЗЫКА ТУРЫНДА БЕЗНЕҢ СОРАУЛАР[1]

### *«ЯҢАЛИФ» АНКЕТАСЫ*

**Татар музыкасы турында**

*1. Татар музыкасының специфик ягы нидән гыйбарәт дип уйлыйсыз?*

*2. Татар музыкасының специфик яклары «европалашу»га комачаулык итә дигән караш дөресме, түгелме?*

*3. Хәзерге көндә нотага салынган һәм Татар академия театрында уйналып килгән, шулай ук башка урыннарда, концертларда җырланган, уйналган иске көйләрнең социаль эчтәлегенә карашыгыз ничек? Анда халык музыкасын файдалану дөрес алып барыламы, дөрес булмаса, нинди бозулар һәм ялгышлар бар дип уйлыйсыз?*

*4. Музыкада яңа әсәрләрнең «европалашу» ягы ничек? «Европалашу»ны нидән гыйбарәт дип уйлыйсыз? «Европалашу» дигән сүз дөресме, дөрес булса, кай яктан һәм дөрес булмаса, ни өчен дөрес түгел?*

***Композитор Солтан Габәши***

***1 нче сорауга җавап:*** Татар музыкасының специфик аерымлыклары әле фән ягыннан тикшерелеп, кискен бер нәтиҗә чыгарылганы юк. Шунлыктан аның бу ягын бер формула рәвешендә билгеләү кыен.

[1] Музыка турында безнең сораулар // Яңалиф. 1931. № 3. Б. 59–60, 62–71; № 4. Б. 55–60; № 5–6. Б. 86–91. Әлеге текст кириллицага нигезләнгән татар алфавитында беренче тапкыр дөнья күрә.

Тик шуларны гына күрсәтергә мөмкин:

Беренче: татар музыкасы – татар көйләре – Европа халыкларының бүген кулланган җиде тавышлы (тонлы) гаммалардан корылмыйча, биш тавышлы кытай гаммаларына корылгандыр. Бу хәл, татар музыкасы белән танышкан бөтен музыка галимнәре тарафыннан бер нигез рәвешендәрәк танылып килсә дә, фәнни рәвештә киселеп исбат ителдеге юк. (Шулай да бу юлда эшләр башланган дияргә мөмкин.) Бу хакта узган ел Казан тарих һәм археология җәмгыятенең мәҗмугасындагы И.А. Козловның бер мәкаләсе чыкты һәм мин дә Татар культурасы йортында ясаган докладымда шуны исбат итәргә тырыштым. Ләкин бу татар музыкасының кытай гаммаларына корылуы – «татар музыкасының специфик бер сыйфаты», дип кисеп әйтү хәзергә читенрәк әле. Бәлки, тикшерүләр нәтиҗәсендә ул шулай да булып чыга, әмма хәзергә бу хәл татар музыкасының специфик эчке сыйфаты булудан бигрәк, аның үсү дәрәҗәсен – тарихи баскычын күрсәтә торган бер билге буларак тора. Чөнки, бер яктан, шул ук нигездә Кытай, Венгрия, Шотландия музыкалары булуы өстенә алардан мәдәниятләре (цивилизацияләре) түбән булган халыклар музыкалары да шул ук нигезгә корылган, хәтта урыс музыкасы да кайчандыр бер заманда шул нигездә булып, ул инде хәзер үскән.

Икенчедән, безнең музыкада да үсеш күренә. Мин үземнең докладымда алты тавышлы көйләр дә (соңрак заман көйләре) очраштыргалаганын әйтеп киткән идем.

Икенче аерымлыгы татар көйләренең тыңлаучыга бирә торган үзенә махсус тәэсирендә (аһәңендә). Бу аерым аһәң «көйләрне тәшкил иткән тавышлар» арасында интервалларның чиратлашуында – төзелү тәртибендә»[1] дип уйлыйм. Нинди интервал артыннан ниндие килүгә карап, көйнең аһәңе билгеләнә һәм татар көйләренең интерваллары төзелүдә ниндидер законлылык (закономерность[2])лар бар дип уйлыйм. Мисал өчен, Кавказ яки Кырым музыкаларының аерымлыгы ниндидер интервалның алдыннан яки артыннан зурайтылган секунда килүдән гыйбарәт булуы, музыка галимнәре теле белән әйткәндә, ул музыкаларның «характерный[3]» интерваллары зурайтылган секунда булуын күрсәтә. Дөрес, безнең музыкада андый күзгә бәленеп тора торган интерваллар күренми, шулай булса да, мин әнә шул кайсы интервал артыннан кайсы интервал килү яки интервалларның бөтен көйгә нисбәтән процентлары мәсьәләсе «татар көенең нигез мәсьәләсе» дип уйлыйм. Бу фикерне куәтләү өчен, шушы дәлилне китерәм: без җырчыларның җырлавын тыңлаган вакытта күп көйләрнең

[1] Укучылар арасында музыка карашыннан бөтенләй хәбәрсез кешеләр булуын истә тотып әйтәм: «Интервал дип ике тавыш арасында булган ярыклык атала. Янәшә ике тавыш арасы – секунда, бер тавыш аркылы икенче булса – терция, ике аркылы өченче булса – квинта, секста... септима, ниһаять, җиде аркылы сигезенче булса, октава дип атала». *(Автор иск.)*

[2] Бу сүз кириллицада бирелгән.

[3] Бу сүз кириллицада бирелгән.

татар яки башкорт көе булуларын һичбер фәнни нигезләргә мөрәҗәгать итмәстән аера алабыз. «Ни белән? Ни өчен? Ничек аерабыз?»– дип сорап, эзләнә башласак, башкорт көйләрендә зур сикерешләр (секста, октавалар) булып, татар көйләрендә аларның булмаганын – юклыгын күрәбез.

Менә бу мәсьәләгә соңгы вакытка хәтле һичкемнең игътибар иткәне һәм, бер генә кешенең дә булсын, тикшереп караганы юк. Тик узган ел гына Татар гыйльми тикшеренү институтының Музыка кабинеты бу мәсьәләгә игътибар итеп, аны эшләүне планына керткән һәм, беренче эш буларак, Прохоров тарафыннан бастырылып чыгарылган җиде көйгә анализ ясау өчен, Позниев дигән бер кешегә тапшырган иде. Ләкин ул эш рәтләп эшләнми, ахырында бер афера белән беткәнлектән, ул эш әле башланмаган килеш, бөтенләе белән үзенең эшчеләрен, үзенең тикшерүчеләрен көтә дияргә туры килә. Һәм шул эш үтәлеп беткәннән соң гына, татар көйләренең специфик сыйфатларын закон рәвешендә формалаштырып булыр дип уйлыйм.

Өченче аерымлык татар-башкорт көйләрендә көйне тәшкил иткән нигез тавышлар арасында көйне матурлый торган вак кушымта тавышларның күп булуында дип уйлыйм. Бу вак бизәкләр музыка телендә «мелизм» дип аталалар. Бу мелизмнар татар-башкорт көйләрендә чамадан тыш күп булып, чит халыклар аларны йә бөтенләй ишетми дә, йә ишетсәләр дә игътибар итмиләрме шунда, нәрсәдер бар. Ләкин шунысы бик ачык: башка милләттән булган музыкантлар татар көйләрен нота белән язарга тотынганда ул мелизмнар югала, бөтенләй язылмыйча төшеп калалар. Мисал өчен, мин һәркемгә мәгълүм булган «Җизнәкәй» көенең ике язылышын китерәм. Болардан беренчесе – 1891–1892 елларда Урал тирәсендә махсус экспедициядә йөреп, көйләр җыйган С.Г. Рыбаков язуы, икенчесе – минем язуым. Чагыштыру уңайлы булсын өчен, мин аларны өсле-аслы, янәшә ике юл иттереп китерәм.

Менә татар көйләренең бу аерымлыгын Виноградов кебек яшьтән татар массасы эчендә үсеп, аларны ишетергә өйрәнгән яисә, Литвинов кебек, абсолют ишетү куәсе булган кешеләр ишетәләр һәм аларга бик зур әһәмият бирәләр. Аларның әйтүенчә (фикеренчә), бу рәвештә көйне вак ноталар белән бизәкләү, ялгыз татар музыкасына гына хас булган специфик сыйфат булып, ул дөньяда башка һичбер халыкның музыкасында очрамый.

Дүртенче аерымлык татар көйләренең җырлану ысулында дип уйлыйм. (Бу аерымлык корал музыкасына бераз кагылса да, башлыча җыр хакында күрсәтелә.) Татар көйләре, төзелгән вакытта ук, шундый махсус бер төзелеш: махсус бер моң, аһәң белән төзелгәннәр ки, аларны шул халыкның үз эчендә туып үскән, үз кешеләре генә тулы һәм дөрес итеп үти ала. Дөрес, бу үтәүдәге аерымлыкның бу көнгә хәтле һичкем тарафыннан фәнни рәвештә тикшерелеп каралганы юк әле. Шуңар күрә без ул аерымлыкның нәрсәдә булуын һәм нәрсәсе белән башкалардан аерылып торуын кисеп әйтә алмыйбыз. Ләкин




шунысын өзеп әйтергә мөмкин: хәзерге көндә итальян ысулы буенча бирелеп килә торган нинди генә музыкаль тәрбия дә бу аерымлыкны бирә алырлык коралны укучыларга тапшыра алмый. Мин моңа дәлил итеп, Казанда техникум бетереп чыккан һәм ифрат яхшы тавышлы җырчылар булган Вәлиева, Байрашоваларның татар массасы тарафыннан үз җырчылары итеп кабул итәлә алмауларын күрсәтәм. Бәлки «алар урта белем генә алганнар шул, югары уку күрсәләр, алай булмас иде», диярләр. Аңар каршы мин иң югары укымышлы һәм иң югары осталар булган Нежданова, Собиновлар җырласа да, татар көйләрен Сөләйманова, Әлмөхәммәтовлар төсле үти алмаячаклар дип уйлыйм.

Әмма халыкның үзе эчендә туып, үсеп, аныңча җырлау техникасын яхшы өйрәнгән кешеләр музыка мәктәпләрендә (йә хосусый рәвештә) укып, итальян школасы буенча тавышларын куйсалар һәм шул школаның бирә торган җыр җырлау техникасына ия була алсалар, бу нәрсәләр татар көйләрен җырларга комачаулык итми генә түгел, бәлки аның тулылыгына, матурлыгына бик зур файда китерәләр. Бу хәлне без шул ук Әлмөхәммәтовлар, Айдаров, Рахманкулова, Садыйкова тәҗрибәләрендә ачык күрәбез.

Бишенче аерымлык татар көйләренең, гомумән алганда, рухлары[1] төшенке булуда дип уйлыйм. Безнең күп көйләребез, гомуммузыка карашы буенча, ирлек, батырлык, шатлык аңлатып торырга тиеш булган «мажор» тезмәсенә туры килеп торуларына карамастан, гади тел белән әйткәндә, елап, сыкрап торалар һәм рух төшенкелеге, изелгәнлек, зар-моңны аңлаталар. Хәтта иң шатлыклы моментны күрсәткән бию көйләрендә дә төбендә ниндидер бер мескенлек, бер урында таптанып тору сизелә. Алар арасында без русларның «Казачок-гопак»лары күк, шатыр-шатыр сикерә торган, очып-очып китә торган күчү (переход[2]), сикереш (скачок[3])лар күрмибез.

Көйләр арасыннан алга бару, хәрәкәтне бер дәрәҗә уяулык (бодрость) аңлата торганнары «бик аз» дип әйтсәк тә, ялгыш булмас дип уйлыйм. Бу сүзләр саф татар көйләре турында гына әйтелеп, башкорт көйләре йә башкорт тәэсирендә булган көйләр хакында туры килеп бетмиләр.

Көйләрнең мондый бер хәлдә булуларының сәбәбе – рус патшалыгына нисбәтән, сәяси коллык, социаль шәраит[4] һәм экономика ягыннан байлар, морзаларга коллык дәвереннән гыйбарәт булган соңгы йөз еллар эчендә чыккан көйләрнең генә сакланган булуларында дип уйлыйм. Чөнки музыка тарихы галәмендә закон хәлен алган бер караш буенча, халык музыкасының әсәрләре – халык көйләре бары бер йөз ел чамасы гына сакланып, яшәп, аннан соң алар йә үзгәрә, йә бөтенләй онытылалар.

Менә шуңар күрә татарның да сәяси мөстәкыйль хәлдә илдән-илгә яу белән күчеп йөргән заманнарында булырга тиешле гайрәтле, батыр, сугышчан көйләр сакланмастан онытылып, тик соңгы дәвер утрак хәлгә күчеп, югары әйткән социаль шәраит эчендәге көйләре генә сакланган булырга кирәк. Бу дәвердә инде яңа сугышчан гайрәтле көйләр тудырырлык зур баш күтәрү – бунт кебек массаны аякка бастырган, аның рухын күтәргән вакыйгалар булмаган, йә бик аз булганлыктан, ул рухта яңа көйләр төзелә алмаганнар булса кирәк.

***2 нче сорауга җавап:*** Бу сорауга җавап бирү өчен, элек «европалашу» дигән сүзнең мәгънәсен билгеләргә кирәк, шуның өчен бу сорауның җавабын мин дүртенче сорауга җаваплар рәтенә калдырам.

---

[1] Стиль мәгънәсендәрәк алына.
[2] Бу сүз кириллицада бирелгән.
[3] Бу сүз кириллицада бирелгән.
[4] Шәраит – шарт.

***3 нче сорауга җавап:*** Мин бу сорауның беренче кисәген: «Хәзерге көндә нотага салынган иске көйләрнең музыкаль эчтәлекләре хәзерге социаль шәраиткә яраклымы, түгелме?» дигән формада аңладым һәм шуңар карата җавап бирәм.

Нотага салынып, Татар дәүләт академия театрында уйналып килгән көйләрне ике төркемгә бүләргә кирәк.

Беренчесе – «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе», «Башмагым» кебек халык көйләре. Икенчесе – сәхнәдәге әсәрнең теләге буенча язылган яңа көйләр.

Болардан беренчеләренең арасында беркадәрләренең музыка эчтәлекләре хәзерге вакыт өчен ярарлык булса да, күбрәгенең эчтәлеге хәзерге үсеш-үзгәрешне аңлата һәм бирә алмыйлар, әлбәттә, бу шулай булмый хәле дә юк, чөнки алар моннан ун еллар гына түгел, хәтта йөз еллар элекке әхвал эчендә туган иске көйләр булып, шул заманның социаль шәраитларын һәм сәяси якларына карата төзелгәннәр.

Яңа көйләргә килсәк, боларның хәзерге сәяси яклар белән бәйләнешләре турыдан-туры булмыйча, сәхнәдә уйналган әсәрләр аркылы гына. Алар туры шул әсәрләргә буйсынып, аларның теләгенчә һәм күрсәтүенчә төзеләләр һәм шул әсәрдәге типларның социаль йөзләрен ачып салырга тырышалар. Аларга аерым бербөтен итеп карап, аларның аерым сәяси сыйфатларын күрсәтеп булмый. Чөнки әсәр нәрсә эшләргә кушса, алар шуны үтиләр. Димәк, аларга бөтенләй икенче үлчәү белән, әсәрләрнең теләгәнне бирә алулары үлчәвеннән карап бәя аерырга кирәк була. Менә бу яктан караганда, минем фикеремчә, «бу әсәрләрнең бик зур өлеше уңышлы» дип уйлыйм. Әлбәттә, арада бик үк уңышлы булмаганнары да булуы мөмкин. Ләкин мин аларны аерып күрсәтерлек (хәзер күземә бәрелеп торган берәвесеннән башкасын) хәтерләмим. Ул хәзер күзгә күренеп торган дигәнем «Наемщик» пьесасында крестьян яшьләре Гәрәй белән Зөбәрҗәтнең кара-каршы җырлаган сүзләрендә. Монда көйнең нигезенә мөнәҗәт көе, тагын да дөресрәге, «Әлбидаг» көе алынган. Боларның берсе мулла малае булып, икенчесе мулла кызы булса, аларны музыка белән сурәтләү өчен, ул көй бик кулайлы булыр иде. Ләкин алар икесе дә крестьян балалары – бу көй аларның социаль йөзләренә капма-каршы килә торган дини рухтагы көй булганлыктан, бу урынны уңышсыз дип санамый мөмкин түгел.

Инде шул ук бер әсәр эчендәге музыка парчалары ул әсәрдән аерылып кулланыла башласалар (мәсәлән, концертларда җырлана башласалар), үзенә сәяси бер бәя куелуны күтәрә ала башлау хәленә керәләр. Ләкин ул бәяне бирү өчен, аларны берәм-берәм тикшереп чыгып, һәркайсын үзенә аерым карарга туры килә. Гомуми генә бер карашка барысына бер сүз белән характеристика бирергә мөмкин түгел. Тик шуңарга гына тукталып китәргә мөмкин: беренчедән, бу парчалар турыдан-туры хәзерге әхвал, үсеш, алга баруларга карата язылган әйберләр булмаганлыктан, аларны 100% ы белән шул нәрсәләрне бирәләр, дип, бәхәс кылырга мөмкин дә түгел, һәм аларга карата андый сора-

уны кую да урынсыз булыр иде. Чөнки андый сорауны махсус шул теманы алып, шуның өчен эшләнгән әсәрләргә генә куярга мөмкин.

Икенче яктан, бу әсәрләр, һичшиксез, татар музыкасы культурасының үсешенә зур ярдәм итәләр. Аларны тоташ алдын-артын карамый куеп чыгару да ярамый.

Шунлыктан ул әйберләргә хәзергә «зарарлары бармы, юкмы?» ноктасыннан карап бәя куеп, зарар бирерлекләре булса, аларны алып ташлап, зарарлы булмаганнарын калдырырга кирәк. Алай эшләүдән куркырга да кирәкми дип уйлыйм. Чөнки музыканың үсеше алга барып, чын мәгънәсе белән хәзерге заманга яраклы көчле әйберләр арта барган саен алмаштыра барырга мөмкин булачак.

Шуның белән бергә, кулыбыздагы көйләрнең зарарлы-зарарсыз икәнлеген үлчи торган билгеле бер үлчәүнең булмавын да әйтеп китми хәл юк. Бу хәл бездә генә түгел, цивилизациянең иң югары баскычында тора торган рус музыкасында да шулай ук. Әле хәзерге көндә аларга да пролетариат музыкасын билгели торган аерымлыклар урнаштырылмаган булып, ул мәсьәлә кызу дискуссия чорын кичерә. Шулай да аларның кулында зарарлы икәнлеге урнаштырылган берничә форма бар. Мәсәлән, бердән, дини гыйбадәт (чиркәү музыкасы, ләкин дингә каршы язылган әсәрләрне музыка белән иллюстрировать иткәндә, алар бу чиркәү музыкасын нык файдаланалар), икенчедән, цыганщина, фокстротлар. Болардан беренчесе бездә дә табыла. Ягъни ул – бездә дә аерым бер музыкаль форма буларак яшәп килгән нәрсә. Шуңар күрә аны күрү, ишетү дә һәм аның зарарын да әйтү кыен түгел (һәм шулай ук руслардагыча алардан дингә каршы агитация эшендә файдалану да мөмкин дип уйлыйм). Икенче өлеше исә, әлбәттә, бездә юк, бездә чегән көйләре җырланмый һәм чегән көйләре генә түгел, гомумән, романслар, фәләннәр юк. Булса, булса «Абау Алла, Гайшәм», «Мамаҗан» кебек бер-ике әйбер бар. Әмма цыганщина урынына тора торган көйләр юк түгел. Ул да булса, соңрак заманнарда татар байлары һәм татар мещаннарының «күңел ачуларына» багышланып чыккан «Әйттер-типтер» көйләре. Ләкин бу көйләр, шул ук сыйныфның гегемониясе арасында булса кирәк, масса арасына да таралып, саф халык көйләре арасында буталып йөриләр. Мин бу хакта үземнең фикерне былтыргы Татар культурасы йортында ясаган докладымда әйтеп киткән идем. Менә бу көйләрне эзләп табып, халык музыкасы эченнән чыгарып, киләчәктә файдаланырга ярамый торган аерым бер төркем итеп билгеләп куярга кирәк. Бу – әле эшләнмәгән, алда эшләнәчәк эш. Ләкин аны татар музыкасы белән дә, тормышы белән дә, психологиясе белән дә, бигрәк тә аның узган көннәре, тарихы белән дә яхшы таныш кешеләр генә эшли алачаклар. Шунлыктан бу эштә Позниевлар, Прохоровлар кебек «этнограф»ларның, әлбәттә, бер тиенлек тә файдалары тимәячәк.

Халык музыкасыннан файдалану мәсьәләсенә килгәндә, яңа әсәрләр тудыру өчен, халык көйләрен нигез итеп файдалану ягыннан карасак, халык көйләреннән файдалану дөрес юлда бара дип уйлыйм.

Әмма шул ук халык көйләрен бөтен килеш алып, көйләрнең үзләрен үзгәртми, тик иске көйләргә яңа сүзләр, яңа җырлар җырлау ягыннан карасак, халык көйләреннән файдалану бик үк дөрес юлда тормый дип уйлыйм. Чөнки югарыда әйткәнчә, моннан күп элгәре заманнарда бөтенләй башка сәяси әхвал, башка социаль шартлар эчендә туган ил көйләренең аһәңнәре, хәзерге темп, үсеш-үзгәрешләрне аңлата алмый гына түгел, бәлки күп вакытта капма-каршы килеп тора торган булалар. Мисал өчен, шушы вакыйганы күрсәтим: бервакытта, бер кичә уздыру өчен, миннән хор төзеп бирүне үтенделәр. Җырлар өчен «Дошман изсә дә мин бирешмәм, каршы сугыш ачармын» мәфһүмендә[1] язылган гайрәт чәчеп торырга тиешле булган сүзләрне алып, аларны көйләр арасында иң төшенке рухлы минор настроениедә булган «Мәкәрҗә Гайсә» көенә салып җырламакчы булдылар. Менә мондый сүзләрнең эчтәлеге белән көйнең эчтәлеге арасындагы каршылыклар җырлана торган әйбернең һәм сүзләрнең һәм көйнең художество кыйммәтен киметкәнлектән, ул әйберләр теләгән максатта тулысы белән ирештерә алмыйлар. Менә шунлыктан бу юлны, нигездә, дөрес түгел дияргә туры килә. Ләкин заманга муафыйк яңа көйләребез булмаганлыктан, хәзергә кимчелекле булса да, без бу юл белән файдаланa торырга мәҗбүрбез.

***4 нче сорауга:*** «Европалашу» сүзен берничә төрле аңларга мөмкин.

1 – Татар халык көйләрен бөтенләй кулланудан чыгарып ташлап, архивка яки музейга тапшырып, алар урынына Европа халыклары (рус, немец, француз, итальяннарның ) музыкасын-көйләрен кабул итү.

2 – Татар көйләрен үстерү юлы белән аларны хәзерге 5 тавышлы гаммалардан чыгарып, 7 тавышлы Европа гаммалары нигезенә җиткерү.

3 – Татар көйләренең үзләрен үстерүгә әһәмият бирмичә, аларны хәзерге хәлләрендә генә алып барып, Европа халыкларының көйләре шикелле үк гармонияләштереп, мәдәни кием киертеп, интернациональ музыка эченә илтеп кую (бу өлештә татар көйләренең ватылмый-җимерелми бөтен килеш алынулары күздә тотыла).

4 – Татар көйләрен (бөтен килеш сакланулары шарт ителми, «кисәкләрен» генә дә алырга да ярый, яки аларны үзгәртергә дә мөмкин дигән белән бергә) нигез итеп алып, Европа музыкасында булган төсле, зур әсәрләр (соната, сюита, концерт, симфония һәм опералар) ясау.

5 – Рус, немец, француз композиторлары шикелле үк, татар композиторларының көй ягыннан һичбер шарт-шәраитсыз, үз башларыннан чыгарган көйләрдән генә, югарыда әйтелгәнчә, зур әсәрләр иҗат итүләре. Боларда, ягъни бу рәвешчә язылган әсәрләрдә, көйләрнең һичберсе турысында, татармы, урысмы йә башка халык көеме дигән

[1] Мәфһүмендә – эчтәлегендә.

сорау куелмастан, фәлән кешенең татар булуы гына шарт ителә, һәм шул авторның татар милләтеннән булганлыгы өчен генә ул әсәр татар музыкасы әсәрләреннән хисапланып йөртеләчәк.

Менә бу «европалашу»ның әллә ничә мәгънәсеннән 1, 5 нче мәгънәләрне алганда, татар көйләре европалашуга һич каршы килмиләр, 2–4 нче мәгънәләрен алганда, бераз каршы килергә дә мөмкин, ләкин гомуми кагыйдә буларак, каршы килмәскә тиешләр. Чөнки татар көйләре табигый үсешләре буенча 7 тавышлы гаммаларга барып чыксалар, аларның каршылык күрсәтә торган урыннары, сәбәпләре үзләреннән-үзләре югалачак. Яисә татар көйләренең кисәкләре генә алынып, аннан ары ихтыяри иҗатка килергә дә, алар европалашуга күнегергә тиешле булачаклар.

Инде 3 нче мәгънә, татар көйләрен Европа гармония карашы буенча мотлак гармонияләштерү мәгънәсен алсак, татар көйләре «европалаштыруга» каршы калергә тиеш дип улыйм. Чөнки 5 тавышлы гына көйгә 7 тавыш нигезендә төзелгән гармония катлаулы тавыш (созвучие[1])ларын китереп ябыштыра башласак, көйнең үзендә булмаган, көйдән артык, көйдән тыш булган ике чит тавыш килеп керергә тиеш булганын һәркем аңласа кирәк. Бу ике чит тавышның килеп керүе көйне, бигрәк тә аның аһәңен бозмый мөмкин түгел дип уйлыйм. Гармониядәге катлаулы тавыш шуңар күрә (өч тавыш – аккордлардан) көйдә булган 5 тавышны эченә алып та, чит тавышларны эченә алмаганнары гына татар көйләрен гармонияләштерер өчен ярап, калганнары ярамаска тиешләр дип уйлыйм. Шуның белән бергә шуны да әйтергә кирәк: бәлки, әлеге тавышларны эченә алган аккордлардан да кайберләре кайбер урыннарда ярап та куя алырлар. Ләкин аларны әле без белмибез. Аларны эзләп табу – әлбәттә, озак заманнар эчендә, күп тикшерү йә тәҗрибәләр сорый торган зур бер эш. Аны киләчәк буын, югары укымышлы яшь галимнәр – теоретикларыбыз эзләп табып, мәгълүм бер кануннар – законнар хәленә куя алырлар һәм шул вакытта ул законнар гомуми интернациональ музыка гыйльме нигезенә нигезләнгән «татар көйләрен гармонияләштерү юллары» дигән сыманрак бер исем белән аерым бер теория караш шәкеленә килербез. Менә шушы эш эшләнеп беткәннән соң гына, татар көйләрен башка халыклардагы кебек матур, тулы, ләкин көйләрнең асыл рухын югалтмаган рәвештә, гармонияләштереп, аларны чын мәгънәсе белән формасы ягыннан националь, эчтәлеге – рухы ягыннан интернациональ булган бер хәлгә кую мөмкин булачак дип уйлыйм.

Хәзерге көндә бу юл консерваториянең этнография факультетын бетерә торган яшь көчләребездән Мозаффаровның шушы юлда эзләнүләре һәм берничә уңышлы нәтиҗәләргә ирешүе безгә мәгълүм һәм мин бу хәлне үземнең «5 тавышлы көйләр өчен нинди дер яңа, шул ук 5 тавышлы гармония ысулы да булырга тиеш» дигән фикеремнең дөреслегенә бик зур дәлил дип уйлыйм.

[1] Бу сүз кириллицада бирелгән.

Инде 4 нче сорауның 3 нче кисәгенә җавап буларак, «европалашу» сүзе Европада яшәгән культуралы халыкларның юнанлылар дәвереннән башлап, гасырлар буенча эшләнеп һәм җыйналып килгән техника байлыкларыннан файдаланып, көйләребез, музыкаларыбызны культуралы халыкларның музыкалары җитешкән баскычка җиткерү, шулар белән бер калыпка, бер формага салу мәгънәсе белән алганда, дөрес булса да, бөтен ул байлыкның буржуа байлыгы, ул музыканың буржуа галәме өчен, аның идеологиясенә хезмәт иткәнлеген искә алсак, бу сүз дөрес түгел! Әгәр инде Европа буржуазиясенең кулында булган, соңгы заман музыкасының махсус рәвештә пролетариатка каршы, аны исертү, йоклату, яисә аны һичбер эш эшли алмаслык апатик хәлгә китерү өчен кулланыла торган «фокстрот», «танго»лар хәлендә дә булуына игътибар итсәк, кайбер явыз ниятле типларның «европалашу» сүзеннән файдаланып, безгә дә шул «фокстрот», «танго»лар формасын кертеп җибәрүгә азапланулары мөмкинлеген искә алсак, һәм кайбер кешеләрнең үлчәүсез, исәпсез рәвештә «европалашу» белән кызыксынып, үзләре дә сизмәстән, шул юлга төшүләре мөмкинлеген күз алдына китерсәк, бу сүзнең дөрес булмавы гына түгел, бәлки аны «зарарлы» дип карарга тиеш дип саныйм. Бездән бик күп югары торган рус музыка галәменең буржуа музыка культура мирасларыннан туп-туры гына файдаланырга ярамаганын билгеләп, «цыганщина», «фокстрот»ларга каршы көрәш ачып та, иске культура мирасын пролетариат идеологиясе һәм психологиясе торышыннан чыгып карап, үзгәртеп (эшләп) файдалану юлларын эзләргә керешүе һәм шул рәвешчә үзенә башка бер аерым тора торган пролетариат музыкасының формаларын табарга тырышу минем бу фикеремнең дөрес булуын күрсәтә дип уйлыйм.

Шуңар күрә мин «европалашу» урынына «культуралашу» сүзен алуны кулайлы күрәм.

Сораудагы беренче җөмләгә килгәндә, музыкада яңа әсәрләрнең бик күбесендә, әлеге «культуралашу» мәгънәсе белән алганда, «европалашу» бар. Сәйдәшев әсәрләренең оркестр белән уйналуы, минем татар көйләремнең күп тавышлы хор белән җырлануы, дуэт, квартет, трио кебекләрнең мәйданга чыгуы һәм Әлмөхәмметов, һәм Виноградовларның берничә халык көен гармонияләштереп бастырулары һәм башка төрле хезмәтләр бар да диярлек культуралашуның билгеләре булып торалар. Ә симфонияләр, опералар кебек зур әсәрләр хакында сөйләп торасы да юк. Аларда татар музыкасында сирәк очрый торган интервал – кечкенә секундаларны кертү һәм көйләрне урыны-урыны белән табигый тавышка җиткерү өстенә хәтта ясалма тавышлар белән октавада 12 тавыш буенча рәттән бара торган «хроматизм»ларга кадәр барып җитү дә бар. «Эшче»нең кайбер җирләрендә бу «хроматизм» оркестрда гына калмый, ул хәтта җырга да кушыла. Ләкин әле бу яңалыклар бер юл алып, билгеле бер формага кермәгәннәр. Алар киләчәктә юл эзләнү, тәҗрибәләр ясап карау хәлендә генә баралар. Билгеле, алар арасында уңышлы гыналары булган кебек,

уңышсызлары да булуы мөмкин. Алда аларның уңышсызлары төшеп калып, уңышлыларыннан билгеле бер юл салынып, алга китәчәк дип уйлыйм. Билгеле, бу юл сызу эше җиңел эш түгел. Моның өчен күп вакыт, күп хезмәт, күп көч куярга һәм күп тәҗрибәләр эшләргә кирәк. Бу эшләр ике юл белән: беренчесе – гыйльми-фәнни һәм иҗади көчләрнең юл сызып караулары, план төзүләре рәвешендә эшләнсә, икенчесе – шул сызган юлларның кайсын алу, кайсын үзләштерү һәм беркетү эше. Киң пролетариат массасының үз хиссияте, үз фикере тәҗрибәләрдән кайсын кабул итеп, кайсын ташлап калдыруны үзе хәл кылыр дип уйлыйм.

*(Дәвамы бар)*

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге*
*фәнни хезмәткәре* ***Фәйзуллина Фәния Галимулла кызы***
*әзерләде*

УДК 39

***Ф.Ф. Мәрданова***

## БЕРЕНЧЕ ТАТАР ЭТНОГРАФЫ

Статья посвящена изучению деятельности этнографа М.С. Губайдуллиной, которая активно занималась исследованием материальной и духовной культуры татар. Деятельность этнографов 1920-х гг., в частности М.С. Губайдуллиной, не являлась объектом специальных исследований, что подтверждает актуальность заявленной темы. При написании статьи были использованы материалы, архивные материалы, делопроизводственные документы Северо-Восточного археологического и этнографического института, Восточной академии, Центрального музея ТАССР и т. п. На основе изучения деятельности М.С. Губайдуллиной делается вывод о том, что она стояла у истоков организации высшего специального этнографического образования в республике, проделала значительную работу по собиранию и популяризации полевых материалов по этнографии поволжских татар. Большинство ее работ являлись первыми исследованиями в татарской национальной этнографии 1920-х гг. и послужили базой для дальнейших изысканий.

**Ключевые слова:** Марьям Губайдуллина, этнограф, 1920-е годы, татарская национальная этнография, высшее этнографическое образование, экспедиция, научная и преподавательская деятельность.

The article is devoted to the study of the activities of the ethnographer M.S. Gubaidullina, who was actively engaged in the study of the material and spiritual culture of the Tatars. The activity of ethnographers of the 1920s, in particular M.S. Gubaidullina, was not the object of special research, which confirms the relevance of the stated topic. There were used the materials as the memoirs of the ethnographer's relatives, archival materials, office documents of the North-Eastern Archaeological and Ethnographic Institute, the Eastern Academy, the Central Museum of the TASSR, etc. Based on the M.S. Gubaidullina's research we can make conclusion that she stood at the origins of the organization of higher specialized ethnographic education in the republic, did a significant job of collecting and popularizing field material of the Volga Tatars on the ethnography. Most of her works were the first studies in the Tatar national ethnography of the 1920s and were served as the basis for further research.

**Keywords.** Maryam Gubaidullina, ethnographer, 1920s, Tatar national ethnography, higher ethnographic education, expedition, scientific and teaching activities.

XX гасырның 20 нче еллары татар милли этнографиясе үсешендә мөһим этап булып тора. Бу чорда Идел буеның күп кенә автономияле республикаларында, шул исәптән ТАССРда, җирле халыкларның тарихын, матди һәм рухи мәдәниятен өйрәнүне максат итеп куйган фәнни җәмгыятьләр – Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте (1923), Татарстанны өйрәнү җәмгыяте (1928) барлыкка килә. 1920 елда Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография институтының Этнография бүлеге беренче киң профильле этнограф белгечләр әзерләп


Мәрьям Гобәйдуллина

чыгара. 1925 елда, республиканың социаль фәннәр үсешенә йомгак ясаганда, этнография өлкәсендә ныклы эш алып барылуы, нигездә, К.Н. Воробьев[1], Мәрьям һәм Кадыйр Гобәйдуллинарның актив эшчәнлеге ассызыклана[2].

Әлеге мәкалә кысаларында Мәрьям Салих кызы Гобәйдуллинаның фәнни эшчәнлегенә күзәтү ясалачак. Ул – татарлар арасында этнограф белгечлеге буенча югары белем алган беренче хатын-кыз [Губайдуллин, 2002, с. 22–27]. 1892 елда Казан сәүдәгәре Салих Сабит улы Гобәйдуллин гаиләсендә туа. Укырга-язарга остазбикәдән өйрәнә. Тиздән өлкән абыйлары Газиз[3] һәм Кадыйрга[4] ияреп, чит телләрне, аерым алганда, немец, француз, грек һәм латин телләрен дә үзләштерә башлый. 8 сыйныфны тәмамлап, чыгарылыш имтиханнарын уңышлы гына тапшырганнан соң, хатын-кызлар гимназиясенә укырга керә [Губайдуллин, 2002, с. 23]. Моннан тыш, ул фортепьяно классы буенча музыкаль белем ала [Губайдуллин, 2002, с. 27].

1917 елда Казанда Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография институты ачыла. Ул Идел буенда махсус этнографик белем бирүче бердәнбер уку йорты санала [ТР ДА. 1339 ф. Р., 1 тасв., 39 эш, 61 б.]. М.С. Гобәйдуллина берьюлы институтның Көнчыгыш һәм Этнография бүлекләрендә белем ала [ТР ДА. 1339 ф. Р., 1 тасв., 41 эш, 9 б.].

Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография институтының укытучылар составы М.С. Гобәйдуллинаны белемле, сәләтле һәм кызыксынучан студент кыз буларак бәяли [ТР ДА. 1339 ф. Р., 1 тасв., 3 эш, 134 б.]. Ул Идел-Кама төбәгенең төрле районнарына институт советы тарафыннан оештырылган экспедицияләрдә актив катнаша [Леонтьева, с. 58]. Фәнни сәфәрләр – җирле халыкның этнографиясен, антропология, география, археология, сәнгать, тарих һәм көнкүрешен өйрәнү максатыннан уздырыла [ТР ДА. 1339 ф. Р., 1 тасв., 39 эш, 62 б.]. Әлеге экспедицияләрдә җыелган этнографик коллекцияләр ТАССР Дәүләт музее фондларына тапшырыла.

Экспедиция нәтиҗәләре буенча уздырылган «фәнни җыелышлар»ның [ТР ДА. 1339 ф. Р., 1 тасв., 39 эш, 65 б.] берсендә М.С. Гобәйдуллина татар-мөселманнарда шаманчылык калдыклары турында чыгыш ясый [Леонтьева, с. 58]. Ул үзенең фәнни эше кы-

саларында Казан татарларының традицион диннәрендәге мәҗүсилек элементларын өйрәнә [ТР ДА, 1339 ф. Р., 1 тасв., 41 эш, 3 б.]. Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте утырышында аның әлеге темага чыгыш ясарга тиеш булганлыгы билгеле. Этнографиянең башка мәсьәләләреннән М.С. Гобәйдуллина Казан татарларының туй йолаларын өйрәнү һәм аларны тасвирлау белән шөгыльләнә [ТР ДА, 1339 ф. Р., 1 тасв., 41 эш, 4 б.].

1920 елның октябрендә институт Советы аны Көнчыгыш этнографиясе кафедрасында калдырырга карар кыла. Шунда әзерлек узгач, аның профессор дәрәҗәсен алу өчен диссертация яклавы күздә тотыла. М.С. Гобәйдуллинаның фәнни җитәкчесе итеп профессор С.Е. Малов билгеләнә. Ә шушы гыйльми дәрәҗәне алуга әзерләнгәндә өйрәнү өчен кирәкле төп һәм өстәмә фәннәрне барлау Н.Ф. Катановка йөкләнә [ТР ДА, 1339 ф. Р., 1 тасв., 3 эш, 134 б.].

Басылып чыккан фольклор материалларын өйрәнүдән тыш, М.С. Гобәйдуллинага Казан татарларының халык авыз иҗаты үрнәкләрен җыю, теркәү һәм аларны рус теленә тәрҗемә итү эше дә тапшырыла. Бу юнәлештә алып барылган эш нәтиҗәләре «Еллык хисапта» чагылыш табырга тиеш була [ТР ДА, 1339 ф. Р., 1 тасв., 41 эш, 4 б.]. Моннан тыш, профессор Н.Ф. Катанов М.С. Гобәйдуллинаны институтның нумизматика кабинеты консерваторы вазифасына тәкъдим итә. Ул рус, көнчыгыш һәм көнбатыш тәңкәләрен, медальләрен өйрәнү һәм тасвирлау белән шөгыльләнә [ТР ДА, 1339 ф. Р., 1 тасв., 41 эш, 2 б.].

1920 елның декабрендә Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография институты Көнчыгыш академиясенә үзгәртелә [ТР ДА, 225 ф. Р., 1 тасв., 10 эш, 1 б.]. Соңгысына Көнчыгышны төрле яктан өйрәнү һәм мәдәният өлкәсендә кадрлар әзерләү бурычы куела. 1921 елдан М.С. Гобәйдуллина академиядә төрек-татар кабиләләренең этнографиясе [ТР ДА, 225 ф. Р., 1 тасв., 10 эш, 4 б.], соңрак Казан татарлары этнографиясе буенча лекцияләр укый [ТР ДА, 225 ф. Р., 1 тасв., 10 эш, 22 б.].

1922 елда Көнчыгыш академиясе Көнчыгыш педагогика институты составына керә. Җирле халыкларның мәдәнияте, теле һәм әдәбияты, этнографиясе буенча укытучылар әзерләү максатыннан, институтта Көнчыгышны өйрәнү бүлеге ачыла. Әлеге бүлек эчендә татар һәм чуваш милли-лингвистик, музыкаль-этнография бүлекчәләре булдырыла. 1924–1925 елларда М.С. Гобәйдуллина әлеге бүлекнең төрки-татар секциясендә төрки-татар кабиләләренең этнологиясен укыта [ТР ДА, 1487 ф.Р., 1 тасв., 50 эш, 82 б.]. 1925 елның октябрендә Көнчыгышны өйрәнү бүлеге «Татар халкының этнографиясе» курсларын кертү турындагы тәкъдим белән чыга. Әлеге уку курсының лекторы итеп М.С. Гобәйдуллина билгеләнә. Параллель рәвештә ул чуваш милли-лингвистика бүлекчәсендә төрек-татар кабиләләренең этнографиясе буенча лекцияләр укый [ТР ДА, 1487 ф. Р., 1 тасв., 50 эш, 151 б.].

Кайбер мәгълүматларга караганда, М.С. Гобәйдуллина беренчеләрдән булып «Казан татарлары этнографиясе» дигән лекцияләр курсын эзерли [Галиуллина, с. 208]. Әмма әлегә лекция материалларын эзләү тиешле нәтиҗәләр бирмәде.

М.С. Гобәйдуллина 1920 елда ук Көнчыгыш халыклары музеен оештыру комиссиясе составына керә һәм Көнчыгыш халыклары мәдәниятенә багышланган күргәзмәне әзерләүдә актив катнашучыларның берсе була. Күргәзмә Казанда 1920 елның 23 сентябрендә ачыла һәм бу чара Көнчыгыш халыклары музеен ачу проектын гамәлгә ашыруның беренче этабы булып тора [Шараф, с. 7]. Күргәзмәдә болгар, татар, кытай, мөселман Көнчыгышы, Идел буе һәм Себер халыклары, нумизматика, Көнчыгыш кульязмалары һәм китаплары бүлекләреннән торган бай коллекция тәкъдим ителә [Шараф, с. 8].

Татар халкының көнкүреше һәм мәдәнияте бүлеген әзерләү яшь этнографлар М.С. Гобәйдуллина һәм К.С. Гобәйдуллинга йөкләнә. Экспозициядә татарларның бик бай декоратив-гамәли сәнгате: милли кием, зәркән бизәнү әйберләре, чигү үрнәкләре һ.б. белән танышырга мөмкин була. Соңрак күргәзмәнең каталогы басылып чыга[5]. Каталогка күргәзмәнең М.С. Гобәйдуллина һәм К.С. Гобәйдуллин әзерләгән татар бүлеге тасвирламасы да кертелгән[6]. Анда татарлар зур 3 төркемгә – Себер, Европа һәм Кавказ төркемнәренә бүлеп каралган. Казан татарлары, Әстерхан һәм Кырым татарлары белән берлектә, Европа төркеменә кертелгән. Әлеге этник төркемнең матди һәм рухи мәдәниятен тасвирлауга аерым игътибар бирелгән. Тасвирламада Казан татарларының кием ансамбле, бизәнү әйберләре, һөнәрчелеге, хуҗалыгы, гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре турында кыскача мәгълүмат урын алган.

Күргәзмә зур уңышка ирешә: аны карарга 10 меңнән артык кеше килә. Оештыру комиссиясе экспонатларны тәкъдим итү вакытын 1921 елның гыйнвар уртасына кадәр озайту турында карар кабул итә [Шараф, с. 8–9]. Әмма 1920 елда төзелгән Көнчыгыш халыклары музее ябылу сәбәпле, әлеге чара үз эшен туктатырга мәҗбүр була. Күргәзмә өчен җыелган берничә мең экспонат 1922 елда Татарстан Республикасы Үзәк музее фондларын (хәзерге вакытта – Татарстан Республикасы Милли музее) тулыландыра.

1925 елда республиканың Үзәк музеенда этнография бүлеге ачыла. Этнографик экспозицияне системалы рәвештә туплаганда татар халкының мәдәниятен һәм көнкүрешен чагылдыручы материалларга аерым басым ясала. Бүлекнең экспозицияләрен республиканың танылган этнографлары – музей директоры Н.И. Воробьев, музейның тарих-археология бүлеге мөдире К.С. Гобәйдуллин, шулай ук М.С. Гобәйдуллина әзерли.

Үзәк музей фондларын һәрвакыт тулыландырып тору өчен, татарлар күпләп яши торган урыннарга даими рәвештә фәнни экспедицияләр оештырыла. Мәсәлән, 1925 елда Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте[7] әгъзалары Н.И. Воробьев, М.С. Гобәйдуллина, К.С. Гобәй-

дуллин һәм С.Г. Вахитов Мамадыш кантонына сәфәргә чыгалар. Экспедиция кантонны этнографик, археологик һәм тарихи яктан тикшерү өчен оештырыла[8]. Фәнни экспедиция вакытында М.С. Гобәйдуллина тарафыннан ясалган төп күзәтүләр Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте әгъзаларының гомуми җыелышында бәян ителә[9]. Сәфәр вакытында җыелган этнографик материаллар Мәрьям һәм Кадыйр Гобәйдуллиннарның «Пища казанских татар»[10] дип аталган уртак хезмәтенең нигезенә ята. Әлеге мәкалә татар халкының аш-су традицияләрен яктыртучы беренче фәнни хезмәт булып тора[11]. Ислам кануннарына бәйле туклану үзенчәлекләрен, йола һәм бәйрәм вакытында әзерләнә торган ризыкларны, аш-суга бәйле төрле тыюларны өйрәнүгә аерым игътибар бирелә. Авторлар билгеләп үткәнчә, бу мәсьәлә аерым тикшеренү таләп итә, чөнки татарларның рухи тормышында аш-су мөһим роль уйный[12].

1925 елда М.С. Гобәйдуллина бертуган абыйсы Г.С. Гобәйдуллин янына Бакуга күчә. Бу чорда инде ул Идел буе татарларының көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә, аш-суына багышланган күп кенә фәнни мәкаләләр авторы булып тора[13]. Аның хезмәтләре фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан тиешенчә бәяләнеп, хәтта Италиядә дә басылып чыга [Губайдуллина, с. 141]. Фән өлкәсендәге зур казанышлары өчен М.С. Гобәйдуллинага доцент исеме бирелә. Ул Баку педагогия институтында укыта башлый [Губайдуллина, с. 142], актив фәнни-тикшеренү эшләре алып бара: Азәрбайҗан төрекләре этнографиясе буенча хезмәтләр бастыра[14].

М.С. Гобәйдуллина 1933 елда Бакуда вафат була. Галимә кыска гына гомере эчендә татар халкының матди һәм рухи мәдәниятен өйрәнүдә яңа юнәлешләр ача. Моннан тыш, ул 10 ел дәвамында актив мөгаллимлек эшчәнлеге алып бара, республикада югары махсус этнографик белем бирүне оештыручыларның берсе була. Идел буе татарларының мәдәниятен һәм көнкүрешен өйрәнү белән шөгыльләнүче киң профильле тикшеренүче-этнографларны әзерләүдә үзеннән зур өлеш кертә.

М.С. Гобәйдуллина – этнографик материалны җыю һәм популярлаштыру буенча күп хезмәт куйган галимә. Ул фәнни экспедицияләрдә, шулай ук күргәзмәләр, музей экспозицияләре әзерләүдә катнаша. Фәнни сәфәрләр вакытында җыелган материаллар Идел буе татарлары этнографиясе буенча күпсанлы мәкаләләренең нигезенә салынган. Күпчелек хезмәтләре исә 1920 еллар татар милли этнографиясендә беренче тикшеренүләр санала һәм алга таба эзләнүләр өчен җитди чыганак булып тора.

**Искәрмәләр**

[1] Константин Иосифович Воробьев – Ленинград дәүләт университетының география факультеты студенты. Бертуган абыйсы – танылган этнограф Н.И. Воробьев – җитәкчелегендә күп кенә фәнни экспедицияләрдә катнаша. Ул Казан татарларының һәм мишәрләрнең традицион ышануларын өйрәнә. 1929 елда «Программа для собирания сведений о духах-хозяевах: домовом, дворовом

и усадебном у казанских татар и мишарей» дип аталган хезмәте нәшер ителә. Программа халык демонологиясен комплекслы өйрәнүне күздә тота. Билгеләп үтик: әлеге программа мондый төр тикшеренүләр арасында беренче. Рус фольклористикасында мондый тикшеренүләр Н.И. Толстой җитәкчелегендәге Мәскәү этнолингвистик мәктәбендә XX гасырның 80 нче елларында гына башлана.

[2] *Губайдуллин Г.* Что сделано в области социальных наук в Татарской республике в течение 5 лет // За 5 лет. К V годовщине провозглашения Татарской социалистической советской республики. Казань. 1925. С. 172.

[3] Газиз Салих улы Гобәйдуллин (1887–1937) – тарихчы, тарих фәннәре докторы (1927), профессор (1927), җәмәгать эшлеклесе, публицист.

[4] Габделкадыйр Салих улы Гобәйдуллин (1888–1944) – этнограф. Шәкертләрнең «Әлислах» хәрәкәтендә катнаша. 1921–1925 елларда Көнчыгыш китаплар музее китапханәчесе, Көнчыгыш академия, Көнчыгыш педагогика институты мөгаллиме, ТАССР Үзәк музееның тарих-археология бүлеге мөдире булып эшли. 1925–1938 елларда Бакуда, Махачкалада педагогик һәм музей эшендә катнаша. Фәнни хезмәтләре Казан татарларының аш-су традицияләрен, X гасыр Болгар тәңкәләрен тикшерүгә багышланган. 1938 елда репрессияләнә. Үлгәннән соң аклана.

[5] Выставка культуры народов Востока. Путеводитель по выставке. Казань: Первая гос. тип., 1920. С. 38–43.

[6] *Губайдуллин К.С., Губайдуллина М.С.* Татары // Выставка культуры народов Востока. Путеводитель по выставке. Казань: Первая гос. тип., 1920. С. 33–37.

[7] Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте (Научное общество татароведения) 1923 елда татар халкының мәдәниятен һәм тарихын өйрәнү максатыннан ТАССР Мәгариф халык комиссариатының Гыйльми үзәге каршында оештырыла. М.С. Гобәйдуллина әлеге җәмгыятьнең әгъзасы булып тора һәм аның эшчәнлегендә актив катнаша.

[8] Историко-этнографическая поездка в Мамадышский кантон ТССР // Вестник научного Общества татароведения. 1926. № 4. С. 93–94.

[9] Обзор деятельности Научного общества татароведения (1923–1929) // Вестник Научного общества татароведения. 1930. № 9–10. С. 203.

[10] *Губайдуллин К.С., Губайдуллина М.С.* Пища казанских татар // Вестник Научного общества татароведения. 1927. № 6. С. 17–50.

[11] Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М.: Наука, 1967. С. 33.

[12] *Губайдуллин К.С., Губайдуллина М.С.* Пища казанских татар // Вестник Научного общества татароведения. 1927. № 6. С. 25

[13] *Губайдуллин К.С., Губайдуллина М.С.* Татары // Выставка культуры народов Востока. Путеводитель по выставке. Казань: Первая гос. тип., 1920. С. 33–37; *Губайдуллина М.С.* Коллекция М. Галеева // Казанский музейный вестник. 1921. № 1–2. С. 84–87; *Губайдуллин К.С., Губайдуллина М.С.* Пища казанских татар // Вестник Научного общества татароведения. 1927. № 6. С. 17–50.

[14] *Губайдуллина М.С.* Пища азербайджанских тюрок // Изв. Вост. факультета Азерб. гос. ун-та. Востоковедение. 1928. Т. 3.

## Әдәбият

*Галиуллина Д.М.* Губайдуллина Марьям Салиховна // Татарская энциклопедия. Казань: Инст. тат. энцик., 2005. Т. 2. С. 208.

*Губайдуллин С.Г.* Дорогие мои предки // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2003. № 1/2. С. 214–219.

*Губайдуллин С.Г.* Незабвенный мой отец // Газиз Губайдуллин: научно-библиографический сборник. Казань: Рухият, 2002. С. 17–62.

*Губайдуллина А.Х.* Наша дорогая Марьям апа // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2002. № 1/2. С. 139–145.

*Леонтьева А.М.* К истории высшего специального этнографического образования // Советская этнография. 1978. № 2. С. 53–62.

*ТР Дәүләт архивы.* Төньяк-көнчыгыш археология һәм этнография институты фонды. 1339 ф. Р., 1 тасв., 3 эш; 39 эш; 41 эш.

*ТР Дәүләт архивы.* Көнчыгыш академиясе фонды. Көнчыгыш академиясенең профессорлар һәм укытучылар исемлеге (1921–1922). 225 ф. Р., 1 тасв., 10 эш. *ТР Дәүләт архивы.* Татар дәүләт педагогика институты (Көнчыгыш педагогика институты (1922 елдан) фонды. 1487 ф.Р., 1 тасв., 50 эш.

*Шараф Г.Ш.* История возникновения выставки // Выставка культуры народов Востока. Путеводитель по выставке. Казань: Первая гос. тип., 1920. 138 с.

***Мәрданова Филүзә Фәннур кызы,***
*Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендәге инновацияләр*
*һәм традицияләр саклау ресурс үзәгенең матди булмаган*
*мәдәни мирас бүлеге мөдире*

УДК 821.512.145, 82:801.6

***Н.М. Юсупова***

## ТУКАЙ ФӘНЕНДӘ ЯҢА ОФЫКЛАР

Статья посвящена изучению материалов к хронике жизни и творчества Габдуллы Тукая, его вклада в развитие тукаеведения. В ходе исследования утверждается, что издание показывает биографию и творчество Г. Тукая как открытый текст, обладающий множественностью смыслов. В нем значительное место отводится изучению окружения Г. Тукая и новых фактов из жизни поэта, выявлению закономерностей развития не только творчества поэта, эволюцию взглядов поэта, этапов становления и развития его как личности, но и татарской литературно-критической и общественно-философской мысли в целом. В статье выявляется, что в данном издании многочисленные факты жизни и творчества поэта оцениваются в контексте социальных и культурных реалий начала XX века, что расширяет представления как о творчестве и биографии Тукая, так и о культуре и жизни татар.

**Ключевые слова**: Габдулла Тукай, хроника, поэт, журналист, Уральск, Казань.

The article is devoted to the study of materials for the chronicle of the life and work of Gabdulla Tukai, his contribution to the development of Tukai studies. In the course of the study, it is argued that the publication shows the biography and work of G.Tukai as an open text with a multiplicity of meanings. In it a significant place is given to the study of G.Tukai’s environment and new facts from the poet’s life, to identify the patterns of development not only of the poet’s creativity, the evolution of the poet’s views, the stages of his formation and development as a person, but also Tatar literary-critical and socio-philosophical thought in general. The article reveals that in this publication numerous facts of the poet’s life and work are evaluated in the context of the social and cultural realities of the early twentieth century, which expands the understanding of both the work and biography of Tukai and the culture and life of the Tatars.

**Keywords:** Gabdulla Tukai, chronicle, poet, journalist, Uralsk, Kazan.

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның шәхесе, иҗаты һәрдаим фәнни һәм әдәби җәмәгатьчелекнең күз уңында. Бу табигый да, чөнки Тукайга булган мөнәсәбәт татар милләтенең үзбилгеләнүендә, яшәешендә мөһим роль уйный, Тукай шәхесе, аның иҗаты татар халкы тарихының, әдәби һәм мәдәни үсешенең ачык энциклопедиясе булып тора. Дөрес, шагыйрьнең иҗат хроникасы, шигъриятенең төп сыйфатлары, милли әдәбиятка йогынтысы, әдәбият тарихында, тәнкыйтендә тоткан урыны XX гасыр дәвамында, һәр чорның үз стереотиплары нигезендә, фәнни нигездә тикшерелгән, бәяләнгән. Ләкин XXI гасыр башында татар әдәби-эстетик һәм әдәби фикерендәге яңарыш, гыйльми офыкларның киңәюе-төрләнүе шагыйрь иҗатын өйрәнүнең яңа перспективаларын ачып, тагын бер кат барлау,

моңа кадәр күләгәдә калып, күренми яткан катламнарны табу-бәяләү, тикшерелми, бәяләнми калган яки берьяклырак өйрәнелгән күренешләргә, фактларга яңача карау кирәклеген көн тәртибенә куйды. Соңгы елларда Тукай энциклопедиясенең дөнья күрүе дә Тукай феноменын гыйльми өйрәнүләрне киң җирлектә алып баруның матур бер нәтиҗәсе булды. 2021 елда эшләнеп, киң фәнни даирәгә тәкъдим ителгән өч томлы «Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар» басмасы да әлеге киң колачлы фәнни эзләнүләрнең дәвамы булып кабул ителә.

Тукайга кагылышлы архив чыганакларын, газета һәм журнал язмаларын, рәсми документларны, төрле чорларда формалашкан фәнни карашларны, истәлекләрне бер бәйләмгә туплаган әлеге басма, беренче чиратта, Габдулла Тукай иҗатын киңкырлы яктыртуы, аның тормыш һәм иҗат биографиясенә кагылышлы материалларны баетуы, шагыйрь мирасын аңлауда тирәк булырлык күп кенә ачышлары, аның шәхесенә һәм иҗатына тирән бәя бирүе белән кыйммәтле. Моңа кадәр киң катлау укучыларга билгеле булмаган байтак кына материалларның табылуы һәм фәнни әйләнешкә кертеп җибәрелүе дә игътибарга лаек.

Икенчедән, басмада урын алган фактларның, мәгълүматларның күптөрлелеге шагыйрь яшәгән, иҗат иткән чорны күз алдына бастырырга, әдәби-мәдәни һәм иҗтимагый мохитне аңларга-тоярга, милли-мәдәни яшәешкә бәйле бик күп урыннарны күрергә мөмкинлек бирә. Шуның белән ул XX гасыр башында татарның яшәеше, мәдәни үсеше, мохите хакындагы күзаллауларны, фикер-карашларны да киңәйтеп җибәрә. Әлеге эзләнүләр шул чорда ук милли аң үсешенең дә югары биеклеккә ирешүен тагын бер кат төгәлләштереп куя. Бу эзләнүләрнең Тукай шәхесенә, ул яшәгән чорга, аралашкан даирәгә бәйле, күбесе моңа кадәр киң җәмәгатьчелеккә билгесез фоторәсемнәр белән баетылуы да зур әһәмияткә ия.

Өченчедән, әлеге басма, вакыйгаларны, фактларны шәрехләүләрдән китеп, хронологик, документаль тикшеренү юлын сайлый, шуның нәтиҗәсендә шагыйрьнең тормыш юлын һәм иҗади үсеш баскычларын эзлекле, дәвамлы төстә, бөтен итеп күз алдына бастыра. Басманың татар һәм рус телләрендә дөнья күрүе дә отышлы. Бу исә Тукай тормышына һәм иҗатына кагылышлы байтак материалларны киң даирәгә алып чыгу, укучылар аудиториясен киңәйтү мөмкинлеге бирә.

Дүртенчедән, әлеге басмада шагыйрь шәхесенә, аның тормыш һәм иҗат юлына бәйле калыплашкан фикерләр яки фәнни ориентирлар шактый үзгәрә. Сер түгел, татар фәне өчен Тукай шәхесен идеаллаштыру хас. Бу басма исә шагыйрь иҗатындагы, тормышындагы моңа кадәр берьяклы гына бәяләнеп килгән бик күп фактларга яңача карарга җирлек тудыра, формалашкан бәя-мөнәсәбәтләрне өстәмә мәгълүматлар белән баета. Озак еллар дәвамында бәяләү бизмәне булып хезмәт иткән «җәдитчеләр-кадимчеләр», «идеаль-камил

булмаган», «дус-дошман» бүленешләреннән китеп, басма авторлары «вакыйгаларны бизәмичә», документларга нигезләнеп, һәр якның уңай һәм тискәре якларын аерып куеп, объектив бәя бирү юлын сайлый. Шуңа да басмада урын алган һәр кеше, һәр төбәк Тукайның Шагыйрь һәм Шәхес булып формалашуына, камилләшүенә билгеле бер өлеш кертүче булып күз алдына бастырыла.

Томлыкның беренче кисәге Тукайның Казан арты һәм Җаек белән бәйле тормыш, иҗат биографиясенә кагылышлы материалларны бергә туплый. Тукайның шушы төбәкләргә бәйле аралашу тирәлеге, татар эшлеклеләре, сәүдәгәрләре, меценатлары тормышына һәм эшчәнлегенә бәйле мәгълүматлар да яктыртыла. «Тукай һәм Казан арты» дип исемләнгән беренче бүлектә шагыйрь тормышының 1886–1894 еллар белән бәйле вакыйгалары туплана. Кушлавыч, Өчиле, Сасна, Кырлай авылларына бәйле балачак фактларын туплау юлында З. Рәмиев һәм Г. Ханнанова, күпсанлы архив документларына һәм истәлекләргә таянып, шагыйрьнең балачагы турындагы мәгълүматларны баета. Әйтик, шагыйрьнең этисе Мөхәммәдгарифның көнитеше, холкы-сыйфатлары бик тулы тасвирлана, бабасы Зиннәтулланың киң карашлы шәхес булуы бәян ителә, шагыйрь үскән гаилә тарихы тулысынча тергезелә. Шуның белән янәшәдә Казан арты төбәге, Кушлавыч, Кырлай авыллары тарихына бәйле бай тарихи мәгълүматлар ачыла, алар аркылы бәләкәй Апуш яшәгән чорның яшәеше, көнитеше дә күз алдына бастырыла.

Томлыкның «Тукай Уральскида» дип исемләнгән икенче бүлеге Тукай тормышының дистә елдан артык вакыты белән бәйле Җаек чорын (1894–1907) яктырта. Бу бүлектә Мотыйгулла хәзрәтнең Тукайлар гаиләсе белән бәйләнешләре этрафлы тасвирлана, шагыйрьнең шәхес булып формалашуында зур роль уйнаган җизнәсе Галиәсгар Госманов гаиләсе турында яңа мәгълүматлар туплана. М. Ибраһимов, Ә. Алиева, Н. Насыйбуллина язмалары аркылы Тукайның шагыйрь буларак формалашуы күз алдына бастырыла, Җаек мәдәни мохитенең, татар даирәсенең, мәдрәсәдә һәм рус классында уку елларының шушы процесска керткән өлеше тәгаенләнә.

Бу бүлекнең тагын ике зур әһәмиятен ассызыклап китү кирәк: бер яктан, укучы өчен Җаекның барлыкка килүе, тарихы, шул чор милли-мәдәни яшәеше хакында искиткеч бай мәгълүматлар ачыла. Шушы фонда төбәкнең алгарышында татарларның ролен тәгаенләү, төгәлләштерү кызыл җеп булып бара һәм һәр фикер истәлекләр, архив документлары белән дәлилләнә. Ә бит татарлар бу төбәктәге яшәешне алга җибәрүдә гаять зур роль уйнаган, казакъ халкының мәдәниләшүенә, алгарышына Мортаза Гобәйдуллин, Хәйрулла Гаделшин, Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин кебек татар зыялыларының, сәүдәгәрләренең, татар дин әһелләренең эшчәнлеге көчле этәргеч биргән.

Икенчедән, Җаекның күп кенә шәхесләренә, шул исәптән җизнәсе Галиәсгар Госмановка Тукайның карашы бертөрле генә булмавы

да билгеле. Шуңа да озак еллар дәвамында шагыйрьнең язмаларын, шигырьләрен укып үскән татар укучысында әлеге шәхесләргә яки вакыйга-фактларга карата берьяклы караш формалашып килде. Бу бүлек объектив бәя һәм архив документлары аша шул карашларны да үзгәртә, калыплашкан фикер-мөнәсәбәтләрнең үзгәрүенә китерә. Алай гына да түгел, әлеге шәхесләрне өр-яңа яктан ачып, Тукайның шагыйрь һәм шәхес буларак формалашуына яки татарның алгарышына зур өлеш керткән шәхесләр буларак тәкъдим итә.

Габдулла Тукай Җаектан Казанга журналист буларак та формалашып кайта. Шуңа мөнәсәбәттә Г. Ханнанова, З. Рәмиев мәкаләләрендә аның «Әлгасрелҗәдит», «Уклар» журналлары, «Фикер» газетасы белән бәйле эшчәнлеге дә яктыртыла. Әлеге тикшеренү нәтиҗәләре Тукайның журналист буларак карашлары формалашуның нигезләрен ачыклый. Үз чиратында алар бу басмалар тарихына кагылышлы байтак мәгълүматлар белән дә таныштыра, аларның ачылуына һәм эшчәнлегенә бәйле таныш булмаган фактларны күтәрә.

Р. Харрасованың язылган Тукайның Җаек чоры иҗатына бәйле язмасы аерым бүлекчә кебек тәкъдим ителә. Ул шагыйрьнең бу чор иҗатына заман нәзари һәм әдәби фикере югарылыгыннан бәя бирүе, аны төрле әзерлектәге татарларга йөз тотып язылган шигърият буларак ачуы, бу чор әсәрләрендәге поэтик алымнарны, иҗади принципларны, структур үзенчәлекләрне аерып чыгаруы, аларны халык авыз иҗаты, Көнчыгыш, суфичылык, рус һәм Көнбатыш әдәбиятлары фонында яктыртуы белән әһәмиятле, актуаль. Әлеге язма аркылы укучы беренче чор иҗатында ук Тукайны шигырь теориясен, язу техникасын тирән дәрәҗәдә белгән, Шәрык һәм Гареб әдәбияты белән яхшы таныш, үзфикерле шагыйрь буларак ача. Булачак шагыйрьгә Мотыйгулла хәзрәтнең дә шигырь төзелеше буенча дәресләр бирүе, Габделвәли Әмрулланың төрек һәм, гомумән, Гареб әдәбияты турында мәгълүмат бирүе билгеле. Моннан тыш Тукай актив рәвештә тәрҗемә белән шөгыльләнгән, ул татар укучысына Пушкин, Лермонтов, Кольцов, Байков, Плещеев иҗатларын татар телендә укырга мөмкинлек тудырган. Үз чиратында бу әдипләрнең иҗаты аның үз шигъриятенә дә көчле йогынты ясаган.

Басманың икенче һәм өченче томнары 1907 елның ахырыннан алып 1913 елга кадәр дәвам иткән Казан чорын яктыртуга йөз тота. Тукайның Казан чоры иҗаты һәм эшчәнлеге, тормышы фонында ул аралашкан даирә, әдәбият һәм сәнгать әһелләре, иҗтимагый-сәяси эшлеклеләр, сәүдәгәр-меценатлар, шагыйрьнең сәяхәтләре турында да бай мәгълүматлар урнаштырыла. Архив чыганаклары, хатлар, көндәлекләр, истәлекләр, журнал һәм газета мәкаләләре, төрле рәсми документлар шул заманның милли-мәдәни мохитен тергезергә мөмкинлек бирә.

З. Рәмиев, Л. Надыршина, Г. Ханнанова, Г. Төхфәтова мәкаләләре, Тукайның Казандагы әдәби иҗтимагый, журналистлык эшчәнлеген бәяләү барышында, аның аерым шәхесләр белән

мөнәсәбәтләрен яктырта. Шушы фонда шагыйрьнең тормышында аеруча зур роль уйнаган Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, Г. Камал, В. Бәхтияров, С. Сүнчәләй, Ә. Хәсәни белән бәйләнешләре аерып чыгарыла. Бу язмалар, шагыйрьнең даирәсен генә түгел, әдип, җәмәгать эшлеклесе һәм кеше буларак, Тукайның үзен дә яңа яктан ача, шактый каршылыклы һәм катлаулы шәхес буларак бәяли. Шунысы мөһим: һәр язмада һәрбер фикер һәм факт дәлилләнә, сәбәпләре һәм нәтиҗәләре күрсәтелә.

Икенче һәм өченче томнарда аерым бүлекләр шагыйрьнең Казан вакытлы матбугатындагы эшчәнлеген яктырта. «Әлислах», «Яшен», «Ялт-йолт», «Аң» басмалары белән бәйле язмалар аркылы Тукайның журналист буларак камилләшү баскычлары, иҗтимагый карашлары формалашу һәм ныгу этаплары билгеләнә, ул кыю сүзле, үткен фикерле, тәнкыйди карашлы журналист буларак ачыла. Ф. Фәйзуллина, Э. Галимҗанова, Л.Надыршина язмаларында шагыйрьнең әлеге басмалар үсешенә керткән өлеше тәгаенләнеп кенә калмый, ул басмаларның үзләре хакында да бай мәгълүмат туплана, шуңа да алар татар журналистикасы тарихының да елъязмасы кебек кабул ителә.

Казанда Тукай белән бәйле урыннар тарихы, шагыйрьнең сәяхәтләренә бәйле язмалар аерым әһәмияткә ия. Г. Төхфәтова, Н. Таиров, Э. Сәлахова, Ә. Алиева, И. Заһидуллин мәкаләләре аша укучы Казан, Әстерхан, Уфа, Санкт-Петербург, Троицк шәһәрләре белән таныша. Алар өч яклы бәя бирүе белән кызыклы: бер яктан, Тукайның ул сәяхәтләргә бәйле үз фикерләре урын ала, икенче яктан, ул сәяхәтләргә өлеш керткән шәхесләрнең истәлекләре яңартыла, өченч яктан, галимнәрнең үз бәясе дә сизелә. Бу исә әлеге сәяхәтләр фонында Тукай шәхесенең яңа якларын калкытып куярга яки ачарга мөмкинлек бирә.

Тукайның Казан чоры иҗатына бәя Л. Надыршина тарафыннан бирелә. Тукайның бу чор шигъриятендәге үсеш этапларын һәм тенденцияләрен, иҗат принципларының, алымнарының үсеш-үзгәрешен тикшергән-бәяләгән, аны рус, Көнбатыш һәм Көнчыгыш әдәби традицияләре яктылыгында өйрәнгән мәкалә фәнни масштаблыгы белән аерылып тора. Биредә Тукай үзфикерле, тормыш-яшәешне яңа концептуаль нигездә бәяли алырлык, милли төсмерле, үз йөзе булган әдип, XX гасыр татар поэзиясенең умыртка баганасын тәшкил иткән Шагыйрь буларак ачыла.

Н. Насыйбуллина (1 том), Г. Ханнанова (2, 3 томнар) тарафыннан әзерләнгән һәм һәр томлыкта урын алган кушымталар аерым әһәмияткә ия. Бөртекләп җыюны таләп иткән әлеге фактик мәгълүматлар аша укучы Г. Тукайның Җаек һәм Казан чорларында иҗат ителгән әсәрләр исемлеге белән таныша ала. Әсәрләр хронологик тәртиптә урнаштырылган, һәрберсенең язылу һәм басылу вакыты, урыны турында төгәл мәгълүмат бирелә. Бу тикшеренүчеләр, әдәбият галимнәре өчен бәһасез зур хезмәт булып тора.

Шулай итеп, Тукай шәхесен киң һәм масштаблы, күпьяклы ачуга юнәлтелгән, һәртөрле идеологик кысалардан арындырылган һәм мөмкин кадәр объективлыкка омтылган бу басма һәркемгә «үз Тукаен» ачарга мөмкинлек бирә. Моңа кадәр дөнья күргән хезмәтләрне өстәмә баетуы, Тукайга бәйле фактларны бер бәйләмгә туплавы, укучыларга әдип иҗатын һәм тормыш хроникасын өйрәнү юлларын һәм мөмкинлекләрен тәкъдим итүе белән әлеге хезмәт фәнни даирәдә генә түгел, татар укучылары арасында киң таралыр һәм өстәл китабына әверелер дип ышанабыз.

***Юсупова Нурфия Марс кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф Югары мәктәбенең*
*татар әдәбияты кафедрасы профессоры*

# *СУЛТАНОВА Р.Р.* ШКОЛА МАСТЕРОВ: ХУДОЖЕСТВЕННОЕ ОБРАЗОВАНИЕ В СФЕРЕ СЦЕНОГРАФИИ В КАЗАНИ (Казань: Татар. кн. изд-во, 2021. 280, с. ил.) китабына бәяләмә

Казан – гаҗәеп бай театр традицияләренә ия шәһәр. Аларның юл башы XVIII гасыр урталарына ук барып тоташа. Россия күләмендә зур шөһрәт казанган сәхнә осталары белән беррәттән, рәссамнар да театр сәнгатенә үз өлешләрен кертте. XIX гасыр дәвамында тарих аларның да исемнәрен саклады. XIX–XX гасырлар чиге – театр сәнгате аеруча гөрләп чәчәк аткан чор. Көмеш гасырда бөтен мәдәният театральләштерелә: күпсанлы опера һәм драма антрепризлары гына түгел, мәктәп һәм өй спектакльләре, әдәби-нәфис, костюмлы баллар-кичәләр, «тере картиналар» постановкалары. Боларның барысын да Казан тормышында күпләп күзәтергә мөмкин була. Моннан тыш, 1910–1920 елларда Казанда яңа театр иҗат коллективлары, шул исәптән әйдәп баручы рәссамнар хезмәттәшлек иткән милли татар коллективлары барлыкка килә. Бу башка сәнгать дисциплиналары арасында сценографиянең мөстәкыйль дисциплина буларак укытыла башлавына уңай йогынты ясый.

Моңарчы Казанда сценография өлкәсендә укытуны тулы һәм эзлекле өйрәнүче булмады һәм ул башкаланың сәнгать педагогикасы тарихындагы ак тапларның берсен тәшкил итә иде. Р.Р. Солтанованың «Школа мастеров: художественное образование в сфере сценографии в Казани» (Казань: Татарское книжное издательство, 2021) китабы нәшер ителү әлеге бушлыкны тутырды, бу өлкәдә алга таба да тирәнтен тикшеренүләр уздыруга алшартлар тудырды. Бу басманы автор Казан сәнгать училищесына – 125, Казан театр училищесына 100 ел тулу уңаеннан әзерләде. Китап авторы – сәнгать фәннәре докторы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Д. Сираҗиев исемендәге (2008), Б. Урманче исемендәге (2012), «Театраль роман» (2020) премияләре лауреаты Рауза Солтанова. Ул милли театр сәнгате тарихы буенча язылган күпсанлы монографияләре («Празат Исанбет. Грани призвания», «Сценография татарского театра: основные этапы и закономерности развития», «История татарского театра в плакатном искусстве»), мәкаләләре белән дә билгеле галимә.

Аның яңа тикшеренүе Татарстан Республикасы Милли архивы материаллары, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры һәм В.И. Качалов исемендәге Казан зур драма театры музей фондларына, уку йортлары һәм шәхси архивларның методик фондлары коллекцияләренә, үзенең чордашлары – рәссамнар һәм укытучылар белән шәхси аралашу тәҗрибәсенә нигезләнә. Тикшерелә торган материалның үзенчәлеге иллюстратив материалның күләмле булуын таләп итә. Китаптагы архивтан алынган һәм заманча фотосурәтләр,

декорацияләр эскизлары, макетлар, костюм, сәхнә гримы, бутафория предметлары эскизлары текстның эчтәлеген тагын да баетып кына калмый, бәлки текстка параллель, мөстәкыйль тикшеренү материалы да булып тора, аларның күбесе беренче тапкыр бастырыла.

Китапның структурасы аермачык: ул Н.И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесына (9–142 битләр) һәм Казан театр училищесына (143–254 битләр) багышланган ике бүлектән тора; алар рәссамнарның сүзлеге (255–266 битләр) белән тулыландырылган; кушымтада (267–275 битләр) Казан сәнгать училищесы укытучысы, сәнгать фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Татьяна Николаевна Кривошеева һәм гримёр-рәссам, Казан театр училищесы педагогы Ирина Александровна Григорьянц истәлекләре бирелгән. Анда шулай ук «Сравнение учебных планов общепрофессиональных и специальных дисциплин 1920-х гг. и современного периода» дип исемләнгән чагыштырма схема да (274–275 битләр) китерелә, ул уку-укыту процессындагы методик характердагы үзгәрешләрне ачык күзалларга мөмкинлек бирә. Тулаем алганда, шул рәвешле китапның исемендә үк әйтелгән җанлы һәм күп планлы картина туа.

Беренче бүлектәге «История и перспективы развития» һәм «Современность» очеркларында Казан сәнгать мәктәбе һәм аның варисы булган Казан сәнгать училищесындагы әйдәп баручы педагогларның иҗади эшчәнлекләре аша сәхнә сәнгатенең барлыкка килүенә күзәтү ясала, 1910–2010 елларда укучыларның театрдагы практик эшкә ни рәвешле җәлеп ителүе күрсәтелә. Сәхнә бизәлешенә (сценографиягә) нигез салган П.П. Беньков, Н.И. Фешин, П.Т. Сперанский, Б.И. Урманче һәм бу өлкәдә үзләреннән зур өлеш керткән Ә.И. Тумашев, К.А. Нәфыйков, А.С. Иванцев, Г.С. Скоморохов кебек рәссамнарның иҗат портретлары ачыла. Китап авторы училищедагы театр-декорация бүлегенең уку планнарын һәм программаларын анализлый, укытучылар һәм студентларның дәүләт заказларын үтәүдә катнашуын, турыдан-туры театр цехларында һәм остаханәләрдә кулланылган производство практикалары программаларын күрсәтә. «Студентлар әзерләүдә күппланлылык, – дип билгеләп үтә китап авторы, – теоретик һәм практик дисциплиналарны колачлый, студентларга алга таба үзләренең иҗади потенциалларын һәм алынган күнекмәләрен театрда гына түгел, ә полиграфиядә дә, телевидениедә дә, дизайн һәм рекламада да гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә». «Күбрәк театр-декорация сәнгате, – дип ассызыклый галимә, – рәсем режиссурасы буларак аңлашыла». Ул укытуга да, студентка да аерым таләпләр куя. Күпсанлы иллюстрацияләр – студентлар тарафыннан эшләнгән эскизлар сценография өлкәсендәге стиль үзгәрешләрен аеруча ачык чагылдыра. Аларны эзләү, авторлыкны атрибуцияләү һәм кабат бастырып чыгару – тикшеренүченең зур казанышы. Татар театр техникумыннан (1922) башлангыч алган Казан театр училищесының тарихы әле тиешенчә өйрәнелмәгән: аның ябылган, башка уку йортларына кушылган, үзгәртеп оештырылган вакытлары да булган.

Басма авторының сәнгать бүлеге тарихын торгызу бурычын куюы да укучыларда зур кызыксыну уята. Аның тарихы шулай ук күренекле рәссамнар һәм сәхнә эшлеклеләре белән бәйле (П.П. Беньков, П.Т. Сперанский, В.А. Никитин, Р.М. Хибатуллин, Л.А. Потягунин, В.В. Попов, Т.А. Зуев).

Төрле аспект һәм күнекмәләрне берләштермичә генә, театрда сәнгати образ тудырып булмый. Бу – уку программасында костюмерлар, бутафорлар, гримёрлар һәм сәнгать дисциплиналары (рәсем, нәкыш һәм композиция) арасында предметара бәйләнешләр булдыруны күз алдында тота. Автор гади һәм аңлаешлы формада укучыга уку-укыту эшенең төрле нечкәлекләрен һәм кыенлыкларын җиткерә.

«Бүгенге көндә, – дип ассызыклый автор, – республикадагы барлык театрлар иҗат составының яртысыннан артыгын училищены тәмамлаучылар тәшкил итә» (148 бит). Республиканың сәнгати мәдәниятендә уку йортының роле шуның белән билгеләнә дә.

Бербөтен гармонияле китап образын тудыруда ачык төсләргә бай дизайнның да (авторы – Н.И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесын тәмамлаган А.И. Гыйльметдинова) роле зур. Һәр бүлек үзенчәлекле архитектоникасы белән аерылып тора. Игътибарны җәлеп итү өчен, отышлы график алым эшләнгән, график элементлар яңа мәгълүматны җиңел кабул итәргә ярдәм итә.

Фәнни-популяр басма жанрында язылган китап киң катлау укучыларга адресланган, һәм, һичшиксез, белгечләр өчен дә, театр сөючеләр өчен дә бердәй кызыклы булачак. Үзенчәлекле версткасы, стандарт булмаган форматы һәм төсле иллюстрацияләрнең күплеге белән китап бүләк басмага да дәгъва итә ала.

***Ключевская Екатерина Петровна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

# *АБДУЛЛИНА Ч.З., СӘГЪДИЕВА Ф.К.* ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТЕЛ ВӘЗГЫЯТЕ: ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ДАИРӘСЕ (Казан, 2021. 136 б.) китабына бәяләмә

Хезмәтнең авторлары – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе аспирантура бүлеге җитәкчесе Ч.З. Абдуллина, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми тел белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Ф.К. Сәгъдиева. Фәнни редакторы – филология фәннәре докторы, профессор, академик М.З. Зәкиев, бәяләүчеләре – филология фәннәре докторы, профессор Л.К. Бәйрәмова, филология фәннәре докторы, профессор И.Б. Бәширова.

Монография керештән, ике бүлектән, кулланылган әдәбият исемлеге, йомгак һәм кушымта өлешләрдән тора.

Керештә күпмилләтле Татарстан Республикасында хәзерге вакытта тел ситуациясенең катлаулылыгы, җәмгыятьтә барган иҗтимагый-сәяси хәлләргә нисбәтән, аның симметриясез икетеллелек юнәлешен алуы, дәүләт тарафыннан тормышка ашырылырга тиешлеге кебек мәсьәләләрне яңача яктырту зарурлыгы ассызыклана. Хезмәттәге «Без хәзер дәүләт теле статусындагы тел турында түгел, ә туган тел / ана теле турында сүз алып барабыз» дигән фикер гаять актуаль һәм мөһим, күпчелек сәясәтчеләребезнең әлеге мәсьәләне күтәргәннәре юк, татар сөйләмә һәм язма телләренең вазифаларын аермыйча, гомумиләштереп кенә сөйлиләр. Аңлашылганча, авторлар, 90 нчы еллардагы кебек, татарларның рус телен ни дәрәҗәдә белүләрен өйрәнүне түгел, бәлки үз ана телләрен, әдәбиятын, мәдәниятен белүләрен тикшерүне максат итеп куялар. Туган телне саклап калу һәм үстерүнең генә милли каршылыкларның кискенләшмәвенә дә нигез булачагы раслана. Шулай итеп, әлеге монографиядә күтәрелгән теманың тел һәм җәмгыять бәйләнеш-мөнәсәбәтендә, милли телнең рәсми һәм фактик статусы дип карап, авторлар билдергәнчә, социолингвистика фәне категорияләре, термин һәм методысуллары белән өйрәнелүенә басым ясала. Хезмәтнең максаты, бурычы, фәнни яңалыгы, теоретик һәм гамәли әһәмияте, актуальлеге билгеләнә (б. 4–7).

Беренче һәм икенче бүлекләрдә Татарстан Республикасында хәзерге тел ситуациясен өйрәнү, икетеллелек һәм күптеллелек шартларында татар теленең функциональ үсешенең заманча юнәлешләрен, үзенчәлекләрен билгеләү, 90 нчы елларда башланган милли сәясәт һәм тел сәясәте өлкәсендә барган үзгәрешләрнең нәтиҗәсен күрсәтү һәм соңгы елларда хасил булган ситуацияне бәяләү уңаеннан мөһим мәсьәләләрне җентекләп анализлау күз уңында тотыла.

Беренче бүлектә тикшеренүнең теоретик һәм практик аспекты 3 параграфка бүлеп өйрәнелә. 1 нче параграф тема итеп күтәрелгән төп проблеманы аңлау өчен тәрәк булган «тел ситуациясе» төшенчә / атамасының табигатен һәм вазифасын яктыртуга багышлана. Әлеге максатка ирешү өчен, тарихи аспектта «тел ситуациясе» төшенчәсе турында гомуми мәгълүмат бирелә (б. 9–13), күптөрле фәнни хезмәтләрдә ничек анализлануы нигезендә тел ситуациясен бәяләүнең үз парадигмалары күзаллана, төп факторлары билгеләнә, яңа карашлар булуы искәртелә (б. 14–18). Башка фикерләр дә бар дип, әлеге терминның кулланылышы / вазифасы тәгаенләнә: «Тел сәясәте – телнең функциональ мөмкинлекләрен үстерүне җайга сала торган төп факторларның берсе», – дип, бу мәсьәлә игътибар үзәгенә куела. Авторлар: «Татарстан Республикасында хәзерге чордагы тел ситуациясен билгеләгәндә, аның тарихтагы нинди вакыйгалар җирлегендә калыплашуын һәм алга таба нинди юнәлештә хәрәкәт итәргә мөмкин булуын фаразлау да әһәмиятле дип таптык», – дип язып, тикшеренүнең реаль, объектив чынбарлыкта булган вакыйгаларга нигезләнеп алып барылуын аңлаталар (б. 8–9). Хезмәттә, тарихи нигез дигәндә, 1926 елдан соңгы вакыт аралыгы күздә тотыла. Билгеле булганча, 1918 елдан башлап гарәп графикасындагы китаплар дини әдәбият дип яндырыла, туздырыла. 30 нчы еллардан системалы рәвештә телне юкка чыгару эше башлана: ике мәртәбә графика алмашына, укыту рус теленә күчерелә, аннан соң ТР яшәүче халыкларның саны 1959, 1989, 2010 елларда үткәрелгән җан исәбен алу нәтиҗәләре (рәсми күрсәткечләргә нигезләнеп), ана теленең ни дәрәҗәдә кулланылышта булуы һ.б. мәсьәләләр таблицада күрсәтелә. 2010 елда татарларның ана телен белү / белмәвенең рус телен белү / белмәвеннән соң куелуының гайре табигый булуы ассызыклана (б. 21–25). «Татар теленең саклanышына аны күпме чит милләт вәкиле үзләштерү исәбеннән чыгып түгел, ә татар халкының күпмесе аны белүе, иҗтимагый тормышта куллануы һәм аңа ихтыяҗ сизү ягыннан карау кирәктер», – дигән фикер куандыра.

Шулай итеп, «тел ситуациясе» төшенчәсе телнең үз системасына, җәмгыять системасына, кешеләрнең яшәеш системасына караган катлаулы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр нигезендә яктыртыла һәм боларның һәркайсына авторларның мөнәсәбәте белдерелә. Рус телендә бирелгән өзекләрнең татарчага тәрҗемәләре бирелә. Авторларның тел белеменә караган фәнни төшенчәләрне бик яхшы белүләре һәм иркен кулланулары күренә (б. 19–25). Хезмәтнең фәнни-теоретик һәм практик аспекты гыйльми хезмәт таләбе дәрәҗәсендә хәл ителә.

Беренче бүлекнең 2 нче параграфында, «Татарстан Республикасында тел сәясәте һәм милләтара мөнәсәбәтләр» проблемасы өйрәнелә. Бу очракта да, мәсьәләнең асылына төшенү өчен, «заман расизмы» («современный расизм»), «мәдәни расизм» («культурный расизм») кебек төшенчәләрнең барлыкка килүе, анализлануы аңлатыла. Һәм түбәндәгечә нәтиҗә ясала: «...милли-мәдәни аерымлык-

лар һәм тел аерымлыклары яшәгән дәүләтләрдә милли сәясәт һәм тел сәясәте аерым халыкларның язмышын хәл итүче төп сәясәт булып тора. Тел сәясәте иң элек дәүләт тарафыннан тудырыла һәм көйләнә» (б. 26). Алга таба әлеге сәясәтнең Татарстан Республикасында ни рәвешле җайга салынуы, күпсанлы фактик материалга нигезләнеп, җентекләп анализлана. Әлеге эшчәнлекнең кайчан башлануы, нинди декрет-карарлар кабул ителү турында мәгълүмат бирелә, «2014–2021 елларда татар халкының милли тәңгәнлеген саклау турында» һәм «2023–2030 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү, үстерү» программалары нигезендә безнең күз алдында барган вакыйгалар күзаллана: китапханәләр, милли бәйрәмнәр, вакытлы матбугат, радио һ.б. чаралар Татарстанда яшәүче халыкларның хокукларын саклап уздырыла. «Тел сәясәте дәүләт сәясәтенә буйсына. ...Утыз ел дәвамында татар теленең дәүләт теле буларак статусын күтәрү буенча гаять зур эш эшләнде, шулай да татар теле, дәүләт теле буларак, рәсми аралашу теле югарылыгына күтәрелә алмады», – дип, объектив нәтиҗә ясала. Әлеге күренешнең сәбәпләрен аерым галимнәрнең ничек итеп аңлатуы күзаллана, төрле модельләр санала, яңа мәгълүмат бирелә. Тел ситуациясе дигәндә, аның рәсми һәм фактик статусы булу истә тотылырга тиешлек, Татарстанда берьяклы милли-рус икетеллелеге хөкем сөрә дип, чынбарлыкта булганча раслана (б. 30–43).

Беренче бүлекнең 3 нче параграфында Татарстан Республикасында татар һәм рус телләренең кулланылыш (сорашу нәтиҗәләре буенча) мәсьәләсе игътибар үзәгенә куела. Бу сорашуларның төп максаты – яшүсмерләрнең һәм урта буынның татар телен белү дәрәҗәсен һәм аңа булган мөнәсәбәтен ачыклау дип бирелә һәм, асылда, түбәндәге сорауларга җавап көтелә: 1) Сез Татарстандагы дәүләт телләрен ни дәрәҗәдә беләсез? 2) Бала вакытта гаиләдә нинди телдә аралаштыгыз? 3) Балалар бакчасында нинди телдә аралаштыгыз? 4) Мәктәптә кайсы телдә белем алдыгыз? 5) Хәзер татар телен нинди даирәдә, кайда кулланасыз: а) гаиләдә, ә) күршеләр, ә) дуслар, б) хезмәттәшләр белән аралашканда, г) җәмәгать урыннарында. 6) Рухи ихтыяҗларны канәгатьләндерүдә нинди телгә өстенлек бирәсез: а) китаплар укыганда, ә) вакытлы матбугат белән танышканда, б) радио һәм телевидение тапшыруларын тыңлаганда һәм караганда, в) интернеттан кирәкле материалларны эзләгәндә, г) хат язганда. 7) Балаларыгызның Татарстандагы дәүләт телләрен белүен мөһим дип саныйсызмы? Иҗтимагый тормышның төрле өлкәләренә карата да шундый сораулар формалаштырыла һәм татар һәм рус милләте вәкилләренең әлеге сорауларга җаваплары төрле төстәге схемаларда % лап күрсәтелә. «Сорашу нәтиҗәсендә тупланган күрсәткечләр яшь буынның телгә булган мөнәсәбәтендә туган теле булган татар теленә өстенлек бирмәвен күрсәтә»,– дип, объектив-дөрес фикер әйтелә (б. 44–58).

Икенче бүлектә Татарстан Республикасында татар теленең кулланылыш мохите турында сүз бара. Алдагы бүлектәге кебек үк, аерым проблемалар өйрәнелә башланганчы, төп төшенчә / терминнарга аңлатма бирелә: бу очракта телнең функциясе, ягъни иҗтимагый тормыштагы кулланылыш даирәсе, җәмгыятьтә башкарган вазифасы, әлеге юнәлештә телнең куәтен билгеләүче факторлар кебек төшенчәләр күз уңында тотыла. В.А. Авронин һәм башка галимнәрнең хезмәтләренә таянып, телләрнең түбәндәге факторлары / мөмкинлеге истә тотыла: 1) тарихы, үткәндәге функциональ кулланылыш даирәсе (дәүләт теле булуы, ассимиляциягә каршы тору көче); 2) әдәби тел буларак формалашып, вазифа үтәве; 3) фәнни регламентлыгы; 4) яңарышка әзерлеге, лексик берәмлекләрне кабул итеп, тел калыбына салып, яңа сүзләр ясау мөмкинлеге һ.б. Шул ук галимнәрнең хезмәтләренә нигезләнеп: «70 елдан артык вакыт дәвамында яшәгән СССРда дәүләт составында булган халыкларның телен һәм мәдәниятен саклау буенча эш алып барылмый, булган очракта да ул бары сүздә генә кала дип уйларга була. Әгәр шулай булмаса, 1926 елда СССР дәүләтенә кергән республикаларда барысы 194 милләт исәпләнеп, 1974 елда шуларның 101 е генә калмас иде, 93 милләтнең үзе турында онытуына ярты гасыр вакыт җитә», – дип белдерелә. Хезмәттә мәсьәләнең 1920–1990 елларда Татарстан Республикасында ничек тормышка ашырылуы тасвирлана һәм: «Дүрт буын алмашынган арада телебезгә булган игътибарның кимегәннән-кими баруы Республикадагы бүгенге тел ситуациясе билгеләнгәндә читтә калырга тиеш түгел», – дип нәтиҗә ясала, телнең куәтен билгеләүче факторларның мөмкинлеге юкка чыга баруы объектив фикер буларакраслана (б. 63–68).

Татар теленең кулланылыш мохите 5 параграфка бүлеп анлизлана: 2.1. Гаилә мохитендә...; 2.2. Мәгариф системасында...; 2.3. Массакүләм мәгълүмат чараларында...; 2.4. Интернет ресурсларда...; 2.5. Тел һәм дин мөнәсәбәтендә. Әлеге бүлекчәләрнең һәрберсе ныклы план нигезендә яктыртыла: а) бүлекчәнең исеме итеп күрсәтелгән төшенчә / атаманың рухи кыйммәт буларак табигате һәм аерым мохит буларак вазифасы аңалатыла, ә) бу мәсьәләнең татар телендә ничек өйрәнелүе күзәтелә, б) телнең куәтен билгеләүче аерым факторлардан кайсысының, бу мохит өчен хосусый фактор буларак, татар теленең кулланылышына нинди йогынты ясавы хакында яңа фактик материал туплап аңлатыла, киң мәгълүмат бирелә.

Һәр мохитне тикшергәндә, барлык фикерләрне гомумиләштерә барып, телнең куәтен билгеләүче аерым факторлардан кайсысының, аерым мохит өчен зарур фактор буларак, ни рәвешле реальләшүе турында нәтиҗә ясала. 2.1. Гаилә мохитендә: «...баланың туган телен белүе яки башка бер телгә өстенлек бирүе киләчәктә нинди телне аралашу теле буларак дәвам итәчәге тулысынча гаиләдә нинди телгә өстенлек бирелүе белән турыдан-туры бәйле», – дип, тарихи факторның ассимиляциягә каршы тору-тормау көче дигән билгегә игътибар ителә (б. 74 һ.б.). 2.2. Мәгариф системасында: «Мәктәптә, югары уку

йортында белем алучы яшь кеше туган теленнән читләшүнең фаҗигасын бөтен тулылыгы белән аңлый алмый. Ул әле тормышта үз урынын табу турында ныграк кайгырта, максатларын да шул юнәлештә билгели. Инде яулыйсы үрләрне яулап, мин кем? дигән сорауга җавап эзләгәндә генә соң икәнлеге, ул үзе генә түгел инде балаларының да үткәннәр белән бәйләнешен югалтканлыгы аңлашыла. Бу, үз чиратында, туган телен белүчеләрнең саны кимүгә китерә», – дигәндә, телнең тарихи барышында, аның дәүләт теле, әдәби тел буларак формалашып, вазифа үтәгәндә табигый факторның җәмгыятьтә бара торган иҗтимагый-сәяси хәлләргә нисбәтән тел сәясәтендә кабул ителә торган субъектив таләпләр нигезенә күчерелеп, ясалма факторга әверелеп, адәм баласының шәхси тормышта да төзәтеп булмастай (буынны юкка чыгару) үзгәрешләргә дучар ителүе аңлашыла. Хезмәттә бик хаклы рәвештә: «...милли мәсьәләләрне хәл итү һәр кешенең этник мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүнең юлларын тапканда һәм аларны тормышка ашырганда гына уңай чишелеш таба ала», – дип белдерелә (б. 99).

2.5. Тел һәм дин мөнәсәбәтендә, тарихи яссылыкта һәм хәзерге заманда татар теленең кулланылыш куәтен билгеләүче аерым факторлардан кайсысының табигый нигез булуына карата: «Тарихи яссылыкта караганда: татар теленең барлыкка килүе һәм үсүе дә ислам дине белән керешкәнлеген күрәбез. Шуңа күрә татар халкында дин һәм тел бер-берсеннән аерылгысыз бербөтен – иман төшенчәсе белән бәйле каралган. Халыкны үзенә генә хас үзенчәлекләргә ия этник төркем итеп бергә берләштерүче, аның бөтенлеген саклап торучы да ислам дине була. Нигездә, бер дин белән берләшкән этник төркем өчен, тел һәм мәдәният белән беррәттән, дин халыкның милли тәңгәллеген (идентичность) билгеләүче төп фактор булып тора», – дигәндә, тарихи чынбарлыктагы табигый фактор күздә тотыла. Әлеге хакыйкать безнең көннәрдә дәвам итә: «Сорашылганнар татар халкының бөтенлеген саклауда тел һәм диннең ролен түбәндәгечә күрсәтә: 74,2% тел милләт сакчысы дип белдерә, 40,3% дин милли бердәмлекне саклый дип бәяли» (б. 114–115). Шуның белән бергә: «Хәзер, гомумән, ислам кануннарын саклап яшәүче милләттәшләребез арасында татар телен бөтенләй белмәүчеләр дә шактый күп. Бу хәл бигрәктә урта һәм яшь буынга кагыла. Әлеге уңайдан шуны да искәртергә кирәк: 34,3% татар мөселман булу өчен татар телен белүнең әһәмияте юк дип саный» (б. 114–117). Шулай итеп, татар теленең кулланылыш куәтен билгеләүче тарихи нигездәге табигый төп факторның көчсезләнә баруы аңлашыла. Авторлар, һәр башка мохиттәге кебек үк, тел һәм дин мохитендә дә татар теленең кулланылышына йогынты ясый, аны куәтле итә торган төрле факторларның мөмкинлекләрен, тарихи аспектта һәм хәзерге ситуациядә ничек файдаланылуын эзлекле рәвештә билгели баралар, аларның ни рәвешле үзгәрүе ачыклана. Әмма бер урында аның тарихи яссылыкка туры килми торган хәзерге хәле турында: «Ислам дине кабул ителү, үз вакытында татар теленең сүзлек

составын баетып кына калмаган, телнең барлык тармакларына да үзенең йогынтысын ясаган һәм бу хәл бүген дә дәвам итә», – диелә. Әмма бу хәлнең бүген дәвам итмәгәнлеге күпләребезгә мәгълүм.

Билгеле булганча, Тәңрегә инанып, төрле кабиләләр булып яшәүче һәм рун язуыннан файдаланган төркиләр, ислам динен кабул иткәч, Аллаһы Тәгаләдән Мөхәммәд пәйгамбәргә вәхи булып иңгән Коръән Кәрим теле (ягъни гарәп теле) графикасында язарга һәм укып аңларга тиеш булалар; Хак диннең чарасы булганга, гарәп һәм фарсы сүзләрен катгый рәвештә үз чыганак теленең кагыйдәсе буенча язу таләп ителә. Төрки-татарларның үз сүзләре бу кагыйдәгә буйсындырылмый, билгеле бер дәрәҗәдә ныгыган иске имля белән языла. Нәтиҗәдә, ике телнең орфографик нормасы параллель кулланыла торган гарәп графикасындагы төрки-татар язма әдәби теле формалаша һәм, дәверләр буена килеп, XX гасырның урталарында, гарәп графикасы алмаштырылганчы, гарәп алынмалары, корама дип, кулланылыштан куылганчы дәвам итә. Төрле чорда язылган төрле жанр / стильдәге истәлекләрдә гарәп алынмалары 60–70% тәшкил итә, димәк, шул дәрәҗәдә язма норма саклана. Төрки-татар сүзләрендәге сузык һәм тартык авазларны язганда, гарәп теленең мөмкинлеге файдаланыла: ун сузык авазны өч билге белән, бер үк тартык авазны 3–4 билге белән күрсәтергә мөмкин була. Әлеге нигездә вариантлылык барлыкка килә. Әдәби тел норма һәм орфографик вариантлылыгы белән бергә кулланыла. Бүген бу хәл күзәтелми: аерым очракларны искә алмаганда, алынмалар татар теле әйтелешенә буйсындырылып, кириллицада языла, нормалар җимерелә. Төрки-татарларда һичкайчан гарәп теле тулаем әдәби тел вазифасын үтәмәгән, әмма ул язма традициянең көчле бер агымын тәшкил иткән, адресатның кем булуына карап, гарәп-фарсы алынмалары һәм архаик угызчылык формалары мул кулланылып, абруйлы әсәрләр иҗат ителгән. Бу хәл сөйләмә сүз, сүз формалары белән языла торган халыкчан истәлекләрне язу белән параллель барган. Гарәп графикалы әдәбиятта норма булмаган, безне йөз еллар буена, ул революциядән соң гына нормага салынды, дип ышандырдылар, хәлбуки, чынбарлыкта нәкъ киресе күзәтелгән. Бүгенге көндә татар телендә күпчелек абстракт мәгънәле сүзләрнең гарәп-фарсы алынмалары булып калуы гына истә тотыла (Татар әдәби теле тарихы..., 1 т. Казан, 2015, б. 620–626).

Йомгак өлешендә алдагы ике бүлектә җентекләп тикшерелгән проблемалар гомумиләштерелеп ассызыклана. «Тел ситуациясе» төшенчәсе – тел турындагы фәндә әһәмиятле һәм әле өйрәнүне, төгәллек кертүне таләп итә торган төшенчәләрнең берсе ул», – дигән фикердән (б. 122–125) бу юнәлештәге эшчәнлекнең киләчәктә дә дәвам ителәчәге аңлашыла. Республикабызда татар халкының яртысы гына яшәве мәгълүм. Алга таба, «Россия Федерациясендә яшәүче татарларның телләре турында» дигән фәнни хезмәт тә язылыр дигән өметтә калабыз. 1921 елда татар теле дәүләт теле дип игълан ителгәндә, татар халкы яшәгән барлык төбәкләрдә телне гамәлгә кую, ана телен-

дә укыту, вакытлы матбугат басылу күздә тотылган. 1899 елда «Русия төркиләре» дигән төшенчә рәсмиләштерелгән. Аңарчы «Русия мөселманлары» дип йөртелгәнбез. Хәзерге вакытта «Россия татарлары» булып яшибез. Менә шул татарларның ана телен белү-белмәүләре ни хәлдә икән? (Татар әдәби теле тарихы..., 1 т. 2015, б. 169–171). 70 елдан соң кабул ителгән декрет та Татарстан белән чикләнә, димәк, киңәйтебрәк тикшерү, анализлау сорала.

Кушымта авторларның фактик материалларны ничек итеп туплауларын күз алдына китерү ягыннан әһәмиятле. Нәтиҗә ясап әйткәндә, хезмәт чын мәгънәсендә актуаль темага язылган, бүгенге тормышыбыздагы иң мөһим мәсьәләне яктырта һәм фәнни хезмәт таләп иткән тәртиптә системага салган. Шунысын да әйтергә кирәк: татар теленең кулланылышына йогынты ясый, аны куәтли торган күптөрле факторларның мөмкинлеге тарихи аспектта һәм хәзерге ситуациядә ничек файдаланылуы эзлеклелегендә ачыла. Димәк, тел сәясетенә бәйле хәлдә аларның үзгәреше күренә. Әлеге монографиянең сәясәтчеләр, тарихчылар, гомумән татар зыялылары кулына барып керүе бик әһәмиятле дип уйлыйм.

***Бәширова Илида Басыйр кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

**2022 елның 4 гыйнварында** 100tatar.ru сайтында «XX гасырның 100 татар җыры» проекты эшли башлады. Сайтта татар мәдәнияте тарихын милли музыка аша өйрәнергә мөмкинлек тудырылган, әлеге юнәлештәге материаллар унар еллык чорларга бүлеп тәкъдим ителгән. Композицияне теге яки бу чорга керткәндә, аның иҗат ителү, яздырылу яки эфирга чыгу вакыты, яки шул чорга ниндидер мөнәсәбәте булуы игътибарга алынган, җырларга сылтамалар ачык чыганаклардан тупланган.

**2022 елның 10 гыйнварында** Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтында «Бу кырлар, бу үзәннәрдә минем, үзем генә белгән җырлар бар» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Ул күренекле татар шагыйре, публицист, җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Сибгат Хәкимнең (Сибгат Таҗи улы Хәкимов) тууына 110 ел тулуга багышланган иде.

**2022 елның 12 гыйнварында** Казан Кремлендә Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам кабул ителүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү буенча республика оештыру комитеты утырышы узды. Утырышны Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов үткәрде. Комитет утырышында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев чыгыш ясады. Утырышта шулай ук ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары, «Хозур» нәшрият йорты директоры Ришат Хәмидуллин тәкъдим иткән Ислам кабул итүнең 1100 еллыгы логотибы проекты хупланды.

**2022 елның 15 гыйнварында** Мамадыш шәһәрендә һәм районның Тулбай авылында күренекле язучы Шәйхи Маннурны искә алу кичәләре оештырылды һәм әдип исемендәге премияләр тапшырылды. Әлеге премиягә быел «Мин дә китәрмен әле» (2019) китабы өчен шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтша, күпьеллык әдәби эшчәнлеге һәм «Мои мечты», «Мне снится край любимый» (2020) китаплары өчен шагыйрь Владимир Калашников лаек булды.

**2022 елның 8 февралендә** Россия фәне көне уңаеннан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин катнашында Гомуми отчет җыелышы узды. Җыелышның көн тәртибенә, төп мәсьәлә буларак, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты М.Х. Сәләховның 2021 ел нәтиҗәләре буенча хисабы кертелгән иде. Чара кысаларында югары хезмәт нәтиҗәләрелеге күрсәткән галимнәргә Татарстан Республикасы дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең исемле премияләре тапшырылды.

**2022 елның 11 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты «Татарларның Урта гасыр тарихына кагылышлы госманлы чыганакларын өйрәнү перспективалары» дигән темага Халыкара түгәрәк өстәл

уздырды. Әлеге фәнни чарада И.В. Зайцев (Мәскәү), Ильяс Кемалоглу (Истанбул, Төркия), И.М. Миргалиев, Д.М. Исхаков, И.А. Мөстәкыймов, И.Л. Измайлов, М.М. Гибатдинов, А.А. Зәбиров (Казан) кебек күренекле тарихчы галимнәр катнашты. Чыгыш ясаучылар күтәргән проблемалар түгәрәк өстәлдә катнашучыларда зур кызыксыну һәм яңа фикерләр уятты, чара бик җанлы узды.

**2022 елның 17 февралендә** Татарстан Республикасы Язучылар берлегендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре сигез томлы «Татар әдәбияты тарихы»н тәкъдим итте. Чарада Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары, танылган әдәбият галимнәре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашты.

Күптомлык Татарстан Республикасының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы заказы белән нәшер ителде. Чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты, филология фәннәре докторы, профессор Дания Заһидуллина, ТӘһСИнең әдәбият бүлеге мөдире, фиология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов, басманың төзүчесе, филология фәнннәре кандидаты, шагыйрь Равил Рахмани чыгыш ясадылар, катнашучыларның күпсанлы сорауларына җавап бирделәр.

**2022 елның 21 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан татар лексикографиясенең актуаль проблемаларына багышланган түгәрәк өстәл уздырылды. Чарада Татарстан Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты, Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты галимнәре, Башкортстан Республикасы фәнни җәмәгатьчелеге, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты вәкилләре, Татарстан китап нәшрияты мөхәррирләре, шулай ук республика вакытлы матбугат басмалары журналистлары, укытучылар, республика районнары башкарма комитетлары тәрҗемәчеләре катнашты. Махсус оештырылган күргәзмәдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан төзелгән һәм бастырылган сүзлекләр тәкъдим ителде. Алар арасында 2014 – 2021 елларда дөнья күргән алты томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»; шул ук сүзлекнең Татарстан китап нәшриятында чыккан икенче басмасы (өч том); ике томлык русча-татарча сүзлек; татар теленең кыенлыклар сүзлеге, орфоэпия, фитонимнар сүзлекләре һ.б. аерым урын алды.

**2022 елның февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Халыкара Туган тел көненә багышланган күптөрле чаралар оештырылды. Г. Тукай исемендәге Арча педагогика көллиятендә, Г. Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт драма театрында «Габдулла Тукай: тормышы һәм иҗаты (Габдулла Тукайның

тормышы һәм иҗаты хроникасына материаллар)» дип аталган өч томлык фәнни хезмәт тәкъдим ителде; 6 томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» басылып чыгу уңаеннан «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында матбугат конференциясе үткәрелде; Казанның төрле мәктәпләренә фәнни десант оештырылды; Институт хезмәткәрләре Башкорт дәүләт университетында татар теленнән IX–XI сыйныф укучылары арасында узган республика дистанцион олимпиадасында актив катнашты һ.б.

**2022 елның 18 февралендә** «Окно» заманча сәнгать галереясында «Кушылу ноктасы» («Точка прикосновения») дип аталган заманча скульптура күргәзмәсе ачылды. Күргәзмәдә Татарстанның алты яшь скульпторыннан торган иҗади төркем – Н. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесын һәм В.И. Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт академия сәнгать институтының Казандагы филиалын тәмамлаган Зөлфия Мөхәммәдьянова, Артур Давыдов, Ксения Зубкова, Тимофей Тюрин, Дамир Закиров, Динар Сәлимовларның соңгы тугыз елда иҗат ителгән эшләре тәкъдим ителде. Академик пландагы реалистик, натуралистик һәм символикага корылган әсәрләр бүгенге чорны һәм вакытка бәйсез образларны ача. Экспозициядә, экспрессионистик рухтагы һәм декоратив сыннар белән беррәттән, постмодернизмага хас булган экспериментлар да бар. Күргәзмә жанрлар төрлелеге белән үзенчәлекле: портрет (ул реалистик та, символик та булырга мөмкин), сюжетлы композицияләр, анималистика, «ню», медаль сәнгате һ.б. Биредә скульптурада кулланыла торган төрле материаллардан (бронза, гипс, керамик балчык, агач, таш) эшләнгән сыннарны, шулай ук бүгенге көндә сынлы сәнгатьтә кулланыла торган заманча материалларны да күрергә мөмкин.

Күргәзмә 15 апрельгә кадәр эшләячәк.

**2022 елның 21 февралендә** Санкт-Петербургның Татар мәдәнияте үзәгендә Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәрендәге һәм Ленинград өлкәсендәге Даими вәкиллеге тарафыннан каһарман-шагыйрь Муса Җәлилгә багышлап «Муса Җәлил: үлемсезлеккә хөкем ителгән» дип исемләнгән кичә оештырылды.

**2022 елның 22 февралендә** Идел Болгарстанында рәсми рәвештә Ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу уңаеннан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Ачык ишекләр көне үткәрелде. Чарада Татарстан Диния нәзарәтеннән вәкилләр, дини уку йортларыннан белгечләр, журналистлар катнашты. Түгәрәк өстәлдә татар дини-рухи мирасын җыю, саклау, актуальләштерү проблемалары хакында сүз барды. Чара кысаларында Мирасханә фондларында сакланган сирәк ядкярләр, кулъязма мирас үрнәкләре, шәҗәрәләр, әдипләребезнең шәхси архив материалларыннан, Институт тарафыннан әзерләнгән фәнни хезмәтләрдән күргәзмә оештырылды. Түгәрәк өстәлдә катнашучыларга «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясеннән Институт галимнәре соңгы елларда әзерләгән китаплар бүләк итеп тапшырылды.

**2022 елның 24 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Татарстанның мәдәни мирасын саклау һәм үстерү мәсьәләләренә (тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать, театр, музыка өлкәсендә) багышланган түгәрәк өстәл узды. Ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының йомгаклау чаралары кысаларында Россиядә халык сәнгате һәм матди булмаган мәдәни мирас елына багышлап оештырылган иде. Түгәрәк өстәл барышында ТР ФА. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләренең яңа басмалары тәкъдим ителде.

Чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты фәнни хезмәткәрләре, Казан дәүләт консерваториясе, Казан дәүләт мәдәният институты, Н.И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы, Казан театр училищесы укытучылары, Татарстан Республикасында мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге, Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать дәүләт музее, Татарстан Республикасы Милли музее, Россия сәнгать академиясенең Казандагы иҗат остаханәсе хезмәткәрләре, сәнгать белгечләре, Татарстан рәссамнар берлеге, Сәнгать белгечләре ассоциациясе әгъзалары (шул исәптән Яр Чаллы, Яшел Үзән шәһәрләреннән), республика матбугаты вәкилләре катнашты. Түгәрәк өстәл кысаларында оештырылган күргәзмәдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать, театр һәм музыка бүлекләре хезмәткәрләренең соңгы ун елда дөнья күргән басмалары тәкъдим ителде.

**2022 елның 25 февралендә** «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында татар әдәби теле һәм татар теле лексикологиясе тарихы турындагы күптомлы басмаларга багышланган матбугат конференциясе үткәрелде. Чара Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының телче-галимнәре катнашында узды. Институтның директор урынбасары, филология фәннәре кандидаты Олег Хисамов, лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре, КФУ Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар тел белеме кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы Гөлшат Галиуллина, гомуми лингвистика бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты Бәхтияр Миңнуллин, шул ук бүлекнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Рифат Мирхәев өч томлы «Татар лексикологиясе» (2014–2018), «Татар әдәби теле тарихы» (2014–2020) басмалары хакында сөйләделәр.

**2021 елның 1 мартында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «Коръәннең Казан басмалары: тарих һәм тикшеренүләр» темасына түгәрәк өстәл узды. Фәнни чарада тарихчылар, ислам белгечләре, журналистлар катнашты. Түгәрәк өстәлнең төп темалары Россиядә Коръән басылу тарихы, Коръәннең Казанда дөнья күргән беренче басмалары, Азия (Гимназия)

типографиясе эшчәнлеге, мөселман дөньясында, Казанда нәшер ителгән Коръән китаплары, Коръән басу буенча Азия типографиясе эшчәнлеген мәңгеләштерү кебек мәсьәләләргә багышланган иде.

**2022 елның 3 мартында** 8 март – Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәгендә «Татар тарихында хатын-кыз» дигән темага түгәрәк өстәл узды. Түгәрәк өстәлдә «Урта гасыр төрки-мөселман дәүләтләрендә хатын-кыз», «Татар тарихчылары хезмәтләрендә күренекле ханымнар образлары», «XX гасыр башында мәгърифәтче хатын-кызларның эшчәнлеге», «Татар ханымнары – мөһаҗирәтнең күренекле вәкилләре», «Татар хатын-кызларының Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышы чорларында күрсәткән батырлыклары», «Татар ханымнары – күренекле җәмәгать эшлеклеләре (Совет чоры, хәзерге чор)» һ.б. юнәлешләрдә фикер алышулар оештырылды.

**2022 елның 3 мартында** Һади Атласи исемендәге иҗтимагый фонд һәм Бөтендөнья татар конгрессы Бөгелмә шәһәренең Һади Атласи исемендәге татар гимназиясендә күренекле тарихчы, милли сәясәтче, мәгърифәтче Һади Атласиның тууына 145 ел тулуга багышланган «Һади Атласи мирасы һәм милли мәгариф: бүгенге көн мәсьәләләре, чишү юллары» темасына фәнни-методик семинар уздырды. Татар зыялылары, галимнәр, язучылар, мәгариф хезмәткәрләре катнашкан чарада тарихчылар Алсу Мөхәммәтдинова, Искәндәр Гыйләҗев, Фәүзия Бәйрәмова, әдәбият галиме Әнвәр Шәрипов, Татарстан Республикасының Халык укытучысы Камәрия Хәмидуллина, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, Милли китапханә директоры урынбасары Ирек Һадиев һ.б. чыгыш ясады.

**2022 елның 11 мартында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимовның тууына 135 ел тулуга багышлап уздырыла торган чаралар Уфа шәһәрендә башланып китте. Башкорт дәүләт педагогика университетында классикның Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан нәшер ителгән өр-яңа 15 томлы академик җыентыгының презентациясе оештырылды. Әлеге чарада Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов һәм текстология бүлеге фәнни хезмәткәре Фәния Фәйзуллина, ТР Язучылар берлеге рәисенең беренче урынбасары, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, шагыйрә Илсөяр Иксанова катнашты.

**2022 елның 12 мартында** күренекле татар язучысы Галимҗан Ибраһимовның туган ягында – Башкортстан Республикасы Авыргазы районы Солтанморат авылында әдипнең тууына 135 ел тулуга багышланган «Халкыбызның бөек шәхесе» исемле

тантаналы кичә узды. Чарада Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре дә катнашты. Әдәбият белеме бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов Институт эшчәнлеге, әдип тормышын һәм иҗатын өйрәнүнең бүгенге торышы турында сөйләде. Текстология бүлеге фәнни хезмәткәре Фәния Фәйзуллина әдипнең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнгән, 2018–2021 елларда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан 15 томлык академик басмасының эшләнү тарихы һәм аның яңалыгы белән таныштырды. Академик басма Солтанморат авылындагы Г. Ибраһимов музеена бүләк итеп тапшырылды.

Кичәгә Солтанморат авылында яшәүчеләр, Г. Ибраһимов музеен төзүдә зур хезмәт куйган шәхесләр, татар һәм башкорт иҗтимагый оешмалары вәкилләре, журналистлар, югары уку йорты укытучылары, район мәдәният хезмәткәрләре, күпсанлы кунаклар чакырылган иде.

**2022 елның 12 мартында,** бөек язучы Галимҗан Ибраһимовның туган көнендә, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге вәкилләре катнашында әдипнең Казан шәһәренең Мәскәү районында урнашкан Г. Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясендәге бюстына чәчәкләр салу оештырылды.

Моннан тыш, 2022 елның 14 мартында гимназиядә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни хезмәткәрләре белән очрашу узды. Чара барышында гимназия укучыларына һәм укытучыларына Институт эшчәнлеге, аерым фәнни проектлар, шул исәптән Г. Ибраһимов әсәрләренең 15 томнан торган академик басмасы тәкъдим ителде. Басманың яңа гына дөнья күргән 11–15 томнары Г. Ибраһимов музеена бүләк итеп тапшырылды.

**2022 елның 15 мартында** Яр Чаллы дәүләт педагогика университетында филология факультеты укытучылары һәм студентлары, шәһәрнең туган тел укытучылары, язучылар, журналистлар һәм сәнгать эшлеклеләре катнашында узган очрашуда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре институтның милли мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеген тәкъдим итте.

Чара Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты ректоры, икътисад фәннәре кандидаты Әлфинур Галиәкбәрованың сәламләве белән башланып китте. Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор Ким Миңнуллин чарада катнашучыларны Институт эшчәнлеге белән таныштырды, галимнәр тарафыннан тормышка ашырыла торган проектлар, соңгы елларда дөнья күргән фәнни хезмәтләр турында сөйләде. Шуларның берсе – татар әдәбияты классигы, XX гасыр башы җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең 15 томлыгы. Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан академик басма белән текстология бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Гөлнара Зәйниева җентекләп таныштырды, ул басманың үзенчәлекләрен, яңалы-

гын аерым билгеләп үтте. Әдәбият белеме бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов 8 томлы «Татар әдәбияты тарихы»н тәкъдим итте; сүзлекләр әзерләү һәм бастыру эше турында лексикография бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты Ринат Сәфәров сөйләде. Милли мәгариф бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты Гөлназ Мөхәрләмованың Институт галимнәре ФДБСка нигезләп эшләгән дәреслекләр һәм дидактик материаллар турындагы чыгышы туган тел укытучыларында аеруча зур кызыксыну уятты. Барлык тәкъдим ителгән китаплар, шулай ук соңгы елларда нәшер ителгән басмалар университетның китапханә фондына тапшырылды.

Әлеге чара Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе һәм Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты арасында хезмәттәшлек турында килешү кысаларында оештырылды.

**2022 елның 24 мартында** Россиядә Халык сәнгате һәм матди булмаган мәдәни мирас елына багышланган чаралар кысаларында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Россия һәм Татарстан композиторлар берлекләре әгъзасы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, философия фәннәре кандидаты Мәсгудә Шәмсетдинова белән «Бишек көйләрендә – Галәм аһәңе» темасына очрашу узды.

Чарада Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни хезмәткәрләре, Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе, Казан дәүләт мәдәният институты укытучылары һәм студентлары, Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм гореф-гадәтләрне саклау ресурс үзәге хезмәткәрләре, журналистлар, рәссамнар катнашты.

Очрашуда композитор Япония, Кытай, Корея һәм башка илләр вәкилләреннән язып алынган аутентик бишек җырларын, шулай ук алар нигезендә язылган үз әсәрләрен тәкъдим итте.

Очрашуда катнашучылар чара кысаларында оештырылган күргәзмәдә татар халык җырлары җыентыклары, татар музыкаль мирасы буенча фәнни хезмәтләр белән таныштты.

**2022 елның мартында** Галимҗан Ибраһимовның тууына 135 ел тулуга багышланган күпсанлы чаралар дәвам итте: «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында әдипнең Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнгән 15 томлы академик җыентыгына багышланган матбугат конференциясе үткәрелде; КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында яшь галимнәрнең «Галимҗан Ибраһимов, язучы, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе» дип аталган Халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды; Г. Тукайның Казандагы әдәби музеенда яшь тәнкыйтьчеләр катнашында «Татар шагыйрьләре» дигән темага түгәрәк өстәл, Татар китабы йортында «Гасырлар киселешендә Г. Ибраһимов шәхесе һәм иҗаты» дип исемләнгән искә алу кичәсе оештырылды; Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «Галимҗан Ибраһимов – язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе» дигән китаплар күргәзмәсе ачылды һ.б.

***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

– авторның фамилиясе, инициаллары

– мәкалә исеме (татар һәм рус телендә)

– аннотация (рус һәм инглиз телендә)

– төп сүзләр (рус һәм инглиз телендә)

– сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, әтисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата фән докторы яки фән кандидаты тарафыннан язылган рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12, 1 нче кат, 10 нчы бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Уңышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек*
*итүебезгә өмет баглап,*
*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2022. № 1

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 31.03.2022. Басылды: 20.04.2022.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 12. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшриятында басылды
(нәшрият адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал бушлай таратыла

О.Ю. Бердникованың «Татарстанда заманча мода юнәлеше буларак, киез һәм ефәк костюмнар» мәкаләсенә







О. Смирнова. «Иске Казан әкиятләре» костюмнар коллекциясеннән

Л.М. Шкляеваның «Идел буендагы җирле халыклар эстетикасында изге имән образы» мәкаләсенә



Р. Әхмәтов. «Минем йортым – минем мирасым». Агач, металл



З. Бикташева. Панно. Чигү, аппликация. 2014



Намазлык. Чигү. XIX гасыр ахыры. Башкортстан Республикасы Стәрлебаш районы



Ә. Хәйрова. Сөлге. Туку, чигү. Пенза өлкәсе Кузнецк районы



Г. Ибраһимовның Киев төрмәсеннән чыккач Хәлилулла Еникиев белән төшкән фотосы. 1913. *ЯhММҮ. Ф. 65, тасв. 5, с. б. 16*



Г. Ибраһимов Шәһит Әхмәдиев белән. *ЯhММҮ. Ф. 65, тасв. 5, с. б. 47*



Г. Ибраһимов Шакирҗан Ибраһимов һәм Шәһит Әхмәдиев белән. *ЯhММҮ. Ф. 65, тасв. 5, с. б. 32*



Г. Ибраһимов Гыйбадулла Алпаров белән. 1913. *ЯhММҮ. Ф. 65, тасв. 5, с. б. 6*



Г. Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсе шәкертләре арасында. *ЯhММҮ. Ф. 65, тасв. 5, с. б. 3*



Г. Ибраһимовның 15 томлы академик басмасы



К.М. Миңнуллин һәм Ә.А. Галиәкбәрова Яр Чаллы дәүләт педагогика университетында узган очрашуда. 2022 ел, 15 март. *Фото https://mail.google.com/mail/u/0/#inbox/FMfcgzGmvVCxxjZcgwfJJkpCJfwllgjs сайтыннан алынды*



«Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында Г. Ибраһимов әсәрләренең 15 томлы академик басмасына багышланган матбугат конференциясе. 2022 ел, 17 март. *Фото https://tatar-inform.tatar/photo_galleries/17-03-2022/galim-an-ibra-imovny-akademik-tuplanmasy-basylyp-chygu-u-aennan-matbugat-ochrashuy-5851517 сайтыннан алынды*



Башкорт дәүләт педагогика университетында Г. Ибраһимов әсәрләренең 15 томлы академик басмасын тәкъдим итү. 2022 ел, 11 март. Уфа



Г. Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясендә ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни хезмәткәрләре белән очрашу. 2022 ел, 14 март



Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Татарстанның мәдәни мирасын саклау һәм үстерү мәсьәләләренә (тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать, театр, музыка өлкәсендә) багышланган түгәрәк өстәл. 2022 ел, 24 февраль



Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Ачык ишекләр көне. 2022 ел, 22 февраль.



Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә татар лексикографиясенең актуаль проблемаларына багышланган түгәрәк өстәл. 2022 ел, 21 февраль

## Яңа китаплар




